## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ

# КЫЗЫЛ ЧӘЧӘКЛӘР

(Без түбәннән күтәрелдек)

Хикәя

*«Кызыл чәчәкләр» хикәясе якты, азат көннәр өчен көрәш юлында һәлак булган иптәшләргә багышлана.*

### БАШЛАНГЫЧ

(Кызыл орлыклар)

Без түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек.

Кем күтәрде? Кайчан? Ничек? — Сезгә менә шул турыда сөйләп бирергә телим.

Мин яшь сабый идем әле.

Кайдан килеп, кайда баруы һичкемгә мәгълүм булмаган бер үткенче[1] мөсафир бабай бездә, хәл җыярга туктаган вакытта, үлеп калды. Ул бик карт иде. Бөтенләй ялгыз иде. Шуның өчен, кызганып яшь түгүчесе дә булмады.

Менә шул бабай, үләр алдыннан үзенә чакырды да, миңа бер уч тутырып орлыклар бирде.

Болар – кызыллар иде, матурлар иде.

– Яз килгәч, – диде, – боларны чәчәрсең! Туфракларын йомшарта тор! Вакытында су сибәргә онытма! Өсләренә чүп-чар төшеп, кояш яктысыннан мәхрүм булмасыннар, яхшы кара! Әгәр мин кушканча эшләсәң, җәй көне кызыл чәчәкләрең булыр, көзгә матур кызыл орлыклар җыеп алырсың... Икенче елга тагын чәчәрсең, шулай итеп бакчаң җәннәткә әйләнер[*], синнән күрмәкче башкалар да шулай эшләрләр!

Мәрхүмнең сүзен тыңладым. Ләкин чәчкән орлыкларым өстенә үзем юкта тирес түккәннәр, нindидер бер явызы кара таш белән бастырып киткән, – орлыкларым вакытында чыга алмый калганнар, кайберләре, томаланып, бөтенләй черегәннәр.

Моңа җаным бик әрнеде. Тиресне себереп түктем. Ташларны читкә алып ыргыттым.

Җылы яңгырлар яуды, якты кояш карады; ни күрим: бер атнадан матур сабаклар, яшел яфраклар чыкты; җәй көне аллы-гөлле кызыл чәчәкләр бөтен бакчама ямь бирде; көз көне энҗе-мәрҗән бөртекләре кебек тигез, матур кызыл орлыклар җыеп алдым. Болар миннән бөтен авылга, бөтен тирә-якка

---

[1] *Үткенче* – үтеп баручы.

[*] 1936 елгы басмада *җәннәткә әйләнер* сүзләре *чәчәккә тулар* сүзләре белән бирелгән.

таралды.

Мин моны бөтенләй онытккан идем инде.

Тарихның яңа сафланган йомшак туфрагында үсеп килгән асыл ирләрне сөйли башлагач, ничектер яңадан хәтеремә төштеләр.

**«Кызыл чәчәкләр» хикәясе.**

(Биш егетнең язмыш тарихы)

I

Россия[*] мәмләкәтендә, бөек Башкортстан туфрагында, Агыйделнең киң болыннар, зур таулар арасыннан боргаланып-боргаланып аккан җирдә үзенең зурлыгы, йортларының төзеклеге белән кечерәк шәһәргә охшашлы бер авыл бар...

Диңгез сулары кебек зәңгәрләнеп уйный торган зур, матур күл буена утырганга, бу авылны Зәңгәр чишмә дип атыйлар.

Зәңгәр чишмәнең бакчаларында чәчәкләр адәм күзе карап туя алмас дәрәҗәдә куе төстә чибәр булып җитешәләр; болыннары елның-елында тирә-якны җәй көне яшел үлән белән, кышкы суыкта солыдан кадерле санала торган хуш исле коры печәннәр белән хәйран итәләр; өч яклап тезелгән таулары, катлау-катлау баскычланып, югары болытларга сузылалар; урманнарында меңәр еллык карт наратлар, чыршылар җәен-кышын яшәреп, шаулашып утыралар; елгалар, күлләр буеннан сөзәк сырт булып җәелеп киткән киң басулары шундый бәрәкәтлеләр ки, вакытында җылы яңгырлар яуса, кояшлы аяз көннәр булса, бу яланнарның мамык кебек йомшак, көзге төн болытлары кебек куе кара туфраклары ярты дөньяны туйдырырлык нигъмәтләр бирәләр...

Авылның уртасында зур базар кайный; аның ике ягыннан биек матур сарайлар, зур тимер йозак белән бикләнә торган ак таш кибетләр тезелеп китәләр...

Боларга тоташып, бераз читкә таба, урта хәлле кешеләрнең уртача зурлыкта өйләре, уртача биналар үз дәрәҗәләренә күрә урын алалар.

Тагы бераз китсәгез, йортлар кечерәя, караltылар, егылмасам ярар дип куркып, үзләренең иске черек терәкләренә таяна төшеп, һәр җилгә калтыранып, һәр яңгырны эченә алып, язмышның бөтен көчләре алдында ыңгырашып гомер итәләр. Иң ахыр барып, күпер башларында, басу капкасы буйларында чүплекләргә, тиресләргә салынган балчык өйләр, корымлы читән куышлар, үзләренең кайгылы йөзләре, сәләмә кыяфәтләре белән, каты җилләргә, көчле бураннарга каршы тора алудан өмет өзгән бер хәлдә дөнья кичерәләр...

Мин менә шул читтәге «өйләр»нең берендә тудым.

Язмыш дулкыннары белән бер кавышып, бер аерылып яшәгән дүрт иптәшем дә шул авылның төрле урамнарында, байлыгы-төзеклеге төрлечә булган төрле өйләрдә туып үстеләр.

---

[*] 1936 елгы басмада: *Иске Русия.*

Арабыздан тик Шаһбазның гына кайда туганын белмиләр; минем бу газиз дусымның дөньяга килүе – анасының кабергә китүенә сәбәп булганга, гөнаһлы, җинаятьле атасының кем икәне һичберәүгә мәгълүм булмаганга, бу уйнаштан туган баланың гомереннән беренче сәгатьләрен һичбер намуслы өй үзенә алырга теләми. Моны ул үзе дә белми, башкалар да сөйләмиләр.

---

Кышның тирән серләренә адәм баласы кайчан, нинди юл белән ирешә алачактыр? – моны һичкем әйтә алмый. Мәхәббәтнең тышкы киемнәре дә бик артык чуар, акыл ирешмәс дәрәҗәдә төрле!..

Зөһрә апа яшьтән үк берәр сылу җегетне йөрәгенең тирән катлауларында иркәләп үстереп тә, авыр тәкъдиргә ачудан, адәмнәр алдында гөнаһ саналган рәвешчә, үзенең беренче төнен шуңа биргәндерме?! Шаһбаз шундый бер мәхәббәтнең җимешедерме? Яки дәртле яшь йөрәк көтелмәгәндә очраган берәр ир җегетнең көчле тәне белән сихерләнеп, акылын, хәтерен җуйгандыр да, ул арысланны үз кочагына алгандырмы? – моны һичкем белми, болар һәммәсе ирсез ана белән караңгы кабергә киткәннәр.

Ни булса булган: Зөһрә апа никахсыз, мәгълүм атасыз бала тапкан да, үзе җан биргән.

Анын яшерен мәхәббәтенең җимеше үткен Шаһбаз, үз гомерен чабата тукып, аркан ишеп үткәрә торган ялгыз, фәкыйрь бабасы Әхми карт кулына калган.

Күзгә караңгы төннең нурлы йолдызлары уйнаштан туган Шаһбазны беренче мәртәбә менә шул картның авыл читендәге балчык өендә, агач сәкедә, – юкәләр, мунчалалар арасында каршылыйлар. Ерак күк бу атасыз-анасыз баланың беренче шикаятьле авазын менә шуннан ишетә.

Җиде яшькә җиткәч, чабатачы Әхми карт та үлә; шул зур авылда минем киләчәктәге дүрт дусымның берсе булган бу бала бөтенләй ятим, ялгыз кала.

**II**

Зәңгәр чишмә үзенең зур базары белән бөтен Агыйдел буенда дан тоткан авылларның берсе, – бәлки, беренчесе.

Бөтен тирә-якның игене, малы, ялланырга теләгән ярлы җегетләре, урак-печән эшләре эзләгән фәкыйрьләр җомга саен безгә агылалар, бездән тагы ерак җирләргә тараләлар.

Безнең өй авылның читендә, олы юлга салынган күпер башында булганга, бу базар көннәре минем өчен дә байтак төшем бирәләр.

Шау-шу белән авылның зур көтүләрен үткәргәч тә, үзем кебек малайларны, кызларны ияртәм дә күпер капкасына чыгам. Чөнки ерак җирнең базарчылары кичтән үк безнең авылга килеп куналар.

Иң алдан Зәңгәр чишмәнең үз сатучылары кайталар. Болар атналар буенча башка базарларда йөргәннәр, кайсылары калага кызыл малга барганнар. Товар белән тулган зур тарантас арба сыгыла-сыгыла килә. Бай үзе шуның өстенә менеп утырган.

Кыңгыраулап җигелгән өч атны кучер атлатып кына китерә – хайваннар симез, матур булсалар да, озак юл йөргәнгә, байтак талчыккан күренәләр. Авызлары күбекләнгән, өсләрендәге тир яңа бераз ката башлаган, үзләре салмак кына атлыйлар.

Болар безгә файдасыз: үзебезнең авылныкы булганга, бер нәрсә дә бирми үтәләр.

Алар артыннан яхшы атлары, начар арбалары белән башкортлар килә башлый; боларның кайсында мичкә-мичкә кымыз, кайсында тәпән-тәпән май, капчык-капчык корт була. Арада тәгәрмәч тугымы, күмер, мунчала кебек нәрсәләр төягәннәре дә күренеп үтә.

Без һәммәсенә капка ачабыз; күбесе безгә ярты конфетмы, прәннекме, каткан клиндер кисәгеме ташлап китә. Кайберләре үзенең саранлыгы белән мәгълүм булганга, алдан сатулашып алабыз.

Капка ачып та бирми китсәләр:

– Башкорт, башкорт барага,
Кермә безнең арага,
Утыртырбыз бүкәнгә,
Типкәләрбез җилкәңә... –

дип җырлап, мыскыл итеп озатабыз...

Иң ахырдан, караңгы төшә башлагач, шыгыр-шагыр итеп, озын-озын кәрваннар кебек, иген төягән, ат, сыер таккан чувашлар, урыслар*, типтәрләр, алатырлар килә башлыйлар.

Болардан бер нәрсә дә чыкмавы билгеле булганга, без инде капка ачып мәшәкатьләнмибез. Ул арада әнкәй дә, күпергә караган читәнгә килеп, миңа кычкыра:

– Солтан, кайт инде, балам! Иртәгә иртә торасың бар... Аша да ят, – ди.

Бу вакыт теге базарчылар симез ит пешертәләрдер, ак күмәч ашыйлардыр, – ә безгә нәрсә?

Көндездән калган ике бәрәңгене тозлап ашыйм, сөтсез, шикәрсез бер чынаяк чәй эчәм дә, читән өебезнең ишек алдына чыгып, әткәйнең чикмәненә уралып, җир идәнгә йокларга ятам.

**III**

Яз буена җыйган кавырсыннарым бар. Өч дистәдән арттылар инде.

---

* 1936 елгы басмада автор *руслар* дип бирә.

Боларны саткач, базары уңышлы булса, бәлки, бик зәһәр берничә корыч кармак алып булыр дип уйлап куйганмын. Зәңгәр күлдә быел эре чуртаннар күренәләр, болар, ахрысы, язгы ташкын вакытында Агыйделдән кереп калганнар. Берничә тапкыр тирәнрәк итеп салып карасам да, эш чыкмады: кармагымны бөгеп яисә сындырып качтылар, болар өчен теле очына якын корыч кармаклар кирәк.

Иртәгә базарга иртәрәк чыгып, башка малайларга чаклы кавырсыннарымны[2] сата алсам, иң аз дигәндә, ике корыч кармак ала алырмын әле.

Күпер капкасыннан кергәч, аннан-моннан ашап, тизрәк ятуым бигрәк тә менә шуның өчен иде.

Шул кармаклар, чылгыйлар[3], чуртаннар турында уйлана торгач, бик күп йокы калган, ахрысы: иртә белән әткәйнең тавышына уянып китсәм, кояш әллә кая күтәрелгән инде.

Юынмадым, чәй-фәлән сорап тормадым, бер сынык икмәк катысы белән санап куйган чылгыйларымны алдым да тышка йөгердем.

Чыксам, ни күрим?!

Әткәй кулындагы өч җәпле[4] зур сәнәк белән кемгәдер кизәнеп бара, кыйнарга әйтә, үзе һаман кызып-кызып сүгенә:

– Азрак акылың булса, уйлап кара син, Әхмәт, – ди. – Гыйрфан байның азбар тизәген кешенең өе буена китереп түгәргә сиңа нинди закон кушар! – ди.

Ни бар, әллә сугышалармы, дим, алар янына чаптым[*].

Күргәч, минем дә җаным әрнеп китте.

Гыйрфан байның ялчысы Әхмәт зур бер йөк тирес төяп китергән дә Зәңгәр чишмәнең яр буена, безнең өйдән ике-өч сажин гына бер җиргә аударган.

Әткәйнең кызуы шуның өчен икән.

Ялчы башта карулашып маташты:

– Бер мин түгел, башкалар да китереп түккәннәр бит, – ди.

Әткәй сәнәк белән аның өстенә кычкырып бара:

– Түксәләр, мин юк чакта, мин күрмәгәндә түккәннәр; моннан соң мин сезнең тиресләрегезнең сасысын иснәп яшәр хәлем юк, – ди.

Ялчы тагын сүз кайтара:

– Сасы иснәп яшәргә теләмәсәң, монда күпер башына килеп

---

[2] *Кавырсыннарымны* – кош канатындагы эре каурыйларымны.
[3] *Чылгыйлар* – кош канатларының иң кырыйдагы каурыйлар.
[4] *Җәпле* – монда *япьле* (тешле).
[*] 1936 елгы басмада: *чыктым*.

утырмассың, – ди.

Бу сүзгә безнең күршеләрдән Шаһи карт белән Сафа абзый да бик ачуланып килеп чыктылар:

– Нәрсә син, Әхмәт, безне ул чаклы мыскыл итәсең?.. Бай дигәч тә, кем ул чаклы синең Гыйрфаның? – дип, бик гайрәт белән килеп тотындылар да, көчләп, төрткәләп, җегетнең түккән тиресләрен кире арбасына төятә башладылар.

Әхмәт йомшарды:

– Әй, абзыйлар, ди, сез миңа ачуланасыз, ди, мин дә бит кеше кулындагы бәндә, ди. Кичәгенәк, ди, басу капкасының аръягына чыгарып түккән идем, озак йөрисең дип, Гыйрфан абзый эт урынына ярды... Әллә кая йөрмә ди, әнә шунда күпер башына түк тә кайт ди. Ә сез миңа ачуланасыз, – ди.

Әткәй, Сафа абзый, Шаһи бабай, көрәкләр, сәнәкләр алып, Әхмәткә булыштылар, тиз арада төяп бетерделәр. Ялчы:

– Миңа рәнҗемәгез, агайлар... Бай кушкач, аптыраганнан түккән идем, – дип сөйләнә-сөйләнә, тиресләрен күпер аръягына алып китте.

Шаһи карт:

– Ну, эт соң бу Гыйрфан дигәнегез! – дип сүгенеп калды.

Талаш-сугыш булмагач, миңа да кызык бетте, соңга калдым дип куркып, тизрәк базарга очтым.

**IV**

Базар кайный. Әллә нинди күз күрмәгән, колак ишетмәгән товарлар белән тулган кибетләрнең алдында, умарта корты кебек, халык шаулый: кысык күзле, түбән карашлы, кара-соры чикмәнле чувашлар; киң маңгайлы, елгыр күзле, ак чикмәнле кара башкортлар; күбесе итекле, картузлы, кыска киемле, зур сары сакаллы, озын мыеклы урыслар; көмеш тәресен ялтыратып йөргән озын кара киемле поплар; ак йөзле, аз сакаллы, кара казакилы, итекле яки читек-кәвешле сәүдәгәр татарлар, – һәммәсе алалар, саталар, алдыйлар, алданалар, үзара гөж киләләр.

Бу кибетләрдән арттарак, озын бер рәт булып, йөкләр – игеннәр, ярмалар тезелеп китә. Баштанаяк онга буялган сатучылар ашыгып-ашыгып үлчиләр; алырга чыгучылар, йөктән-йөккә барып, кабып, учка изеп карап, он эзлиләр.

Икенче башта сатарга китергән атлар, сыерлар, сарыклар, колынлы бияләр бер-берен тибеп, кешнәшеп торалар. Алардан ерак түгел ит кибетләре, симез сарык билдәмәләре белән тулы арбалар күренә; шулардан ерак түгел арбалар, тәгәрмәчләр, юкәләр, камытлар, арканнар, – белмим, тагы niләр тулып яталар.

Боларның һәммәсеннән читтә зурлы-кечкенәле мичкәләр белән арбалар тезелгәннәр; бу кымызчы башкортлар янында, яшел чирәмгә паласлар, киезләр җәеп, табын-табын кешеләр утырганнар, – байлар, муллалар кымыз эчәләр. Йөзләре кызыл, күзләре тонган, – ахрысы, байтак мичкәләрне бушатканнардыр.

Аннан-моннан карап, тиз генә базарны әйләнәм дә кырык тартмачылар янына киләм. Кавырсынны болар җыялар, корыч кармакны да болардан гына табып була.

Бу ни эш тагы?

Мин, авылдан-авылга вак-төяк сатып йөрүче кырык тартмачы Шәрәфи абзый янына килеп, малайларны этә-этә керә башлаган гына идем, арт яктан кемдер:

– Алмадым... валлаһи... алмадым... – дип елап җибәрде; икенче берсе:

– Ялганлама, карак малай!.. Үз күзем белән күрдем... Чылгыйларын күрсәткән булды да ике кармакны эләктерде... – дип сүгенә-сүгенә, берәүне яңакларга тотынды.

Бала-чага, гөж килеп, шаулап, таптап, шул кызыкка таба йөгерештеләр.

Кавырсын да, кармак та хәтердән чыкты, мин дә шул якка ташландым.

Ул арада җыелган малайлар:

– Тот, тот! Юк, ул түгел, Кәрим урлады! – дип шаулашып, икенче якка авыштылар.

Мин шуларның уртасында калдым.

Кармак урлауда гаепләнеп кыйналган малай, елап, әрнеп, минем каршыма килеп чыкты. Аның башында белен кебек изелгән җыртык кәләпүш, өстендә мең ямаулы, буй-буй җыртыклы киндер күлмәктән башка бер нәрсә дә юк. Кап-кара тәненең һәммә җире диярлек күренеп тора.

Үзе буйга минем чамалы – сигез-тугыздан артык булмас. Төсе кап-кара, чәчләре пумала кебек*, күзләре елтырап яналар. Бер кулында кавырсыннар, икенчесендә җепкә тагылган ике кармак күренә.

Теге кеше яңаклаган да яныннан куган. Хәзер инде бу кызыкка бала-чага кушылган.

Ләкин малай бирешергә теләми:

– Алмадым, валлаһи, алмадым, – дип еласа да, әйтерсең, эт оясына килеп чыккан бүре баласы кебек, үзен сырып алган бала-чага белән талаша, килеп кагылсалар, әле бер яклап, әле икенче яклап, кай җирләренә туры килсә, шуннан тырный, суга, тешли.

Ул арада булмады, бу эт көтүе эченә сары башлы, су күзле, әйбәт

* 1936 елгы басмада *пумала кебек* сүзләре урынына *кабарып, бөдрәләнеп тора* сүзләре килә.

киемле, яңа итекле ниндидер бер малай килеп чыкты да:

– Әй, Шаһбаз, эләктеңме? Беркөн безне кыйнаганда шәп идеме? – дип, гаепле малайның өстенә ташланды, бу өмәгә башкалар да дәртләнеп кушылдылар.

Мин дә читтә кала алмадым, шул бәргәләшнең эченә кереп, уңга-сулга яңаклый башладым. Минем йодрыкның иң ныгы әле яңа гына килеп катнашкан чибәр киемле, сары башлы малайга эләккән булырга кирәк: аның күз төбе шешеп чыкты, күп конфет ашаудан черегән тешләреннән кан китте.

Ул арада зурлар катнашып, безне аердылар, кем кыйнады моны дип, тикшерә башладылар. Кавырсыннарымны култык астына кыстырдым да йөгердем.

Әйләнеп карасам, теге гаепле малай Шаһбаз да минем артымнан чаба. Башкалар аңа:

– Уйнаштан туган! Уйнаштан туган! Карак, карак! Гарьлек, гарьлек! – дип кычкырып, таш белән бәрәләр.

Туктап көттем дә үзебезгә алып кайттым. Әнкәй аңа бер бәрәңге, бер сынык икмәк бирде, кем икәнен сорашты.

Ул теге мәрхүм чабатачы Әхми картның үлгән кызының улы икән. Хәзер бөтенләй ятим булып, үзенең ерак бер агасында тора икән. Исеме Шаһбаз икән.

Без аның белән бик тиз дуслаштык. Ул миңа үзенең бер кармагын бирде: корыч кармак, теле очына җитеп тора! Мин аңа ике йомырка бирдем.

Юлда тегеләрнең саклап торулары бик мөмкин иде. Зәңгәр чишмә буйлап, ындыр артларыннан гына мин аны агасына чаклы озаттым.

Алар авылның икенче читендә, безнеке кебек начар бер өйдә яшиләр икән.

**V**

Бу базарда әткәй Гыйрфан байдан бер дисәтинә урак белән ике дисәтинә печән чабарга алган икән. Печән бик җиткән, ди. Бүген кичтән шуны чабарга куна китмәкче була.

Көндезге чәйне эчкәч, чормадан чалгыны алып төшеп карады да, төзәттерәсе җирләре бар, муены бик йомшак, яңа божра кирәк булыр дип, тимерлеккә[5] китмәк булды. Бер барганда эшләре бетсен дип, әнкәй уракларны кертеп бирде: боларны да тешәтергә[6] кирәк икән.

Барысын алдык та кичкә каршы әткәй белән тимерлеккә киттек.

Зур урамга чыккач, миңа бер көтү малай очрады. Мин әткәйдән алгарак киткән идем. Бу көтүнең эчендә теге сары башлы, әйбәт киемле, черек тешле

---

[5] *Тимерлеккә* – тимерче алачыгына.
[6] *Тешәтергә* – үткенләргә.

малай да бар иде. Ул мине күрде дә тиз үк иелеп таш алды, туры минем башка төзәп җибәрде: таш минем колак төбеннән жуылдап үтте. Мин шунда ук тагын юньлерәк бер каты балчык алдым да аңа төзәп аттым. Ул иелеп калды, балчыгым икенче бер малайның маңгаена кунды.

Малайлар эт кебек һаулап миңа ташланганнар иде, мин тиз генә эткәйгә барып сыендым.

– Бер туры килерсең әле... экәңне танытырмын[7] мин сиңа! Уйнаштан туган нәрсә! – дип кычкырып калды теге әйбәт киемле малай.

**VI**

Атсыз гомер итү бик кыен иде. Әйбәт булды, безнең эткәй ат алды: кечкенә генә, ябык кына бер нәрсә, быел гына сабанга кергән, ди. Бу ат өчен без ике дисәтинә урак урып, күпмедер печән чабып, җыеп, кибәнгә салып бирәбез.

Ат булгач, камыты, арбасы җиңел эш инде: эткәй, Ивановка урысларына барып, берничә көн таш кисте дә кечкенә генә, җиңел генә камыт, ыңгырчак, дилбегә, дүрт тәгәрмәч, ике күчәр алып кайтты. Гыйрфан байдан, көз көне ашлык сукканда ике көн эшләрмен дип, тәртә, үрәчә, кабык кебек, башка вак-төяк кирәк-ярагын алып кайтты да җыйнак кына арба ясады.

Шулай итеп, без хәзер атлы-арбалы булдык.

Эткәй әйтә, син дә, ди, бераз эшли башласаң, яңа өй алырбыз да, ди, бу тирес оясыннан авылның уртасына таба, теге балта остасы Зарифлар янына күчәрбез, ди.

Их, тизрәк үсәсе, тизрәк эткәйгә эшләшәсе дә, бу тирес оясыннан шул авыл уртасына, оста Зарифлар тирәсенә күчәсе иде!

Ат булгач, бер йөреп кайтыйм дип, энкәй дә бармакчы иде, Сафа бабайның килене бәбәйләргә тора, шуңа булышырга кеше кирәк дип чакырдылар да, ул калды, без эткәй белән, яңа атны, яңа арбаны җигеп, яланга ашлык карарга киттек. Җирән кашкага ашатырга печән чабып алып кайту өчен чалгы да алдык.

Их, җегет! Нәрсә бит, быел ашлыклар, карасаң, исең китә: шулай әллә кайдан-кая җәелеп, Зәңгәр чишмә кебек үзеннән-үзе дулкынланып утыралар иген басулары!

Безнең ярты җир солы бар. Әйбәт үскән. Инде саргаеп килә.

– Моны сатмабыз, җирән кашкага ашатырбыз, шулай бит, эти!

– Шулай, балам, шулай!

Ун таяк тары чәчкән идек. Утаган ягы бик шәп үскән. Түбән башы

---

[7] *Әкәңне танытырмын* – монда “кирәгеңне бирермен” мәгънәсендә.

бераз чүпле – урыны-урыны белән билчән, каз үләне баскан. Шулай да бер унбиш пот тары чыгар әле:

– Чыгар бит, әткәй?

– Чыгар, балам, чыгар!

Басуны әйләндек, арба тутырып яшел печән төядек тә иң еракка – борчак җирләренә килеп чыктык.

Их, малай, борчагы нәрсә бит! Инде бөтенләй кузакланып беткән – сырга кебек, сабакны сыгып утыралар. Санап карадым: кайбер кузакларда сигезәрдән ике рәт тезелгән. Күрше Сафа бабай әйтә, бер кузакта уналты борчак булса, ул инде бик уңган була, ди.

Озакламас, өлгерер дә инде: урыны-урыны белән әле дә саргая башлаган:

– Шулай бит, әткәй, борчак уңган бит!

Әткәй үзе җир башындагы сарутны, актамырны чабып, арбага тутыра, үзе миңа җавап бирә тора:

– Шулай, балам, шулай! Уңган, бик уңган... Тик исән-сау җыеп алырга насыйб булсын, боз сугып, корт төшеп әрәм итмәсен! – ди.

Чү! Тукта!

Тегендә кемнәр ул безнең борчак эченә кереп ятканнар?

Әткәй нидер кычкырып калды, мин, аңа карамастан, чыбыркыны алдым да бар көчем белән шул безнең борчак эченә кереп яткан малайларга йөгердем.

Ни күрим?

Берсе теге базарда минем белән сугышкан сары башлы, черек тешле, әйбәт киемле малай. Аның белән янәшә тагын берәү яткан – таза, нык, төптән юан үскән, сабыр гына бер ир бала. Өченчесен азрак таныйм. Бу – Гыйрфан бай мәхәлләсенең Заһит хәзрәт улы Фазыйл мәгъзүм бугай: чибәр генә киенгән, озынча йөзле, зур күгелҗем күзле, нечкә кара кашлы, минем чамалы бер малай.

Ачуымнан нәрсә әйтергә белмәдем:

– Ник безнең борчакны урлыйсыз? – дидем дә чыбыркы белән малайларга берәм-берәм селтәнә башладым.

Теге Фазыйл мәгъзүм акыллы күзләре белән миңа текәлеп карады да, ничектер, гаҗәп бер осталык белән чыбыркымны тотып алды, һаман шулай текәлеп карап:

– Солтан, син нигә һаман безгә бәйләнәсең?.. Беркөн тимерлек янында менә Гыйлаҗиның күзен чыгара яздың... Без сиңа тигәнебез юк бит! – диде.

Бу малайның күз карашы йөрәгемә төште, тавышы, акыллы сүзе бөтенләй хәлемне бетерде. Эчтән шулай җиңелсәм дә, тыштан һаман

киреләндем:

– Ник бәйләнмәскә? Нигә Шаһбазны рәнҗетәсез? Нигә безнең борчакны таптап, ашап йөрисез? – дидем.

Фазыйл әллә нинди бер җирәнү белән:

– Харап булган икән! Имеш, борчакны ашыйсыз? Әнә янәшәдә безнең ике дисәтинә борчак ята: бик кирәк булса, төя дә алып кайт! – диде дә капкан борчагын түкереп ташлады.

Безнең талашны әткәй ишеткән, ахрысы.

– Солтан, син нигә алай акылсызланасың?.. Кемнәр икәнен танымыйсыңмыни? Килегез барыгыз да монда! – дип кычкырды.

Бардык.

Фазыйл мәгъзүм атны мактады, сары башлы малай минем өстемнән тел сөйләде:

– Без, ялан карап йөреп, сезнең борчак эченә хәл җыярга утырган идек, улың безгә бәйләнә, – ди.

Әткәй көлде:

– Солтан, син боларны танымыйсыңмыни? Нигә алай сугышып йөрисең? – диде.

Сары башлы, әйбәт киемле малайга карап:

– Бусы Гыйрфан бай улы Гали була, – дип өстәде, аннан соң теге озын, аксыл йөзле, күгелҗем күзле, акыллы Фазыйл мәгъзүмне күрсәтеп: – Бусын танымаска бер дә ярамый, бу – байлар мәхәлләсенең мулласы Заһит хәзрәт улы мәгъзүм Фазыйл... Ә менә бусы, оста Зариф бабаңның төпчеге, – дип, таза, калын сабыр малайга күрсәтте. Аннан соң барыбызны да кочагы белән борчак җиренә таба этәргәләп:

– Йә, барыгыз, юкка сугышып йөрмәгез, саргайганрак җиреннән борчак җыеп китерегез... Мин ут ягып куырырмын, – диде.

Без бергәләп киттек. Бергә борчак җыйдык. Шаяра-шаяра сөйләнеп, талашкалап алдык.

Гали һаман миңа бәйләнә, Шаһбазны сүгә:

– Солтан, – ди, – нәрсә шул уйнаштан туган хәерче малай өчен минем белән сугышып йөрисең? – ди.

Фазыйл мәгъзүм, безнең белән яшьтәш булса да, чыннан зурлар кебек акыллы сөйли. Минем кулдан тота да:

– Йә, Солтан, моннан соң безнең белән сугышмассың бит инде? – ди.

Теге Зариф оста малае Гыйлаҗи дәшмәде – җыйды да җыйды; дуңгыз нәрсә икән, без юкка суган сатып йөргәндә, ул менә дигән кипкәннәрен бер кәләпүш тутырып та өлгергән.

Арба янында төтен күренде, ул арада әткәй дә:

– Җитәр инде, кайтыгыз, – дип кычкырды.

Барсак, без бөтенләй хур булдык. Әткәй көлә:

– Сез, ахрысы, эчегезгә җыйгансыздыр. Менә Гыйлаҗи җегет ичмасам!.. Ул атасына охшаган: күп сөйләнми, эшли дә эшли, – ди.

Борчак тиз куырылды; кәләпүшләргә тутырып алдык та, арбага биек итеп төялгән яшел печән өстенә атланып утырдык.

Кайтыр юл түбән таба иде.

Җирән кашка, яшь булса да, көчле икән: шул чаклы печән белән биш кешене бертуктаусыз йөгертеп алып кайтты.

**VII**

Борчак җирендә бәрелешү – безнең арадагы сугышларның актыгы булды.

Шул көнне, безнең арбага төялешеп кайткач, Зәңгәр чишмәдә бик озак су кердек тә, татулашып, дуслашып таралдык.

Кызу урак өсләре булганга, якын арада күп очрашырга туры килмәде. Тик базар көннәрдә генә бергә-бергә җыелып ала идек. Ул да бик сирәк була иде.

Безне бөтенләй якынлаштырган нәрсә Гыйрфан байның яңа салына торган зур таш кибете булды.

Бездә бу елларда ак таштан кибетләр салу күбәеп бара. Авылда моның остасы берничә генә кеше. Боларның иң шәбе безнең әткәй диләр.

Гыйрфан бай безнең әткәй белән Зарифны чакырткан да:

– Берегез балтачы, берегез ташчы: сез миңа ак таштан кибет салып бирегез, – дигән.

Болар өсләренә алганнар. Тагы берничә балтачы белән ташчыны куштылар да, иген-тару җыелып бетүгә, эшкә тотындылар.

Әткәйгә ияреп, мин һәр көн диярлек бара идем. Зарифның улы Гыйлаҗи – теге калын, таза малайның да килми калган көне сирәк була иде.

Гыйрфан белән Заһит хәзрәтнең йортлары янәшә булганга, Фазыйл белән Гали электән үк бер-берсеннән аерылмыйлар икән. Без дә барып кушылгач, дүрт малай менә дигән бер компания булып алдык.

Шаһбаз шул базардагы сугыштан бирле миңа бик багланып киткән иде. Эш беткәч, ул һәр көн диярлек безгә килә икән. Әнкәй аңа:

– Гыйрфан байларга атасы белән китте. Шунда уйныйдыр, – дигәч, мине көтеп утыра-утыра икән дә боегып кайтып китә икән.

Берничә көн үземә дә очрады.

Көчләп диярлек Галиләргә алып бардым. Ләкин үзебезнең компаниягә тиз генә кушып булмады.

Башка вакытта лачын кебек үткен малай шул Гыйрфан байларның,

Заһит хәзрәтләрнең йортына килеп җитсә, бөтенләй югалып кала: зур капкаларга, яшел түбәле өйләргә карый да, бераз аптырап сүзсез торгач:

– Боларның этләре бик усал бугай... тешләрләр... Мин кайтам... – дип, китә дә бара.

Урамнарда, базарларда, Зәңгәр чишмә буйларында очрап, Галиләр, Фазыйллар, Гыйлаҗилар белән бик күп тапкыр бергә уйнап, җенләнеп, көрәшеп, башка компанияләргә каршы сугышларга катнашып, үзе бик күп баһадирлыклар күрсәткәч кенә Шаһбаз безнең арада үз булып китә алды. Шуннан соң гына ул Гыйрфан байның зур сарайларыннан, таш пулатларыннан курыкмый башлады.

Беркөн шулай Фазыйлларның бакчасында сабан сөреп уйный идек.

Гыйлаҗи сабан арты тоткан, Фазыйл белән мин төпкә, Гали очка җигелгән, Шаһбаз, нәкъ сабанчы малайлар кебек, көйләп-көйләп, «атлар» куа иде.

Намаздан кайтышлый, Заһит хәзрәт бу әйбәт тавышны ишеткән дә бакчаның коймасыннан карап торган. Шул якка таба борылгач, хәзрәтне күрдек тә, оялышыбыздан сабаннарны, камытларны ташлап, шыр килеп качтык.

Хәзрәт ачуланмады.

– Уйнагыз, уйна! – диде.

Фазыйлга карап:

– Менә бу ертык киемле бала кем ул? Көйләп ат куучы шулмы? – дип сорады.

Андый вакытларда безнең Фазыйлның теле телгә йокмый – шундый әйбәт җавап бирә:

– Әтәм[8], бу – ятим бала... Аның ата-анасы юк... бер ерак агасында гына тора... Бик ярлылар... Ул үзе бик үткен, бик уңган малай, – ди.

Хәзрәт, Шаһбазны чакырып, башыннан сыйпады, ике тиен садака бирде. Фазыйлга:

– Әйдә, кер әле өйгә, – диде.

Без яңадан сөрергә керештек. Ике әйләнеп тә җитмәгәнбез, атылып Фазыйл килеп чыкты.

Кулына бераз киелгән, шулай да бик таза күлмәк, бер иске чалбар, бер кәләпүш, бер камзул тоткан. Үзе шат. Ансыз да матур зур күзләре бөтенләй ачылып, нурланып уйныйлар:

– Беләсезме, – ди, – әтәм боларны Шаһбазга бирде. Болар минем үлгән абзамның калган киемнәре... Әтәм әйтә, дога кылсын, – ди...

---

[8] *Әтәм* – әтием.

Шаһбаздан бигрәк без шатландык. Башка вакытта юньләп сүзгә катнашмый торган Гыйлаҗи да кая басканын белми, кул суга, сикерә:

– Вәт нәрсә, малайлар, – ди, – болай гына ярамый, Фазыйл, бар син сабын алып чык, Шаһбазны суга кертәбез, тәнен пычак белән кырып юабыз да, шулай пакьләп, яңа кием кидерәбез, – ди.

Бу фикер бигрәк тә ошады, күз ачып йомганчы сабын да чыкты.

Без, акны-караны күрмәстән, кая басканны белмәстән, Зәңгәр чишмәгә чаптык.

Барыбызга да бәйрәм иде, иге-чиге булмаган шатлык иде.

Килеп җитүгә Шаһбазның мең ямаулы пычрак, ертык күлмәген салдырмыйча ук өстеннән өзгәләп, тарткалап алып бетердек тә: «Һау... әлләлә... һау... әлләлә... әлләлә»... – дип, уратып-уратып суга ыргыттык. Аннан соң, уйнап, кычкырып, аны барыбыз бергә юындырырга керештек.

Шаһбаз үзе бик артык исе китмәгән кебек күренде. Әмма безгә бу көн гаҗәп бер күңелле булды.

Шуннан соң Шаһбаз безнең компаниянең иң ныклы, иң кирәкле кешесе булып җитте.

**VIII**

Без, бер авылда туып, бер суны эчеп үскән булсак та, төрлебез төрле урамнарда, төрле өйләрдә торгангамы, холыкларыбыз, һөнәрләребез бик төрлечә иде.

Фазыйлдан башка безнең компания әллә кайчан таралган булыр иде. Кайбер вакыт юк-бар өчен талашып китәбез. Бәргәләшеп алган чаклар да була. Менә мондый заманнарда Фазыйл әллә кайдан акыл таба, кызык сүз әйтә, яңа уен чыгара да, әле биш минут элек кенә бугазга бугаз килгән малайлар, гөрләшеп, кочакланышып, яңадан уйнарга тотыналар. Талашны, сугышны бөтенләй оныталар.

Мин бөтен компаниягә балык тотуларда, урманга, тауга, җиләккә йөрүләрдә командир булдым. Минсез мондый эшләр башланмый, башласалар да, очлап чыгара алмыйлар.

Зариф карт улы Гыйлаҗи сугыш-талаш вакытларында безне коткара.

Без, үзара бик артык якынаеп киткәч, авыл малайлары өстеннән бөтенләй башлык кебек булдык. Теләсә язгы ат чаптыруларда, теләсә базарларда, теләсә башка уеннарда – без һаман үзебез теләгәнчә алып барабыз. Моңа башкаларның эчләре поша. Безнең дошманнар көннән-көн күбәя. Шуңа күрә атна саен диярлек бәрелешләр була. Менә мондый вакытларда Гыйлаҗи булмаса, без, лачыннан качкан чәүкәләр кебек, таркалабыз да бетәбез... Тик ул гына үзенең курку белмәс йөрәге, таза калын беләкләре белән безнең дошманнарыбызга каршы тора алуыбызга сәбәп була.

Аның өстенә тагы, Гыйлаҗи бөтен авыл малайлары эчендә бердәнбер балта остасы санала. Яз килсә, ул безгә менә дигән көймәләр ясап бирә. Кошлар килеп җиткәндә, безнең һәркаюыбызның кечкенә өй кебек матур, җыйнак итеп ясалган сыерчык ояларыбыз әзерләнеп, биек киртәләр башына утыртып куелган була. Боларны да ул ясый.

Җиләк җитсә, кечкенә-кечкенә тубаллар, көз керсә, авылның бер башыннан икенче башына ишеттерерлек яңгыратып суга торган биек, текә какмалар – болар һәммәсе шул атасына охшап туган Гыйлаҗи кулыннан ясалып килә.

Галине әйтәсе дә юк. Нәрсә ясарга агачмы, нечкә тактамы, калайлармы, кадакларммы – һәммәсен Гали ташый. Акча дигәнең аларда өзелми. Конфетлар, клиндрләр, прәннекләр белән аның үзенең тешләре череп беткән. Без дә болардан ара-тирә авыз итәргә кире тормыйбыз.

Шаһбаз иң соң килеп кушылса да, ул тиз арада безнең компаниянең үзәге булып алды.

Бер жиргә уенга барасымы, җиләккә, балыкка бару өчен җыярга кирәкме, яки берәребезне кыйный башлаганнармы – янында Шаһбаз булса, бер дә аптырамыйсың! Ул, ике бармагын тешләренә куеп, берничә сызгырып җибәрә икән, безнекеләр хәзер сизеп алалар да, кайда, нинди эштә булса да, чабып килеп җитәләр. Әйтерсең, әкияттәге җеннәр инде! Бу сызгыруда авылда гына түгел, тирә-якта да аның тиңдәше юк диләр. Ул әллә ничә төрле сызгыра. Без инде аның сызгыруыннан нәрсә әйтергә теләгәнен тел белән сөйләп биргән, сүз белән кычкырган кебек аңлыйбыз...

Сугыш вакытларында да аның кирәк чаклары була.

Ул көчле түгел, ләкин бик үткен, бик хәйләле: кайбер вакытларда һич көтелмәгән җирдән килеп, ничәсен бәреп ега да, дошманнар хур булып качалар.

Йөгерүдә, суда йөзүдә дә аңа чыккан кеше юк.

Җырлауга, моңлануга, көлке сүз әйтеп башкаларны мыскыл итәргә туры килсә, ул инде дошманнарга гына түгел, безнең үз йөрәкләребезгә дә еш-еш агулы укларын кадый.

**IX**

Шулай үсәбез...

Әйтерлек зур алмашынулар булганы юк.

Тик Шаһбаз гына бер дә көтелмәгән эш эшләп ташлады.

Бер көнне аның маңгае ярылып килде. Бәйләмәгән-нитмәгән, тик аз гына тоз сипкән – шулай ярасы канланып күренеп тора.

– Сиңа ни булды? Кем кыйнады? – дибез.

Башта дәшмәде, бик кыстагач, сөйләп бирде.

Ул бит ерак бер агасында тора. Шуның хатыны бик усал икән. Әрәм тамак син, юкка ашап ятасың дип, һаман әрли, талый икән. Үз балаларына ашарга биргәндә, моны өлешсез калдыра икән. Бер көнне шулай кечкенә бәлешләр пешергән дә ике баласына икене тоттырган. Зур улы, анасы чыгып киткәнне генә карап торган да, үзенең өлешеннән яртысын Шаһбазга бүлеп биргән. Кечкенә кыз бала, йөгереп, анасына әләкләгән: «Шаһбаз сорап, алдап алды», – дигән.

Хатын кызып, җенләнеп керә дә: «Бәхетеңне ашаган нәрсә! Үз бәхетеңне ашавың җитмәгән, инде минем балаларым ризыгына тотынгансың икән!» – дип каһәрләп, мич буендагы кайчыны алып, Шаһбаз башына бәрә. Ятимнең маңгае ярыла.

Безнең өчен бу бик зур эш булды. Гали белән Фазыйл өйләреннән ак күмәч кисәкләре, бәлеш калдыклары чыгарып бирделәр. Гыйлаҗи белән без, тиз генә су китереп, юдык – яраның эчен карадык: зарарлы түгел, сөяккә тимәгән кебек. Чүпрәкләр таптык та үзебезчә бәйләп куйдык.

Фазыйл атасы янына кереп чыкты да:

– Вәт нәрсә, Шаһбаз, – диде, – ул җиңгәң барыбер көн күрсәтмәс, син бездә кал!

Шаһбаз аңа туры карады:

– Мин сездә ни эшләп торырмын?

Фазыйл:

– Әтәм әйтә, тамагы тук булыр, өс-башына бирербез, өйдә хатын-кыз йомышына йөрер, ди, ялчылар белән ат карашыр, ди.

Шаһбаз дәшмәде. Ләкин яңадан теге йортка кайтмаган – Фазыйлда торып калган.

Без моңа бик шатланган идек, Шаһбаз үзе дә күңелле кебек күренә иде.

Ләкин болар озакка бармады.

Фазыйлларның бер асравы күп савыт-саба күтәреп бара икән – аягы тайган да, егылып, бөтен нәрсәсен ваткан. Остазбикә:

– Ничәмә йөз тәңкәлек әйберемне әрәм иттең! Теләсәң каян тап, түлә, – дип кычкырына башлагач, асрау, үзен аклар өчен, Шаһбаз өстенә нахак сүз сөйләгән:

– Мин кереп килә идем... менә бу уйнаштан туган малаегыз әллә кайдан йөгереп каршыма чыкты да миңа бәрелде... Мин шуннан егылдым... – дигән.

Заһит хәзрәтнең остазбикәсе Шаһбазны чакырып ала да:

– Ятим бозау асрасаң, авызың-борының май итәр, ятим бала асрасаң, авызың-борының кан итәр, дигән борынгылар... Синнән хәер булмас, күземә күренмә, бар, бүгеннән чыгып кит! – дип, аяк тибеп тиргәп куа.

«Гаепле» бала дәшми-тынмый, чыга да югала. Кая киткәндер? Һичкем

белми – һәммә кеше аптырап кала.

Теге агасы Заһит хәзрәткә килеп җитә:

– Яхшы атлы булган булып, асрарга алган идең, ... бер айга да түзми, кыйнап чыгардың... Тап! Тапмасаң, өстеңнән кәгазь бирәм, – ди.

Без, төрле җиргә таралып эзләргә тотындык.

Әллә кемнәр: «Шул көнне караңгы төшәр алдыннан Зәңгәр чишмә буенда йөри иде, үзен-үзе суга ташламагай иде», – дип кайгырышкан булалар.

Мина бу бик каты әсәр итте. Никтер, эчтән моңа ышана яздым. Аның шундый бер эшне эшләп ташлавы бик мөмкин кебек тоелды.

Халык Зәңгәр чишмәдән су алырга тартына башладылар.

Бер атна үткәч, хәбәр килде:

Шаһбаз Заһит хәзрәтнең остазбикәсе куып чыгарган көнне бу авылдан киткән дә, Ивановкага барып, татарча белә торган карт чувашка дуңгыз көтәргә ялланган. Әле дә шунда, ди.

Мин аптырый калдым. Гыйлаҗи дәшмәде. Гали, бер дә исе китмәгән кеше кебек, көлә генә:

– Нәрсәгә ул чаклы хәйран каласыз, – ди. – Чабатачы Әхми баласының көтүче булып китүендә нинди гаҗәп эш бар, – ди.

Тик Фазыйл гына мине бераз тынычландырды:

– Курыкма, Солтан! Шаһбазга бернәрсә дә булмас, – ди. – Үзен-үзе югалта торган җегет түгел ул, ди. Кулдан-кулга күчеп, хатын-кыздан кыйналып, тиргәлеп гомер иткәнче, анда үз көнен үзе күрер, – ди.

Һәм шулай булды.

Шул көннән соң Шаһбаз, үзе сөйләшеп ялланып, көн күрә башлый. Үз ирке белән ялланучы ялчы булып китә.

Бу вакыт ул да, без барыбыз да ундүртенче яшькә чыккан гына идек.

**X**

Шаһбаздан соң башкалар да берәм-берәм тарала башладылар.

Фазыйл мәгъзүм Казанга китә. Ул урысча да, мөселманча да укый, ди. Аны мактап сөйлиләр. Галим булыр, зур кеше булыр, Зәңгәр чишмә буен яктыртыр, диләр.

Җитмәсә тагы, Гали дә кышларда әллә кайларга китеп югала торган булды. Ул да укый, ди. Сату-алуга өйрәтә торган гыйлемлекләр артыннан йөри имеш, ди.

Гыйлаҗи моны ишеткәч көлә:

– Анысы юк эш инде, – ди, – Акчаң булса, сату-алу эшен укымыйча да бик шәп йөртә белер идем әле, – ди.

Нәрсә сөйләп торырга?! Гали укыр өчен түгел, байлыкка, симезлеккә

чыдаша алмаганнан гына йөри инде!

Моңарчы һичкая кузгалмаган Гыйлаҗи да аякланды.

Быел яңгыр аз яуды. Игендә өмет зур түгел. Авылның байтак җегетләре, эш бетәр-бетмәс, читкә, кәсеп эзләп чыгып киттеләр. Безнең иптәш тә:

– Бер бәхет эзләп кайтыйм әле! – дип, шуларга иярде.

Зәңгәр чишмә буенда мин ялгызак калдым.

**XI**

Көзләрдә, кышларда иптәшләр шулай таралгаласалар да, яз кайталар. Җәйне бергә үткәрәбез.

Йөргән таш шомара, мин монда күгәреп ятам.

Кичә көтмәгәнрәк вакытта Гыйлаҗи кайтып төште дә безне җыйды. Йөрүе бөтенләй бушка булмаганга охшый: аякта итек, өстә кара чикмән, кулда күн бияләй, башта яңа кырма бүрек. Үзе дә үскән, нык тазарган. Аз гына мыек та чыгарга чамалый бугай. Өйдәгеләрен онытмаган: сеңлесе Гайниягә ике тәңкә ярымлык шәл, атасына бер читек, әнкәсенә күлмәклек алган.

– Сезне дә онытмадым, – ди. – Менә сезгә алтын шахтасы янында ясалганнан бер кызылбаш! – дип, атасы чыгып киткәч тә, безнең алга бер бөтенне утыртып куйды. – Бүген сезне сыйларга чакырдым, – ди.

Мин бераз оялдым – Фазыйл безнең яшьтәш, бала чактагы иптәш булса да, хәзер ул гыйлем кеше бит; аның алдында болай кылану килешеп бетәрме икән?

Гали – эт нәрсә берүк; моны күрүгә чаршау артына чыкты да Гыйлаҗиның әнкәсе белән нидер пыш-пыш сөйләшеп алды.

Күп вакыт үтмәде, тегеннән, чаршау астыннан, Гайниякәйнең ак кулы безгә зур бер тәлинкә белән әйбәтләп киселгән икмәк, әрчеп туралган суган, байтак ук салкын ит сузды.

Без тәрәзә пәрдәләрен төшердек, кеше килә башласа, безгә алдан хәбәр итегез дип, Гайния белән җиңгине ишек алдынамы, бакчагамы чыгардык та акрын гына эчә башладык.

Башта Гыйлаҗи сөйләде.

Ул Уралда агалы-энеле бергә эш йөртә торган ике мөселман миллионерның алтын шахтасында эшләгән икән. Гаҗәп авыр чаклар була, ди. Кайбер вакыт кое кебек тар, тирән шахталарга төшеп, муеннан суда эшлисең, ди. Шундый бер коеда азапланган чагымда, ди, арканга тагып югары мендергән чиләгемнең җебе өзелде дә эчендәге комы, ташы, зур балтасы – белән минем өстемә түбәнгә очты, ди. Әллә әткәй-әнкәйнең догасыдыр, башымны бер якка борып өлгердем, юкса, ди, шул җәһәннәм базында җан

биргән идем, ди.

Фазыйл иптәш бездән калышмый эчә, шулай да акылын җуймый, һаман сораша тора:

– Соң ничек, – ди, – син инде күпләрендә эшләдең, үзебезнең мөселманда җиңелрәк түгелме? – ди.

Гыйлаҗи, аз гына да көлмичә, җавап бирде:

– Җиңелрәк, әлбәттә җиңелрәк!..

– Ничек ул алай?

– Менә ничек: шахтаның иясе мөселман булса, синең йөрәгеңә сул яктан очлы шүрене турыдан-туры тыга да каныңны эчә башлый. Эчә, эчә... Бервакыт синең йөзең агара, хәлең бетеп егыла башлыйсың. Шуннан соң ул сине кызгана да каныңны эчүдән туктый... Ә урыс алай итми: ул шүрене йә уң яктан, йә кабыргадан тыгып азаплый... Менә ике арада аерма шулай, – ди.

Фазыйл бераз уйланды:

– Син юкны сөйлисең, Гыйлаҗи. Үзең бит агармагансың да, хәлең дә бетмәгән, – ди.

– Агарырлык эшләргә вакытым булмады. Шүрене тыгып, бер-ике суыргач та качтым мин.

Сүз икенчегә күчте.

Безнең Шаһбаз элекке елларда шахталарда йөрештерсә дә, быел кыш Семберме, кайсы бер губернададыр, постау[9] фабрикаларында эшләгән. Ул шунда үзләренен хуҗасы Нигъмәт хаҗи дигән бер миллионер картны сөйләп эчебезне катырды:

– Безнең янга килә дә, – ди, – кабыргага төртеп, ну, Шаһбазкай, минем марҗалар әйбәтме? Төндә үзләре янында кундыралармы сине? дип, юк-барны сөйләп йөри, – ди.

Бу байны Гали дә белә икән. Калада әллә нинди бер мәҗлестә күргән икән. Шундагы кызыкларын сөйләп, бик озак көлдерде.

Ул арада кемдер ишек шакылдатты. Мин курка калдым. Берәр чит кешеме дип торам, Гали сикереп торды да, каршы чыгып, тиз генә кире керде! Кулында тагы бер бөтен кызылбаш.

– Күрәсезме, – ди, – моны?

– Бүген кич монда җыелачакны белгәч, мин берәүнең колагына салып куйган идем. Җегет нәрсә икән, китереп тә җиткерде, – ди.

Фазыйл бераз йөз чытты:

– Җегетләр, күбрәк булмасын, – ди.

Шаһбаз көлеп куйды:

---

[9] *Постау* – уң ягы киезсыман тукыма.

– Их, Фазыйл туган, – ди, – күп булмый ул! – ди.

Тагын эчү башланды. Яратышу китте, үбешү, кочаклашу китте. Минем күңел бик риза түгел, шулай да утырам.

Шаһбаз иртәгә юлга чыга икән. Матур, моңлы тавыш белән акрын гына көйләп куя:

Сандугачлар килгән безгә,
Китмәсләр микән көзгә?
Язгы сабан туйларына
Кайтырбыз микән без дә?

Гали нык исергән. Гәүдәсен тота алмый, күзе тонган. Әле берәүгә, әле икенчегә килә дә карлыккан тавыш белән:

– Бу нәрсә?.. Бу эчүмени?.. Әйдәгез, калага китәбез: минем тройка әзер... ике сәгатьтә барып җитәбез... Коньяк... шампанский... бары да миннән булыр! – ди.

Фазыйл аны кочаклап үз тезенә утырта да куркыта башлый:

– Син, – ди, – артык исердең!.. Болай булса, йә син чыгып кит... йә мин китәм... – ди.

Гали сикереп тора да, авызындагы күбекләрен чәчеп, Фазыйлны кочаклап үбәргә азаплана...

– Юк... юк, – ди, – син китмә... Син киткәч... дөньяның яме бетә, күрке бетә... Син... син безнең кояш бит, Фазыйл туган! Эчмә дисәң, эчмим... бетте... сүзем юк... Сорамыйм... Шулай да бер генә, миңа шундый нәни генә, чокыр эчәргә рөхсәт бир инде!.. – ди. Үзе хахылдап көлә.

Аңа аракы дип су эчерәләр. Аннан соң бер чынаяк бик каты чәй бирәләр дә, Гыйлаҗи аны тышка, һавага алып чыгып керә.

Һәммәсе бераз айныйлар.

Гали бераз тәртип белән тагы сүз башлый:

– Мин, – ди, – җегетләр, укыйм әле... Сәүдә гыйлеме укыйм... Урысны, жидны гына түгел, немецне җиңәрлек булганчы укыйм...

Фазыйл аның сүзен бүлә:

– Укып беткәч, ни эшлисең?

– Аннан соңмы?.. Аннан соң сау бул, Зәңгәр чишмә! Сез дә миңа зур шәһәрләрнең берсенә бергәләп кунакка рәхим итәсез... Каланың уртасында, иң зур урамда, минем йорт булыр... Байлык әле дә бар... Эш башларга шул җитәр, тик һиммәт кенә кирәк... Атайдан мал, миннән гыйлем белән һиммәт[10]! Калага күчәм... Матур сарайлар салдырам... Хатынның миңа дигәнен сайлыйм. Җәннәт кебек бакчаларым була. Каланың барлык түрәсе,

---

[10] *Һиммәт* – тырышлык.

иң зурлары да миндә эчәләр, миннән бурыч алалар, миңа еректан кул кушырып торалар... Менә минем план шулай, җегетләр!.. Ну, сөйлә, Гыйлаҗи: синең исәп ничек? Минем белән калага күчәсеңме?.. Күчсәң, акча бирәм, подрятчик булып, зур йортлар салдырып йөрерсең!

Гыйлаҗи тутырып бер чокырны эчә дә кызмача сөйләнә:

– Минме? Гали туган, – ди, – мин, ди, ачка үлсәм үләрмен, Зәңгәр чишмә буйларын бөтенләйгә ташлый алмам, – ди. – Зәңгәр чишмә тирә-якта бер генә! Әнә тәрәзәдән кара: ул ничек ай яктысында дулкынланып ята... Диңгезмени!.. Иңе кайдан кая җәелгән... Юк, туган... Мин моны ташламам, патшага хезмәт итеп кайтам да, бил баглап, җиң сызганып, изүне чишеп, эшкә тотынам... Минем атай, – ди, – гомер буена балта остасы булса да, кулга алырлык коралы юк... Минеке алай булмас... Мин балтаны корычтан эшләтәм. Ул, агачны гына түгел, каты ташны да кыеп төшерер. Минем пычкыларым, өтергеләрем, ышкыларым кул тидерү белән үзләре йөреп торырлар... Мин, Сафи карт кебек, күземне кыйшайтып, башымны бөгеп, төзләп маташмам... Минем үлчәүләр ике бүрәнә арасына ялгыш кысылган яфракны да сизәрләр. Беләсеңме?.. Хатыным үземнән дә уңган булыр. Бу урамны ташлыйм. Сезнең янга күчәм... Йортлар нараттан була... Атны икедән артык асрамыйм. Болар кырык потны Зәңгәр чишмә белән кала арасында «әһ» тә дими йөртәләр. Арбалар бар да тимерле... Камытлар һәммәсе каештан... Өй буенда бакча: анда җимешләр пешә... Ындырда бәрәңге бакчасы, анда кыяр, карбыз, кавын, торма, чөгендер, кишер, кәбестә – җаныңа ни кирәк, һәммәсе бар... Дөньяны шулай корып бетәм дә, сезнең дүртегезне бер вакытта хатыннарыгыз белән парлап кунакка чакырам... Елга ике мәртәбә: берсе – чана юлы төшкәч тә, авылда казлар, сугымнар суйган, кыз биргән, туй уздырган чорларда... Икенчесе – җәй көне, печәнгә төшәр алдыннан, яшь тәкәләр өлгергәч, авылда кыз озату, килен төшерү көннәрендә... Бал-май үземдә күп була... Башкорттан мичкәләп кымыз алдырам... Карт-коры, мулла-мунтагай күрмәгән арада төшергәләү өчен чиреге белән менә бу кызылбашларны китертеп куям... Ярыймы шулай булса?..

Гали бу озын сүз вакытында нәрсә уйлаптыр катып торды. Фазыйл көлеп куйды:

– Гыйлаҗи, синдә дә шул хыял белән алдагы дөньяны ясап кую бар икән!.. Ну, берәрне эчәбез дә таралабыз...

Мин дәшмәдем. Ләкин башка кешеләрнең уйлары барып чыкмаса да, Гыйлаҗи үзенекенә ирешер кебек тоелды. Аның эш сөяр йөрәге, оста кулы, нык, таза гәүдәсе – бу эшләрне аңа бик җиңел, бик якын күрсәтәләр...

Галинең бер начар гадәте бар: эчте исә, Шаһбазга бәйләнә башлый. Әле

дә тик торганда аңа чәнчеп сүз кузгатты:

– Ну, батыр, – ди, – син ник бер дә сөйләмисең? Син нинди тормыш корырга уйлыйсың? – ди.

Шаһбазның маңгай тиреләре җыерылды. Каш өстендәге ярасы тирәнәя төшкән кебек булды. Мин бераз шөбһәгә баттым: тагы, дим, сугыш чыгармасалар ярар иде, дим.

Гали, үч иткән кебек, янә килеп бәйләнә:

– Ну, батыр, ник дәшмисең? Әллә телең юкмы? – ди. – Булмаса, синең кем булачагыңны үзем әйтеп бирим, – ди.

Гыйлаҗи да моңа кушыла:

– Ник җавап бирмисең, Шаһбаз? – ди. – Әйдә, бер дә кайгырма, башка юл тапмасаң, минем белән балта эшенә китәрсең: алырбыз шәп кораллар, җыярбыз үзебез кебек таза beләкле җегетләрне, барыбыз бергә китәрбез ерак илләргә – салырбыз зур күперләр, салырбыз башы болытларга тигән зур сарайлар! – ди.

Шаһбаз тагы ныграк карала, теш арасыннан гына:

– Рәхмәт, ул эшкә минем кулым бармый, – ди.

Гали тагын бәйләнә:

– Нәрсәгә, – ди, – юкка баш ватасыз. Мин үзем әйтеп бирим аның кем булачагын: безнең Шаһбаз әфәнде оек-чабата кияр, артына капчык асар, кулына озын чыбыркы тотар да көтү көтәргә китәр, – ди.

Фазыйл сикереп торды, ул ачулы иде:

– Нәрсә син, Гали, ул чаклы кабарынасың? Кеше уен сөйли, син хәзер талаш чыгарасың!

Гали, черек тешләрен ыржайтып, көлә:

– Юк, Фазыйл әфәнде, мин талаш чыгармыйм, мин тик әйтәм генә, чабатачы Әхминең баласы көтүче булмый кая барсын дип әйтәм... – ди.

Ул сүзен бетермәде, Шаһбаз, бөтенләй тимергә әйләнеп, көеп, сикереп торды да:

– Дөньяда минем өлешем дә бардыр әле: Гыйрфан бай бөтен дөньяның нигъмәтен үзенә җыеп бетә алмагандыр, – дип, артык кабахәт сүз белән сүгенеп, Галинең яңагына шундый салып җибәрде, җегет урындыклар, эскәмияләр аша мич буена барып төште.

Шаһбаз, һичкемгә һичбер сүз әйтмәстән, чыгып ук китте. Гали, сикереп торып, акыра башлады:

– Бу хулиганлык! Мин хәзер үрәтникне, земскийны чакыртам. Ул уйнаштан туганны Себердә черетәм, – ди.

Фазыйл аны туктатты:

– Шаулый торган булма! Син үзең гаепле! Нигә аны юкка рәнҗетергә?

Гали бераз тынычланды. «Мин аңа танытырмын әле!» – дип сөйләнә-сөйләнә, шешкән яңагын, каралып чыкмасын өчен, салкын су белән, бакыр акча белән уарга кереште.

Гали калды. Без Фазыйл белән чыгып киттек.

Мин аны өйләренә чаклы озаттым да Зәңгәр чишмә буена, күпер башындагы читән өйгә кайттым. Вакыт соң иде.

Бөтен авыл тыныч, рәхәт йокыда. Минем ятасым килми.

Капка баганасына сөялдем дә йөзем белән Зәңгәр чишмәгә әйләндем.

Әйтерсең, гомеремдә беренче мәртәбә күрәм мин бу күлне!

Моны юкка күл диләр. Бу бит диңгез. Диңгезнең дә матуры, зуры!

Зиһенем еракка китте.

Һәркем бер нәрсә турында уйлый. Киләчәккә зур уйлар йөртә. Мин әле һаман шул күпер башыннан, тиреслектәге читән өйдән дә чыга алмыйм.

**XII**

Ятсам да йоклый алмадым.

Таңнан торып, Зәңгәр чишмәдән су китердем, арыш көлтәсе тападым, чоланнан көрпә алып чыктым да улак тутырып җирән кашкага бутап бирдем.

Әле өйдәгеләр тормаганнар.

Минем башымда һаман бер уй. Атай картаеп бара. Гомере шул тирес башында үтә. Мин инде җиткән җегет булдым, менә берничә елдан патша хезмәтенә чакырырлар. Өч ел анда үтәр. Ул вакытта тагы ялгыз калалар. Тагы йорт-җир төзәтеп йөри алмаслар.

Юк, болай ярамый!

Бу эшләр миңа оят: мин хәзер атайдан шәбрәк таш кисәм, башкаларга селкенмәгән авыр ташлар минем кулда уйнап йөриләр. Җегетләр арасында сугыш-ни булса, минем беләкләргә чыдаучылар сирәк чыга.

Юк, болай ярамый! Хәзергә үз көннәрен үзләре күрерләр. Мин китәм, бүген үк китәм дә, алты почмаклы өй, кечерәк бер келәт алып, шуларны Зариф осталар янына күчерергә җитәрлек акча табып кайтам, һәр ел бездә заводларга, шахталарга өчәр-дүртәр йөз минем кебек җегетләр китәләр. Акча табалар, өс-баш ясыйлар, йорт-җир төзәтәләр. Чәчәргә җирең җитмәгәч, чабарга тугаең булмагач, өстеңә капланырга торган урманнан бер чыбыркы сабы да ала алмагач, нәрсә дип монда гомер буенча Зәңгәр чишмәне саклап ятасың!

Иртәнге чәйгә утыргач, шул турыда сүз ачтым:

– Әткәй, – мин әйтәм, – алты почмаклы өй белән кечкенә бер келәт алып, шуларны теге Зариф осталар янына күчереп салу өчен күпме акча кирәк булыр? – дим.

Әткәй дә, әнкәй дә миңа аптырап карадылар. Әткәй бераз елмая:

– Нәрсә син, Солтан, берьюлы зурдан күтәрәсең? – ди. – Әле бу елга бүрәнәсен генә алып куярга көч җитсә дә ару булыр иде! – ди.

Мин кырт кистем:

– Юк, – мин әйтәм, – эткәй, син ачык әйт: мин дигәнчә эшләгәндә күпме акча кирәк булыр? – дим.

Карт бераз уйланды:

– Йөз тәңкәсе табылса, эш башларга ярар иде, – ди. Мин дога кылып тордым да киенергә тотындым:

– Сез, – мин әйтәм, – миңа фатиха бирегез, мин бүген үк чыгып китәм. Иң күбе миңа бер ел вакыт бирәсез, мин сезгә, санап, алтын белән ике йөз сумны менә шул икмәк янына китереп куярмын, – дим.

Әнкәй куркып калды, йөзләре агарды, яшьле күзләре белән миңа кадалды:

– Чү, балакаем, ник ул чаклы ашыктың соң? – ди. Мин ике сүзгә урын калдырмаслык итеп әйтәм:

– Миңа фатиха бирегез, мин бүген үк китәм... Бер ел дип әйткәнем – иң күп куеп әйтүем. Күңелем сизә, мин алты-җиде айда кайтырмын... Хәзер сентябрь икән, язгы сабанга улыгыз сезнең каршыгызда булыр, – дим. – Эткәй, син берәр алты почмаклы өй белән кечкенә келәткә күз сала йөр... Теге Зариф оста янындагы буш урынны берәрсе эләктермәсен... Старостаны майлаштыра тор: мин аның белән былтыр сөйләшкән идем... «Ярар, бер тутырган тавык белән бер бөтен кызылбашны кызганмасаң, урын синеке булыр», дигән иде, – дим.

Эткәй миңа туры карады, аның күзләрендә: «Бу бала акылдан шашмыймы?» – дигән бер сорау бар иде:

– Солтан, син чынлап ук бүген китәсеңме? – ди.

– Китәм, эткәй, китәм. Сезне бу тирес башында үтерәсем килми. Үземә дә, типсә таш ярырдай җегет булып, – бу чүплектә сасып яту хурлык! – дим.

Риза булдылар. Ләкин икесендә дә ниндидер бер эчке өмет катнаш курку сизелә иде.

Былтыр «Восьмой прииска» дигән шахтага[1+] авылдан өч йөз җегет киткән вакытта мин дә дәртләнеп куйган идем. Шул вакыт алынган еллык билетым да сандык төбендә яткан икән. Әнкәй ашыгып күлмәкләремне юды, ямады, кечкенә капчык ясады, өй башыннан бер пар яңа чабата алып төште, миңа юлга дип, азрак ит, азрак бәрәңге пешерде. Шуларның шулпасын ашадык, чәй эчтек. Киендем. Утырып дога кылдык, исәнләштек. Зәңгәр чишмәнең төрле мәчетләренең матур биек буяулы манараларында мәзиннәр төрле тавыш белән өйлә намазына азан әйтә калдылар. Мин, кечкенә капчыкны аркага асып, ялгызым Урал тауларына карап сәфәргә чыктым.

**XIII**

Бездән унбиш чакрымда Мәргәнташ дигән биек бер тау бар. Моның башыннан чишмә чыга. Бер кабер дә бар. Башкортлар Салават каһарманның[2+] якын дусларыннан Мәргән шунда күмелгән, шуңа каратып исем бирелгән дип сөйлиләр.

Шахталарга бара торган юл менә шуның итәгеннән үтә.

Өйдән чыккан кызу белән бу тауга җиткәнче туктамадым, артка әйләнеп тә карамастан, һаман бардым да бардым. Бераз ял итим, тәмәке тартып алыйм дип, калкурак бер ташка утырсам, тирә-яктагы күренешкә хәйран калдым.

Зәңгәр күл диңгез кебек җәелеп ята. Әйтерсең, экияттәге сихерле көзге инде. Көзге кояш яктысында шулай матур булып, җанлы булып нур эчендә уйный.

Күлнең кыйбла ягында утырган безнең авыл да үзенең яшел түбәле сарайлары, биек манаралары, бакчалары белән кечерәк бер шәһәрдән ким түгел икән. Шул сарайлардан бераз китсәң, Зариф осталар урамы күренә. Болар да чибәр йортлар. Аннан соң вак, кечкенә балчык читән өйләр, бер-бер артлы тезелеп, буталып, авылның читендәге тиреслекләргә барып чыгалар. Әнә бер якта Шаһбазның агасының балчык куышы... Менә бу яклап, күпер башында, бер өем чүп кебек безнең читән. Авылның тирә-ягын менә шулар йөзәрләп, меңәрләп чолгап алганнар... Болай караганым юк иде, читтән торып карасаң, безнең авыл зур, бик зур бер чүплек икән, байлар тирәсе шул зур тирес мәйданының уртасына чыккан бер-ике чәчәк кенә икән.

Агыйдел әллә кайлардан уралып-уралып, безнең шул җирләргә кагылып-кагылып үтә икән!

Юк, болай ярамас, таш яусын, дөнья җимерелсен, мин язгы сабанга чикле ике йөз сум акча табам да шул чүплектән уртагарак күчәм. Бу турыда ике сүз булырга ярамый!

Озак уйлап, тәмәкене тартып бетердем дә янчыгын, кәгазен – барын берьюлы түбәнгә ташладым:

– Бу авылга кире әйләнеп кайтканчы минем актык тартуым булыр, – дим.

Шул җиде-сигез айга үземә сүз бирәм: тәмәкене ташлыйм, аракы эчмим, хатын-кызга якын бармыйм... карта уйнамыйм... Шулай итеп, ике йөзне җыям! Мәргәннең кабер ташы моңа гуаһ[11] булсын!

Шулай дип үземә-үзем ант иттем дә Салават баһадирның мәрхүм юлдашының башы очыннан тагы алга – Уралның эченә таба кереп киттем.

---

[11] *Гуаһ* – шаһит, танык.

**XIV**

Алты ай эшләдем. Җиденчегә киткәндә минем эчке күлмәгемнең култык астында кечкенә бөти кебек әйбәтләп тегелгән йөзәр сумлык ике кәгазь һәрвакыт тәнемне кытыклап рәхәтләндерәләр иде.

Моның өченниләр генә күрмәдем, кайларда гына булмадым.

Башта Рәмиевләрнең[3+] «Восьмой» дигәннәрендә эшләдем. Хезмәт каты, хак начар, эш вакыты хәлләреңне бетереп аяктан егарлык озын иде. Түздем. Дөньяның рәтенә бераз төшеним, башка җирдән табышлы кәсеп эзләргә җитәрлек акча ясыйм дип түздем.

Аннан соң, болардан китеп, бер француз компаниясенең шахтасына ялландым.

Таулар биек, агачлар матур, заводлар һәммәсе төрле тау араларыннан төшкән елгаларның тамагында буып ясалган зур матур күлләр тирәсендә утырганнар. Кая барсаң да бер хәл: кая барсаң да каты эшлиләр, кая барсаң да безнең кебек җирсез иленнән, авыр тормышыннан зар булып чыгып киткән меңәр-меңәр татар, урыс җегетләре очрыйлар; эшлиләр, эчәләр, сугышалар, тагын эшли, тагын эчәләр...

Сүземдә тордым. Тартмадым, эчмәдем, картага якын бармадым. Болары артык кыен да булмады. Әмма... әмма хатыннар дигәннәре, ай-һай, ай-һай, бик, бик мөшкил хәлгә куйгаладылар.

Мин таза җегет: буй озын, күкрәк киң, кулбашлар үзеннән-үзе биеп тора, беләкләрем – бер селтәгәндә биш җегетне егарлык!

Балга чебеннәр нинди генә чаралар белән ябырылмыйлар, тук, таза, рәхәт көн иткән яшь хатыннар, җитү кызлар да, мондый җегетләрне кулга төшерү өчен, нинди генә хәйләләр кормыйлар!

Юк, алар адәм дә, фирештә дә, шәйтан да түгел – алар җыланнар, тыштан матур, эчтән агулы җыланнар...

Әткәй-әнкәй алдында биргән вәгъдәм өчен, Салават баһадирның Мәргәне каберендә эчкән антым өчен мин бу җыланнарга очрамаска, боларның агуы белән зәһәрләнмәскә тырыштым.

Әмма, әмма булдыра алмадым.

**XV**

Шахтадан-шахтага йөри торгач, ахыр барып, актык утыз тәңкәмне тутыру өчен, урыс-татар байларының уртак бер компаниясенә хезмәткә ялланган идем. Инде яз да керә иде, хак зур булмаса да, ашаудан кысып, көненә унбишәр сәгать эшләп, айга егерме биш сумнар калдырырлык чама бар иде. Безнең яклардан, Казан, Сембер, Саратау[12] губерналарыннан килгән

---

[12] *Саратау* – Саратов.

бик күп татар җегетләре дә эшлиләр иде. Бергә-бергә күңелле үтә иде. Алар башта мине эчмәгән, тартмаган, карта уйнамаган өчен, бигрәк тә – хатын-кызга карамаган өчен «ишан» дип мыскыл итәләр иде. Гомер буенча шахтада эшләп, хәзер инде шунда бала-чагалары булган бер Казан карты вакыт-вакыт әрнеп сөйләнеп куя иде:

– Әй, Солтан туган, ди, аңлыйм мин сине, ди иде. Үзем дә мин башта шулайрак булып карадым, ди. Юк бит, туган, ди, бот кысудан карын тараймый, ди иде. Байлар эчәләр, тарталар, карта уйныйлар, бишәр җирдә матур кызлар асрыйлар. Аларның бер көндә эчкәннәре безнең егермебезгә бер елга дөнья котәргә җитәр иде, ди. Ә без нәрсә, ди. Атна буена шахтаның җәһәннәм төпләрендә билдән пычрак суда йөреп, сөякләрең каткан була, получкадан соң шуны бер ярты белән бераз йомшартасың. Бу эчүмени?! Бу эчүләр дә булмаса, без әллә кайчан таш булып катар идек, ди. Булдыра алсаң, түз, эчмә, ди. Әмма, туган, әмма туган... аның белән генә дөньяны төзәтеп булмый икән, – ди торган иде.

Башта шундый сүзләр булгаласа да, бара торгач, мине куйдылар. Мин ишан да, монах та булып йөрим.

Күп чыдадым. Инде тагы утызлап сум гына кирәк. Күпкә чыдаганны азына түзәрмен дип өмет итәм.

Их, булмады, җегетләр!

Шахтаның управляющие бик шәп бай тора торган бер урыс иде. Шуңарда яңа уналты-унҗидегә чыккан бер кыз тора иде. Зур укымышлы, диләр.

Буйга озынча, билләр нечкә, кулбашлар, бөерләр тулып, кайнашып торалар. Күкрәк калку. Муеннар, их, муеннар: алсу ак булып, җаныңны, йөрәгеңне үзләренә суырып-суырып алалар. Иреннәрендә карасу-кызыл кан уйный, әйтерсең, үбәр өчен генә яратылганнар! Тешләре оста кул белән тезелгән тигез ак энҗеләрмени?! – шулай матур булып тезелеп торалар...

Озынча, бераз биек борын аның бөтен йөзенә ниндидер үткенлек, сөйкемлелек бирә. Күгелҗем тирән зур күзләренә карасаң – бөтенләй хәлем бетә торган иде.

Бу фәрештәне – бу җыланны беренче күрүемнән үк күңлемә курку төште. Шуннан бер афәт, бер бәла-каза чыкмаса ярар иде дип уйландым.

Ул үзе безнең шахтада пай ияседерме, конторда ялланып хезмәт итәдерме, белә алмадым, – ни дә булса, бар, ул эшкә катнаша, эшчеләр арасына да килеп йөри, ара-тирә фәрманнар да бирә. Чын исеме шулдырмы – аны “Лиза” дип йөртәләр.

Күңелем каршы булса да, йөрәгем курыкса да, әллә нинди бер көч мине җиңә башлады. Дүрт-биш ай буенча кими саклап йөргән яхшы күлмәгем

белән әйбәт итегем бар иде. Шулар әллә ничек капчыктан чыктылар. Эштән соң, бәйрәм көннәрендә, үзем сизмәстән үк, өстемдә шул күлмәк була, тазартылып, итегем аягыма киелә...

Әллә кайчан алып та, Гайниякәем өчен булыр дип саклап килгән исле сабын да үзенең ак йомшак күбекләре белән Солтанның битләрен, муеннарын, шалкан чәчәрлек булып каткан колак эчләрен иркәләп юалар. Кайчандыр, кайдадыр бер явыз җылан яшь хатын миңа: «Сез чәч җиткереп йөрегез, кара чәчләрегезнең маңгаегызга төшебрәк торуы сезгә бик килешә», – дигән иде. Әллә кайчан онытылган шул сүз дә хәтеремә төшә – шимбә көннәрдә башкалар мыек-чәч төзәткәндә, мин әле бала җон кебек кенә, чак кына күтәрелеп килгән сакал урынын бик озак кырам, әмма чәчкә аз гына да пәке тидермим. Кара чәчем маңгаема төшә дә башлады инде.

Шулай ясанып, күлмәкчән, күкрәкне, муенны бераз ачып чыккан вакытларда мин төрле яктан яшь хатыннарның үземә сокланып карауларын сизәм. Ачуланам да, эчтән кәефләнәм дә.

Лиза белән без бик еш очрашабыз. Ул башкалар кебек күзен майлатмый да, ләкин тирән, зур, матур күгелҗем күзләре белән минем йөрәк бәгырьләремә үткәреп, туры, озак карый...

Хәлләрем бетә, тез буыннарым калтырый.

Көннәрнең берендә Лиза каядыр барырга җыенган икән.

– Әйдә, Солтан, утыр кучерга: минем Иван әллә кая йомышка киткән, – диде.

Зур тауларның тар, текә ярларыннан дүрт сәгать йөртеп кайтардым. Бөтен дөньямны сөйләтте.

– Ярый, бик яхшы, шулай нык булганың яхшы, – диде. Үзе һаман шулай йөрәгемә үтеп карый, беләкләрем, киң күкрәгем, таза көчле гәүдәм белән сокланып туя алмый кебек иде. Ләкин андый яктан бер сүз дә әйтмәде, тик бер таудан җәяүләп менгәндә генә:

– Солтан, тукта... Хәлем бетте, – дип минем беләкләремә, кулбашыма таянды, аннан соң билемнән кочаклый язып, арбага сикереп менде дә, атны каптырырга кушты.

**XVI**

Шулай үтә.

Беркөн иптәшләр карта уйнап утыралар. Мин карап торам. Шул вакыт управляющийның асравы керде дә:

– Барышняның әйберләрен күчерергә кирәк, ике җегет килсен!.. Әйдә, Солтан, син барыбер тик утырасың икән... бер иптәш ал да бар, – диде.

Жегетләр көлә башлады. Усал телле Әхмәт миңа бармак яный:

– Син, жегет, – ди, – Лиза тирәсендә күп йөри башладың, антыңны эчеп куйма!.. – ди.

– Нәрсә, – мин әйтәм, – йөрү ул: эш кушкач, бармый хәл юк бит инде! – дим.

Вәли, кулындагы картаны өләшә-өләшә, әйтә салды:

– Бер хәл бардыр, – ди, – ул яшь симез бия безнең Солтанны бик еш эшкә куша, – ди. – Аңа Солтаннан берәр нәрсә кирәкмиме икән? – ди.

Әхмәт тагы телгә салышты:

– Их, жүләр дә соң син, Вәли! – ди. – Гомерендә айгыр күрмәгән яшь симез биягә нәрсә кирәк булсын?! Күрәсең, чыдаша алмый йөри бит! – ди.

Теге Казан картын алдым да, икәүләп Лизага киттек.

Управляющий хатыны каядыр кунакка киткән икән, Лиза күтәрелеп карамыйча гына, безгә эш куша башлады:

– Бу караватны азрак күчерергә... Әнә теге диванны күтәреп астындагы чүпләрен чыгарырга, белмәм тагы ниләр...

Без болар* белән маташканда, эчке бүлмәдән Лизаның тавышы килде:

– Бабай, син яисә Солтан, берегез килегез әле. Моннан чыгарасы нәрсә бар, – ди.

Бардым. Ишек ачып эчкә кердем.

Ни күрим?

Жәннәтме, нидер, белмим! Гаҗәеп бер матурлык белән җыелган бүлмә: чәчәкләр, алтын тышлы китаплар, аяк басарга куркырлык хәтфә келәмнәр булса, оҗмахтагы хур кызларында гына була торган асыл мендәрләр, ефәктән челтәрле юрганнар белән тулы гаҗәеп бер карават...

Бүлмәнең тәрәзәсе терраска, аннан бакчага чыга икән.

Мин кергәндә Лиза шул бакчага чыга торган ишек-тәрәзә янында иде. Күзләремә керердәй булып, сүзсез-нисез карап торды да:

– Солтан, кил әле бире, бакчадан тәрәзәгә менә торган баскычның бер тактасы кузгала, син шуны рәтләп куй әле, – диде.

Бардым. Рәтләдем.

Өстенә карарга тәкатем житми: Лизаның бөтен тәне үтә күренә, ул әллә нинди бер нечкә пәрдә кебек кенә нәрсә кигән. Муен, күкрәк, беләкләр бөтенләй-бөтенләй ялангач. Әйтергә сүз тапмадым.

Үзе кушканча, почмактан дүрт-биш пот булырлык авыр бер сандыкны бер кулым белән алдым да чыгып киттем.

Маржа әллә нинди бер көлү белән кычкырып көлде:

---

* 1936 елгы басмада: *болар* сүзе урынында *эш* сүзе килә.

– Ну, синдә көч дигәне бар икән! Җегет син, Солтан! – ди.

Эшне бетердек тә яңадан карта уйнаучыларга кайттык. Безнең иптәшләр аракы, колбаса, кармак тагы әллә нәрсәләр алдылар да бәйрәм итү өчен тауга киттеләр.

Мин бармадым; анда барсаң – карта, аракы; монда калсаң – фәрештә* сынлы җылан! Белмим, ни эшләргә?

**XVII**

Безнең барактан ун гына сажин җирдә бик зур бакча бар. Уртасыннан кечкенә генә елга да ага. Иптәшләр киткәч, шуңа чыгып утырдым. Күңелем Зәңгәр чишмәгә, Агыйдел буйларына китте. Озак-озак Гайнияне уйладым. Бу кыз белән вәгъдә алышу түгел, җүнләп сөйләшкәнем дә юк. Шулай булса да, ул минем йөрәгемә хатыным булып кереп утырган. Мин киләчәк көнне башкача уйлый алмыйм. Инде егерме биш сум гына кирәк. Аннан соң юлга, вак-төяк бүләк-яракка бер унбиш сум эшлим дә авылга кайтам. Йортны күчерәм. Гайниялләр белән янәшә булабыз.

Тукта! Чү!

Кем ул бакчада бөтенләй ак киемдә ялгыз йөри?!

Лиза икән. Күрүгә миңа таба борылды. Торып китимме, дидем, кузгала алмадым.

Еррактан ук матур елмаеп, минем йөрәк бәгъремә туры карап, матур тавыш белән сөйләнеп килә:

– ...Солтан, син нигә иптәшләрең белән пикникка китмәдең? Көн бик әйбәт бит! Җитмәсә, тагы зур бәйрәм! Син язны яратмыйсыңмы әллә? – ди.

Мин әллә нәрсә лыгырдап җавап бирергә теләсәм дә, ул мине бүлде:

– Ах, беләм... беләм! Син ялгыз калып, үзеңнең Агыйделең, Зәңгәр чишмәң, Гайнияң турында уйларга теләгәнсеңдер, – диде.

Бу кыз – чыннан да мине харап итә.

Үзе дә җанына чыдаша алмый, бугай. Минем дә тәкатемне ала.

Сүз кайтарганымны көтмәде, ачык кискен тавыш белән көлде:

– Сиңа миннән фәрман шул: бүген кич чиркәү төнге сугуын башлагач, син менә шул бакчадан барасың да, үзең бая төзәткән баскычтан террас аркылы минем бүлмәмә керәсең, ишеттеңме?

Сүзен әйтеп тә бетте, аккош йөрешләре белән биеп-биеп янымнан гаиб тә булды[13]. Минем колакта аның көмеш тавыш белән көлүе генә чыңгылдап калды.

**XVIII**

Кичкә чаклы шул турыда уйладым.

---

* Чыганакта: *фирештә.*

[13] *Гаиб булды* – юк булды.

Тукта, мин әйтәм: карта уйнамыйм, аракы эчмим, тәмәке тартмыйм, тамагымны кысам. Болар бит һәммәсе дә шул ике йөз тәңкәне тутыру өчен эшләнәләр.

Хатын-кызга якын бармаска дип нәзер әйтүем дә шуның өчен иде: болар белән якынлашсаң, ничек кенә булса да, артык чыгыш ясыйсың. Азмаз бүләк бирәсең, җиләк, конфет ашатасың... Боларның һичберсен кабул итмәсә, барыбер үзең аның өчен яхшырак киенәсең, купшыланасың, саран исемеңне чыгартмас өчен, кеше алдында хур булмаслык яшим дип, үзеңә күбрәк тота башлыйсың... Шулай итеп, тулып килгән ике йөзең әкренләп кими башларга да мөмкин!..

Ярый, башкаларга шулай...

Әмма Лизага нәрсә? Ул менә дигән бай, укыган кыз. Аңа минем тәнемнән башка бернәрсә дә кирәкми... Яратса, шул көйгә яратыр, яратмаса, чукынып китсен: мин, аңа ярыйм дип, үзем өчен бер тиен чыгым ясамам, купшыланмам!

Бер уйга туктала алмадым, шулай да итекне яңадан тазарттым, күлмәкне төзәтеп кидем, су кереп кайттым, чәчне рәтләдем.

---

Кич. Урал тынды. Эшчеләр – күптән йокладылар.

Чиркәү суга башлауга, мин акрын гына тордым да, бакчага чыктым. Терраска карасам, анда бер ак фәрештә ишек яңагына сөялеп тора. Мине күрепме, башка сәбәптәнме, кинәт югалды.

Теләмәдем, бер нәрсә дә уйламадым, аякларым шул якка алып киттеләр. Тәнемдә җиде ай буенча җыелган куәт акылымны каплады, каннарым бөтен бөерләремнән, йөрәгемнән ташып күкрәгемә таба килеп тыгылдылар. Дөнья җимерелсә, иртәгә моның өчен башым киселә торган булса, – мин һаман да туктала алмас, һаман да шул баскычтан, террас аша, көндез күргән җәннәтемә керер, кыз теләмәсә, каравыл кычкырса, һаман керер идем.

---

Ләкин каравыл кычкыручы булмады.

Ачык ишектән барып кергәндә, Лиза үзенең караватында асыл мендәрләр, ефәк юрганнар эчендә хур кызы кебек югалып, яткан иде.

Күземә ак-кара күренмәде, тиз ашыгып, җеннәнеп аның янына таба бара башладым.

Ул ниндидер эчке ялкыннан көйгән иреннәре белән йөземнән, күкрәгемнән, әллә кай җирләремнән үбә, акылыннан, һушыннан язып үбә, кочаклый, үзе әллә кайдан эчтән, тирәннән, җәһәннәм эссесеннән килгән ят бер тавыш белән:

– Бәгърем, кил ... дип, көлеп ыңгыраша иде.

Бу азгын көлү йөрәгемә үтә төште.

...............................................................................................

Мин хәйран калдым: ул моңарчы һичбер ирнең кочагында булмаган, саф кыз булып чыкты! Үзе моны сөйләп бирде:

– Син, ди, яңадан Зәңгәр чишмәгә кайтканчы хатын-кызга якын бармам, дип ант иткәнсең! Әмма мин сине күргәч, синең киң күкрәгеңне, көчле беләкләреңне күргәч, минем беренче яшьлегем шул арслан белән булыр, дип ант иттем, ди. Йә, сөйлә: кем көчлерәк булып чыкты? – ди.

Үземнең антымның сәбәбен сөйләгәч, ул хахылдап көлде:

– Җүләр син, – ди, – кирәк булса, мин сиңа үзем ике йөз түгел, биш йөз, биш мең дә бирермен, – ди.

**XIX**

Лиза, бәлки, биш йөзен дә, биш меңен дә биргән булыр иде.

Ләкин оҗмахтагы хур кызларының кочакларын оныттырырлык булган бу кичәдән, адәм баласының гомерендә бер генә мәртәбә насыйп була торган ул гаҗәп иркәләрдән соң минем күңлем зур куркуга төште.

Бәлки, дим, шулай булыр: ул мине алыр, асрар, киендерер, шундый төннәр, шундый иркәләр белән миңа тагы җәннәт көннәрен бирер, – аннан соң нәрсә? Туяр да, кирәгең беткәч, куып чыгарыр.

Кем белә, бәлки аның күңелендә башка уйлар да бардыр... Мине үзенә ир итмәкче буладыр...

Моның өчен кирәк булса, йә үзе мөселманлыкка чыгар, йә мине чукындырырга теләр.

Их, мин ул кыз белән акылымнан язам бугай...

Юк, булмас, берсе дә булмас, берсе дә булмый.

Матур бер җылан өчен дин алмаштырып, әткәй-әнкәйне, Гайниямне ташлап йөрер хәлем юк!

Хәерле сәгатьтә моннан китәм!

Бәйрәм алдыннан – кичәге көн барлык эшләгәннәрем өчен тиешле акча алынган иде.

Дүшәмбе көн хезмәткә чыкмадым.

Билетымны алдым, китәчәгемне белдердем, яңа күлмәк белән итегемне капчыкка салып аркама астым да Уралның саф көмеш елгалары, боргаланып-боргаланып болытларга сузылган биек таулары, зур күлләре буйлап тагы шахталар эзләргә киттем.

Озак йөрергә туры килмәде. Дүртенче көндә мин яңадан бер алтын приискасына килеп ялландым.

Тагы берничә атналар эшләгәч, ике йөз тәңкәне тутырып, аның

өстәвенә юллык, өйгә вак-төяк бүләклек тә арттырдым.

Вак акчаларны бөтен ике йөзәрлеккә алмаштырып, йөрәк өстенә бөти ясап тектем дә, Уралның тирән шахталары белән бәхилләшеп, Зәңгәр чишмә ягына таба юл тоттым.

Кайтышлый, тагы Салават баһадирның Мәргәне кабере янына – биек тау башына утырып, хәл җыйдым.

Яңгырлы-болытлы көз, аның артыннан карлы-буранлы каты кыш үткән; минем баштан да әллә ничаклы хәлләр кичкән, ләкин Зәңгәр чишмә аз гына да үзгәрмәгән.

Ул һаман да элеккечә зур, мәһабәт булып, әллә кайдан җәелеп, һаман элеккечә матур кояш нурлары белән уйнап яши икән әле.

**XX**

Тәкъдирнең язганы шулай булгандыр, күрәсең, инде.

Сентябрьдә китәм, язгы сабанга кайтып җитәрмен, насыйб булса, дигән идем.

Чама-чамадан ерак китмәде.

Мин авылга кайтып төшкәндә, солы, борайны чәчеп бетергәннәр, тары, карабодайга яңа чыкканнар гына иде әле.

Әткәй кат-кат рәхмәт укыды:

– Ахыры хәерлегә генә була күрсен, һичбер көтелмәгән эш булып чыкты бу, балам, – ди.

Әнкәйнең шатлыгына чик-чама юк. Аңа дип алып кайткан күлмәклек белән яулыкны биргәч, түзмәде, елап җибәрде:

– Мал да, бүләк тә өмет итмәгән идем... Башы исән-сау гына кайтса ярар иде дип, намаз арты саен елап-елап дога кыла торган идем... Бервакыт әллә кайсы шахта җимерелгән, уналты кеше аста калып изелгән, утыз кеше имгәнгән имеш, дип сөйләделәр, шуны ишеткәч, ашаганым аш, эчкәнем су булмады... Бердәнбер балам иде, аңардан да аердың, күрәсең, дип, көн еладым, төн еладым, – ди.

Өйдәгеләрдән авыл хәлләрен сорашып, ни күргәннәремне сөйләп, берничә сәгатьләр утыргач, урамга чыктым да иптәшләрне эзләргә киттем. Бәлки, Гайнияне дә очрата алмаммы дигән өмет бар иде.

Шул арада минем бүләкләр, ике йөз тәңкәләр бөтен авылга таралып та өлгергән икән. Һәркем исәнлек-саулык сорашуга сүзне шул якка бора:

– Эш белән генә ул чаклы мал таба алу бик авыр хәл... Берәр җирдән эләккәндер яисә, кисәкләтә алтын табып, хуҗаңа бирми калдыргансыңдыр, – диләр.

– Әйе, – мин әйтәм, – табарсың кисәкле алтыннарны! Анда арыслан кебек ир-җегетләр бөтен гомерләре буенча алтын казыйлар да, аякларындагы

ревматиз белән аркаларындагы бөкреләреннән башка бер нәрсә дә таба алмыйлар, – дим.

– Хәерле булсын инде, ничек булса да, яхшы кайткансың... Картая башлаган көннәрендә ата-анаңа зур ярдәм булган, – диләр.

Юлда очраганнардан мең бәла белән котыла-котыла, Галиләргә барып җиттем. Ул бакчаларында, чәчәкләр арасында, әллә нинди матур сурәтле мөселманча китап укып ята иде. Өстенә кинәт барып чыккач, шаша калды:

– Бу кем?.. Солтан, синме? – ди. Үбеп, кочаклап, бик озак күреште.

Шунда ук чәй китерде, вак бәлешләре белән барын бергә җибәрә башладым.

– Ну, – дим, – кая безнең башка иптәшләр?

– Иптәшләр таралгаладылар, – ди. – Шаһбаз күптән түгел кайткан иде, ул каядыр бер заводка урнашкан бугай. Һәрвакыт шунда торырга исәпли, – ди.

– Ну, сез аның белән килештегезме?

Гали көлде:

– Менә җүләр, әлбәттә килештек! Иртән уянгач та Фазыйлга бардым... Мин әйтәм, кичә әлләниләр булып беткән икән... Мин Шаһбазны рәнҗеткәнмен икән... һичберсен хәтерләмим... Бар, Алла хакы өчен, исереклектән булган, диң... мине кичерсен дип әйт, дидем.

Фазыйл үзенә чәйгә җыйды. Мин дә бардым. Без яңадан килештек, элеккедән дә болайрак дус булдык. Ул кичәдә тагы Гыйлаҗига барып, эт булганчы эчтек...

Мин елаганмын, Шаһбазның аягына егылып гафу үтенгәнмен. Тагы әллә ниләр булган... Иң кызыгы: йорт алдына чыгып, Гыйлаҗиның анасын тотканмын да: «Миңа кызың Гайнияне бир, мин аңа гашыйк булдым, ул тирә-якта бер кыз!» – дип, ахмаклык сатып беткәнмен... Ну, ярый.. Син үзең бик баеп кайткансың, ди. Куык очырасыңмы, әллә чыннан да шулаймы?..

Мин аңа сөйләп бирдем.

---

Фазыйл кымызда икән. Шушы көннәрдә кайта, ди.

Гыйлаҗи атасы белән күрше авылда мәчет эшли, ди. Ул да базар көн кайтмакчы иде, ди.

Исәнләштем дә туры өйгә киттем.

---

Кич староста килде. Аның янына Шаһи карт белән Җамалины чакырдык.

Тавыкның бик шәбе тутырылган иде. Бер чирек әче бал белән бер бөтен кызылбашны күргәч, картларның авызлары колакларына җитте,

күзләре уйный башлады.

Староста мине янына чакырып алды да колагыма гына:

– Хәнифә апаң әйтә, Солтан кайткан икән, ди. Миңа хәл белергә дә килми дип үпкәли, ди. Син иртәгә аңа кереп чык, карчыкның күңеле булсын: күчтәнәчкә бер биш кадак кәрәзле ак бал алып бар, – ди.

– Ярар, – дип баш идем.

Эшләр тиз җайланды. Старостаның мөһере белән кәгазе дә кесәсендә икән, аштан соң, чәй эчкән вакытта ук, урынны безнеке ясап беркеттеләр.

Зариф оста янәшәсендә күптән үк Себергә сөрелгән безнең кардәш Минһаҗның буш урыны ята. Бу алты гына сажин булганга, өй салып керергә закон кушмый. Аның янындагы тыкрык өч-дүрт арба берьюлы сыярлык – шундый киң.

Безгә менә шул буш урын, аның өстәвенә теге тыкрыктан бер-ике сажин җир кирәк иде. Кызу кулдан моны бетереп алдык. Ике карт тамга салды, староста мөһер басты да кәгазьне әткәйгә бирде:

– Теләсәң, иртәгә үк тот та күч... Менә картлар сиңа тыкрыктан ике сажинны үлчәп бирерләр... Барлыгы сигез сажин була... Закон буенча йорт салып керү өчен бу бик җитә, – диде.

Рәхмәт укып, догалар кылып, яңа йортка бәхетләр теләп, ярты төн вакытында чыгып киттеләр.

**XXI**

Сиксән биш сумга югары оч Галәвинең алты почмаклы өен алдык. Үзе ике генә ел торган. Бүрәнәләре яңалар, корылар. Ишек, тәрәзә, идән, түшәм – бары да бик бөтен.

Тик, бераз биегрәк булсын өчен, нигезгә берәр бүрәнә салырга туры киләчәк.

Утыз сумга Садыйк байның бер келәтен алдык. Зур гына, иркен генә. Өсәкләре дә бик яхшы икән. Булгач-булгач ак келәт булсын дип, моңа кечерәк кенә бер тәрәзә дә куйдырырга исәплим.

Әткәемнең көздән чыгарып калдырган ташы бар икән. Алты сажин, ди.

Насыйп булса, өйнең дә, келәтнең дә астына тирән итеп нигез салырбыз, юкса, су китеп чери, фәлән итә башлый.

Өй кузгаткач, аның кирәге күп була икән. Кыегы, ишек алды, тагы әллә нәрсәләре өчен егерме тәңкәлек төрле бүрәнәләр, киртәләр, такталар алдык...

Иптәшләр: «Үзең маташсаң, озакка китәр, әйдә өмә ит!» – диделәр. Әткәй дә риза булды.

Өйне, келәтне, таудагы ташны да өмә белән ташыдык. Җегетләргә рәхмәт инде: Гали – дүрт аты белән ике ялчысын җибәрде. Фазыйл кымыздан кайтмаган иде. Заһит хәзрәт үзенең балта эшенә бик оста карт ялчысы белән

ике ат бирде.

– Ну, җегет, сиңа яңа нигез корабызмыни? Миннән башка булмый бу эш! – дип, Гыйлаҗи да балтасын, пычкыларын күтәреп кайтып җитте.

– Синең хәбәрне ишеткәч, ди, мәчетне ташлап кайттым, ди. Сиңа, ди, шундый бер өй ясап бирим, бөтен Агыйдел буенда даның чыксын; өең, якмыйча, май кебек җылы булсын, – ди.

Башкалар да, һәркем кулыннан килгәнчә, атлы – аты белән, атсызы – кул көче белән булышып, уен-көлке эчендә өй белән келәтне ташып та бетерделәр* ...

Икенче көндә күрше-күләнне җыеп, өмә сымаграк ясап, өйне мүкләп күтәрдек. Бусына инде Зариф оста берничә сәгатькә кайтып үзе дә булышты... Яңа күрше Гайнияләр аш-су белән ярдәм иттеләр.

Берничә көннән мич тә өлгерде.

Шулай итеп, бер атна дигәндә, без бу яңа урынга, яңа өйгә бөтенләй торырга да күчтек – күпер башындагы чүплектән мәңгегә-мәңгегә котылдык.

**XXII**

Бәхет бер алга китсә, шулай була бит ул.

Без яңа өйгә күчкәннең икенче көнендә Фазыйл кайтып төште.

Яратам шул җегетне!

Бөтен тирә-якның йолдызы булса да, башкалар кебек борынын күтәрми. Балачактагы дуслыклар буенча, олы башын кече итеп, безне һаман да үз күрә, якын күрә. Әле дә, өендә чәй эчкәнме-юкмы, хәл белергә, яңа йорт котларга дип безгә килгән. Кулында бер стена сәгате, ярты аршин зурлыгында бер көзге бар.

– Менә сезгә болар өй котлаудан булсын, – ди.

Шатлыктан әнкәйнең башы күккә тиде, ничек итеп рәхмәт әйтергә белми, үзенең чаршавы артыннан, ояла-ояла, әллә ниләр сөйләп бетерде:

– Алла үзегезгә бергә мең итеп кайтарсын, – ди. – Без әйбер көтмәгән идек, үзегезнең фатиха биреп чыгуыгыз да безгә бик зур шатлык иде, – ди,

Мин, әнкәйнең сүзләреннән бигрәк, Фазыйлга карап хәйран булдым.

Ул хәзер камил җегет булып, ир булып үсеп җиткән инде. Сүзләре, үзен тотулары бөтенләй өлкәннәрчә. Аның өстендәге шәһәрчә киемнәре, бигрәк тә аягындагы кыска ак ботинка белән башындагы ак камыш эшләпәсе аңа әллә нинди зур төс бирәләр. Болардан бигрәк, мин аның тавышына, йөзенә карап гаҗәпләндем. Шул сигез ай эчендә ул бик ябыккан. Электән дә аксыл йөзе хәзер, ничектер, үлем аклыгы белән капланып, эчкә суырылган. Элек тирә-ягына нур чәчеп торган зур, матур, тирән күгелҗем күзләре хәзер,

---

* Чыганакта: *беттеләр.*

никтер хәлсезләнеп, эчке бер кайгы белән карыйлар.

Тавышта да әүвәлге көч юк. Ул элгәре сабыр, ләкин кискен бер тавыш белән кыска-кыска итеп берничә сүз әйтсә, аңа адәм түгел, ташлар да буйсына кебек иде... Хәзер бу да, ничектер, йомшарганмы, хәлсезләнгәнме? Белмим, ни дә булса бар.

Җаным түзмәде, әткәйләр алдында ук бу турыда үзеннән сорадым:

– Фазыйл, – мин әйтәм, – сиңа кымыз килешмәгән, ахрысы. Бик ябык күренәсең... Әллә берәр чирең бармы? – дим.

Ул балачактагы кебек акыллы күзләре белән миңа туры карый.

– Әйтерлек хасталыгым юк... Быел кыш Казанда имтиханнар алдыннан бик каты укырга туры килде... Ахрысы, шуннандыр, кан азаеп калган, бераз гына ютәл дә бар,– ди.

Ләкин мин аның күз карашыннан, тавышыннан аңладым: бу әйтелгәннәр – сәбәпнең бөтенесе түгел, монда әйтергә ярамаган башка эшләр дә булса кирәк.

Әнкәй чаршау эчендә, мич алдында ашыгыч-ашыгыч нидер чыж-пыж кыздыра, пешерә калды, самавыр кайнаганчы әзрәк йөреп керик дип, мин Фазыйлны алып чыгып киттем.

**XXIII**

Агыйдел, безнең ындыр турында кинәт бер борма ясап, авылның эченә керә язып кала.

Без азбарлар, бәрәңге бакчалары ашасыннан шунда таба киттек. Әле язгы ташкын бөтенләй кайтып бетмәгән икән. Зур, киң елгабыз үзенең биек ярлары эчендә тулышып, кайнашып ага.

Балыкчылар, зур сөзгеләренең озын саплары югалып беткәнче суга чумдыра-чумдыра, балык аулыйлар.

Аргы якта әллә кайдан кая җәелеп яткан болындагы таллар ниндидер аерым бер көчле яшеллекләр белән бизәлгәннәр. Алардан бераз үтсәң, Уралның безгә караган итәгенең тармаклары сырт-сырт булып тезелеп китәләр дә, бара-бара каядыр еракта, күккә терәлгән җирдә, күгелҗем кара урманнар белән капланган биек тауларга барып ирешәләр.

Әнә минем Салават дусның юлдашы күмелгән Мәргән тау безгә каршы сәламләп тора.

Күңелләр ничектер шул якка тартты.

Балыкчылардан бер көймә алдык та, ярдан-ярга тулышып аккан Агыйделнең көчле дулкыннары белән көрәшә-көрәшә, ары якка чыктык.

Көн якты, аяз иде. Язгы сабан тургайлары, үзләренең өзлексез моңнары белән җырлый-җырлый, нәкъ безнең турыда, әллә кая югарыга, биек күккә таба китеп югалалар иде.

Ерак китмәдек, минем бишмәтне җәйдек тә, таллар төбенә ятып, еракта, томан эчендә, күкләргә таба боргаланып менгән Уралны тамашага талдык. Юлдашым миңа һаман да кайгылы күренә иде. Яңадан сораганны көтмәде, папиросын яндырды да үзенең серен сөйләп бирде.

**XXIV**

– Уйла син, туганкай Солтан, – ди, – матур, акыллы татар кызын! Буйга зифа. Укымышы бар. Зәвыксыз да түгел: теләгәндә киенә белә, вакытында матур сүзләр белән синең күңелеңне ача ала!.. Хезмәт сөя, үзенең әмәл кәгъбәләренә[*] бару өчен, кирәк булса, ут-су кичеп көрәшерлек йөрәге бар. Шул фәрештәгә[*] каршы китереп куй үсеп буйга житкән бер җегетне! Бу да ахмак түгел, моның да кеше алдында көлке булмаслык буе-сыны, дөнья көтәрлек укуы бар. Һәммәсеннән бигрәк, дөрес, саф күңеле бар. Болар еллар буенча бер-берсен яратышалар. Телдән әйтешмәсәләр дә, һәр икесе үзләренең киләчәк көннәрендә дөньяның ачысы-татысын[*] уртаклап, бергә, тик бергә гомер итүне йөрәкләренең иң тирән катлауларына яшь сөю каны белән язып куйганнар! Менә шул вакыт ике уртага кара гарәп килеп керә.

Җегетнең анасы бу саф дуслыкны кайдандыр ишетә дә: «Угылым азган икән, Казанда әллә ниткән мөселман маржалары белән сихерләнеп йөри икән... Аны тизрәк коткару – минем бурычым!» – дип, үзе белгән, яраткан бай кызына сүз салдыра. Вәгъдә ала, ике арада бүләкләр йөрешә башлый... Җегет, арып, авырып, бераз хәл алыйм дип кайтса, аны менә шул хәбәр белән каршы алалар: «Котлы, мөбарәк булсын, без сине башлы-күзле ясадык... Кыз матур, байлыгы зур, артында ике йөз дисәтинә җире, мал-туары, бик күп урманы, бер тегермәне бар», – дип тәбрик итәләр... Имеш, Гыйрфан байның кызына өйләндереп, мине зур бәхеткә чумдыралар!

Фазыйл сүзләрен мин хәйран булып тыңладым. Аның сөйгәне Гәүһәр туташны җанлы көенчә күз алдына китереп бастырдым... Шуннан соң Заһит хәзрәтнең һәркем каршында кадерле – изге остазбикәсе минем алдымда бер аждаһага әйләнде дә Фазыйл өстенә ажгырып-ажгырып ташлана торган кебек булды.

Тик берничә минутлар үткәч, сүз әйтә алдым:

– Соң, – мин әйтәм, – әткәң Заһит хәзрәт кайда булган? Ул ризамыни?

Фазыйл, бик күңелсезләнеп, йөзен чытты:

– Син беләсең бит безнең әткәйне: ул йомшак, аның өстенә мәхәлләдән, байлардан, кеше сүзеннән бик курка торган кеше. Башта каршы булган: «Фазыйл жир читенә китмәгән бит, үзе кайткач карарбыз», – дигән... Ләкин

---

[*] 1936 елгы басмада: *үзенең әмәл кәгъбәләренә* сүзләре *үз теләгенә* сүзләре белән бирелә.
[**] 1936 елгы басмада: *фәрештәгә* сүзе *кызга* сүзе белән бирелә.
[***] 1936 елгы басмада: *төчесен*.

безнең әнкәй артык үз сүзле, усал, үткен бер хатын: әткәйнең ай-ваена карамастан, эшне бетергән, – ди.

Мин, аптырап, иптәшемнең күзләренә карадым:

– Ә хәзер нәрсә ди әткәң?

– Нәрсә әйтсен: «Булган эш булган инде, тәкъдирдә язылган шулдыр», – ди.

– Мин шуңа аптырыйм, бу эшкә Гали ник каршы тормаган?

– Бөтен бәла дә шунда шул: аларның пароходлар төшкәч тә җибәрелгән иген баржалары беләнниндидер аңлашылмау чыккан икән; Гали, шуның артыннан Рыбинскига[4+] китеп, ун көннәр йөреп кайткан...

Кайтса, аңа да яңа хәбәр итеп: «Сеңеләңне Фазыйлга ярәштек», – дип сөенче алганнар...

– Хәзер ул нәрсә ди?

– Нәрсә дисен, сүгенгән, йортыгызны ташлап чыгам, дигән. Фазыйлга тиң кыз түгел ул, бу эш барыбер җимерелер, дип куркыткан. Аңа карамастан, хатын-кыз үз эшен эшли биргәннәр... Мин кайтып төшкәндә, ике як та туйга хәзерләнә иде...

– Соң, син хәзер үзең ни эшләмәк буласың?

Фазыйл ике сүздә моны әйтеп бирде.

Өйләнү ихтималы юк. Эш анда түгел. Шул мәсьәлә сәбәбеннән гаилә эче җәһәннәмгә әйләнгән... Әткәсе бик борчыла – гомерем буенча саклап килгән абруемны җимерәсез, ди... Әнкәсе, акылыннан шашып, көн-төн елый, – ил алдында мине хур иттең, дөнья йөзенә күренерлегем калмады, ди. Хәзер түшәктән тора алмый, авырый... ашамый... эчми. Менә җәһәннәм шунда...

Боларның һичберсенә карамастан, Фазыйл китәчәк. Атасы белән ара суыкланганга күрә, аңардан бер тиен дә акча алмаска тели. Гыйрфан бай моңарчы ел саен бирә бара иде, аны да кире ташлый.

– Мин хәзер, – ди, – сезнең кебек үз көнемне үзем күрергә, үзем эшләп, үзем ачыгып, үзем-үзем хуҗа булырга китәм, – ди.

## XXV

Фазыйл сүзендә торды.

Агыйдел буендагы сөйләшүдән бер атна үтүгә, ул сәфәргә чыкты.

Ул, кыш укырга акча табар өчен, бу җәйне хезмәт итеп үткәрмәкче. Гали аңа:

– Болай биргән ярдәмемне алмасаң, безнең Кама буендагы икмәк приемын идарә кылырга кер, айга җитмеш сум үзем бирәм. Ул пристаньда әткәйнең катнашы юк, аңа мин үзем хуҗа, – дип караган иде, Фазыйл риза булмады.

– Волга буендагы постау[14] заводларында бер таныш иптәшем бар. Шуңа барам, аның аркылы керә алмасам, Мәкәрҗәгә[5+] китәрмен, – ди.

Аны озату миңа, бер яктан, бик авыр булды. Икенче яктан, шатландым: – Фазыйл хәзер үзенә хуҗа була... Үзенең сөйгәне Гәүһәр белән ирекле тормыш төзерлек азат юлга керә.

– Башка нәрсә әйтим: хәерле сәгатьтә, дускаем!

**XXVI**

Фазыйлдан соң Гали дә озак калмады.

– Аның авыруы бар, – ди. Безнең Шаһбаз, көлә: – Сиңа, Гали, ди, байлар авыруы йоккан... Моның бердәнбер дәвасы: һәр көн ун сәгать эшләү, катыга ятып йоклау, арыш икмәге белән бәрәңгедән башканы ашамау, – ди.

Гыйлаҗи да шул юлда бәйләнә:

– Алар өстенә, өстә начар чикмән, аякта чабата булсын, – ди.

Әмма башка кешеләр начар сөйлиләр:

– Галинең калада бер матур марҗасы бар икән, шул чирле нәрсә булган икән, Галигә дә шуңардан ниндидер бер яман авыру йоккан икән, тизрәк дәваланмаса, Галинең борыннары череп төшәчәк икән, – диләр.

Гали үзе нык кайгырмый.

– Минем, – ди, – нервлар бик какшаган. Үпкәдә дә азрак бар. Бусы кыш көне бер эчкән вакытта, үземне-үзем белмичә, ялан өс салкынга чыгудан булды, ди. Миңа бернәрсә дә түгел. Кавказда ике ай ятам да төзәләм. Анда булдыра алмасалар, Германиягә барып кайтырга да мөмкин, – ди.

Ул да китте.

Шаһбаз ике генә көнгә кайткан иде. Ул хәзер «Иж» дигән бер заводта[6+] эшли икән. Шунда урнашырга уйлыйм, ди.

– Чәчәргә жирең, җигәргә атың булмагач, Зәңгәр чишмә суы белән генә яшәп булмый бит, – ди.

Дөрес сүзгә ни әйтәсең?!

Аны озаттык.

Агыйдел буенда Гыйлаҗи белән мин генә калдым. Бу иптәш тә атнага бер генә кайта. «Кысылдык» башкортлары, җир сатып акча алгач, үзләренә мәчет салдырырга, күперләр эшләтергә тотынганнар икән.

Гыйлаҗи, балталарын, пычкыларын күтәреп, шунда эшләргә йөри.

Зәңгәр чишмәдә тик мин бер үзем!

**XXVII**

Бу дуңгыз Кәрим бай малайларына һичбер йомыш бирергә ярамый: бер юл печәнгә генә барып кайтабыз дип, фурман арбамны[15] алып торганнар иде,

---

[14] *Постау* – уң ягы киезсыман тукыма.
[15] *Фурман арбамны* – гадәттә көлтә, салам, утын ташый торган арбамны.

ике тәүлек буенча көн-төн урман ташып, үрәчәләрен[16] эштән чыгарганнар. Җитмәсә тагы: «Ачуланма инде, Солтан абзый, Әшкүл тавын төшкәндә, кара тай дулап арбаңны аударды, бер үрәчәсе шунда азрак ярылып китте бугай», – дип сөйләнеп, җан көйдерәләр.

Берсеннән-берсе симез әллә ничә алашалары бар өстенә, тай җигеп урманга йөргәч, шулай булмый ни эшләсен соң!

Килеп карарсыз миңа моннан соң берәр йомыш сорап! Үзегезне эт белән генә кудырып чыгарырмын!..

Шулай үз алдыма сүгенеп, азбар эчендә арба төзәтеп маташа идем... кемдер кыйбла як читән ашасыннан безгә сикереп төште.

Карасам, Гыйльминур җиңги икән! Ачуым берьюлы таралды, шатланып ук киттем.

Яратам, валлаһи, шундый хатыннарны: һәрвакыт шат, уенчак, эшкә уңган, сүзгә үткен, уен-көлкегә дисәң, чыдап кына тор! Тулы тәннәрен уйнаклатып, күз карашы белән тирә-ягына шатлык чәчеп йөргән бу калку күкрәкле килендә кайчандыр минем күңелем бар иде. Бервакыт аз-маз “алай-болай” итеп тә алгалаган идек. Әле дә, күзен, кашын уйнатып, бөтен гәүдәсе белән биеп яныма килгәч:

– Алла куәт бирсен, Солтан! – дияргә өлгерә алмады, мин аны шаярта да башладым:

– Нихәл, матур җиңги? – дим. – Сафа абзый өйдә булмаган төннәрдә ялгыз йоклаулар бик күңелсез түгелме? – дим.

Ул аңламамышка салына. Үзенең күзләре яна, яңакларында алсу ут уйный башлый.

Мин тагы өстим. Имеш, озын көйгә җырлаган булам:

– Ялгыз ятукайлар читен булса, мине дә генә кунарга ай чакыр, дим.

Ул канына чыдаша алмый, шулай да, сер бирмәскә тырыша, бөтенләй гаҗәпләнгән тавыш белән каты итеп суза:

– Нә...р...сә???

Мин:

– Кая ташладым соң боравымны? дип әйбер эзләгән кеше булып, аңа таба барам да, кинәт кенә биленнән кочаклап алам.

Ул кыр кәҗәсе кебек ыргып, яннан кача:

– Тиле, көпә-көндез ярыймыни ул? Сафа абзаң ишетсә, икебезне дә харап итәр бит, ди. Бераз чигенә дә:

– Мин сиңа башка хәбәр белән килгән идем, алай кыйлангач, әйтмим инде, – дип, үпкәләп китә башлый.

---

[16] *Үрәчәләрен* – арбаның як-ягына канат сыман өстәлгән җайланмаларын.

Күңелем нидер сизенде; мөгаен, Гайниядән бер хәбәр бардыр кебек тоелды:

– Тәүбә, тәүбә! Бетте, актыгы булсын, җиңгәкәем, ачуланма, хәбәреңне сөйли күр, – дим.

Ул яңадан азбарга кереп, мин төзәтә торган фурманның арт тәгәрмәченә утыра да хәбәрен сөйләп бирә.

Их, җегетләр! Бәхет ишекләре бер ачылса, гаҗәп була икән ул!

Нәрсә, ди, бит! Хәбәре нәрсә бит!

Һәр сүзе мең алтын тора бу хәбәрләрнең!

Минем Гайниякәем Гыйльминур белән сердәш икән, ахирәт икән!

Сафа өйдә булмагач, аулак өй дип, җиңгәсенә, чигүләрен алып, кичә кич утырырга кергән. Шунда үзенең дусына эч серләрен ачкан.

«Мин Солтанны яратам, авылда аннан башка һичбер җегет күземә күренми», – дип, озак-озак сөйләгән!

Боларны ишеткәч, шатлыгымнан ни эшләргә белмәдем:

– Чынмы? Чынмы? Мине юкка тилертмисеңме? – дип, яңадан Гыйльминур җиңгигә барып тотындым.

Җиңги бөтенләй икенче – сабыр тавыш белән:

– Уйнап сөйләргә мин баламыни?.. Менә бүләге дә! – дип, җиң эченнән бер яулык чыгарып бирде.

Нәрсә бит яулыгы! Кызыл җирлек өстенә яшелле-сарылы дебет[17] белән чәчәкләп-чәчәкләп чиккән! Карасаң, күзең рәхәтләнә: шулай ал-гөл чәчеп тора бу чәчәкләр!

Гыйльминур җиңги китте, мин Гайниягә сәлам җибәрдем: «Бүген кич йокламасын, ил-күз тынгач, мин бакча як тәрәзәләрен алып, аның янына керермен», – дидем.

**XXVIII**

Мин Гайнияне баладан ук беләм.

Сабый чакта без аның белән бергә үстек. Бик күп еллар Агыйдел буенда бергә каз бәпкәләре саклачык. Аның анасы аз гына кардәш тә булганга, безгә һаман катнашырга туры килә иде.

Әткәйләр Гыйрфан байга таш кибет эшләгәндә Гыйлаҗи белән дуслашып киткәч, мин бу йортка бигрәк тә еш килә торган булдым. Малайлар үзара җенләнеп уйнап йөргәндә, бездән кече булса да, Гайния дә һаман шунда, безнең тирәдә урала иде.

Ундүрт-унбиш яшьләр булгач кына, әнкәсе Гайнияне:

– Синең ир малайлар белән уйнап йөрер чагың үткән инде! – дип, безгә

17 *Дебет* – бик нәфис, хайван яки кош-корт мамыгыннан эрләп катылган чигү җебе.

катнашудан тыя башлады.

Шул арада ул кызыл алма кебек пешеп тә өлгергән инде: суыр да йот, тик иреннәреңне генә өзмә!

Алма нурланадыр кызаргач,
Җегет тәүфикъ таба кыз алгач...

Фу, каһәр, мин бит башка нәрсә турында сөйли идем әле... Бу җыры кайдан телемә керде тагын?!

Шулай безне тыйдылар. Кеше алдында очрашып сөйләшеп булмый башлады... Әмма безнең күңелләрне аера алмадылар.

Буяулы чиләкләрен күтәреп, бөгелә-сыгыла суга барган-кайткан чакларында, уракка, печәнгә йөргән вакытларда без аның белән бик еш очраша, очраган саен, мин Гайниягә күз кысам, каш сикертәм, ул миңа, шәл астыннан матур җылмаеп, сөеп карап үтә иде.

Берничә мәртәбә бергә эшләргә дә туры килде. Гыйрфан байда ашлык сукканда моның иң шәбе булды. Үткән ел игеннәр бик харап уңган иде. Хак арзан булды. Күп байлар, юк бәягә сатып әрәм итәсе килмәгәнгә, бишәр-унар кибәнне «елларга» калдырдылар. Галинең атасы Гыйрфан байның да берсеннән-берсе биек сигез кибәне, тау кебек сузылган ике зур эскерте бар иде. Ел коры килеп, хак шәп булырлык булса, ул боларны суктырмаска – алдагы кышка калдырырга исәпли иде. Ләкин яңгырлар яхшы булды. Быел да ашлык басуга сыймастай булып җитеп килә. Шуңа күрә Галиләр бу кибәннәрен, яңага чаклы суктырып, сатып бетермәк булганнар.

Гыйрфан бай мине чакыртты. Кердем. Матур өйдә бер карават кебек нәрсәгә кырын яткан, авызында тәмле тәмәке:

– Артыннан йөрергә үземнең вакытым юк, – ди. – Солтан, син үз өстеңә өзеп ал да шул ашлыкларны минем машиналар белән суктырып бир, – ди, – безнең атларны җигәрсең, ди, сиңа, ди, пот башына дүрт тиен ярым түләрмен, ди, ашлыкны җилгәреп, өсәккә[18] тутырып, саламны өеп бирерсең, – ди.

Мин алты тиен сорадым. Ул бишкә менде.

Шуңа килешеп, мин ике парна[19] арасында Гыйрфан байның ындырында машина кордым.

**XXIX**

Миңа акчасы да ярады. Бөтен чыгышларыннан тыш сигез сум саф файда да калды.

Аннан бигрәк, кызыгы зур булды. Аннан да бигрәк, шул машиналар

---

[18] *Өсәккә* – келәттә ашлык, он һ.б.ш. салып саклау өчен такта белән бүлеп ясалган урынга яки зур агач әрҗәгә.

[19] *Парна* – сукаланмый торган кыр.

Гайния белән безнең араны якынайтуга сәбәп булдылар.

Җегетләрнең менә дигәннәрен җыйдым. Әйдәгез, мин әйтәм, мин, дим, сезгә көнлек хакын халыктан биш тиен артык түлим, дим. Ашау да, дим, авылда беренче булыр: иртә белән, дим, суык чәй белән чи икмәк ашарсыз, көндез әчегән катык булыр, кичкә, дим, берәр табак апара эчәрсез, дим...

Малайларым сикереп торалар, биш тиенең башыңа кадалсын, илләмәгәр, диләр, иртән майлы белен булсын, төшкә симез итле өйрә булсын, кичкә тагы ите-бәрәңгесе аерым табак белән китерелгән аш булсын... Болардан да бигрәк, кызларның, киленнәрнең тазаларын, матурларын җыйна: алар безнең алда җырлап, биеп торсыннар, диләр.

Гайния белән Гыйльминур булмаса, Хәернисалар килмәсә, баргач, кире китәрбез, диләр.

– Ярый, – мин әйтәм, – җегетләр; бөлсәм бөләрмен, эшләр сез дигәнчә булыр: белене дә булыр, өйрәсе, итле бәрәңгесе дә булыр, кызларның да, киленнәрнең дә, Гайнияләр, Гыйльминур җиңгиләр кебек, ана арысланнарын җыярмын, – илләмәгәр эшләүгә беләкләрегез түзсен: бер караңгыдан чыгарбыз, икенче караңгыда керербез, – дим.

Шулай итеп, бер кызга бер җегет, бер иргә бер хатын исәбе белән кырык кеше җыйдым.

Кичтән ай яктысы белән машина корылып беткән иде, таңнан чәй эчеп чыктык та гөрр... гөрр... китереп дуылдата башладык.

Рәхәт соң, валлаһи, бу машина белән ашлык сугулар!..

Ындырның бер башыннан икенче башынача тезелешеп, «без – кем?» дип мактанышып, бөтен авылга югарыдан карап торган биек кибәннәр кими баралар, каядыр югала баралар! Бер җегет кибән башыннан көлтә ыргытып тора, ике фурман өзлексез ташыйлар, ике-өч малай, бөтен авыл яңгыратып: «Һайду... һау... аууу», – дип, сигез атны бер түгәрәк эчендә шартлатып куалар... Машина бертуктаусыз: «Зз.. вз... вррр...» – дип сызылдап, выжылдап әйләнеп тора, көлтәне бер яктан йота бара, икенче яктан саламны кагып, алга этәрә тора; шул җирдә хатыннар тырмалар белән ашлыкны тартып ала торалар, бераз гына арырак зур җилгәргеч машина «быз... гыз...» килеп, орлыкны кибәктән аера тора, бер читтә таза җегетләр бу янып торган кызыл бодай орлыкларын йөккә төяп, таш сарайларга озата торалар...

Ә бу якта машинадан чыккан саламнарны чүмәлә-чүмәлә өя торалар; изүләре чишелгән, тиргә баткан таза ирләр салам агачларын бу чүмәләләр астына тыгып җибәрәләр дә, кулны тидермәстән, күтәреп алып китәләр, очыртып, әллә кайларга мендерәләр.

Гайния җырлый:

Челтәрле күпер астыннан

Карлар ага боз булып;
Бер җегетне карата алмый
Буй үстермәм кыз булып.

Башкалар аңа кушылалар.

Тегендә биек кибәннәр югала торса, монда алардан әллә ничә өлеш зур салам эскертләре баскыч-баскыч булып күккә таба үрмәлиләр, озынаялар, киңәяләр, биегәя баралар.

Мин, тузан арасында буталуны яратмаганга, биек эскерт башына салам мендерүгә күп ирләрнең беләкләре чыдамаганга, күбрәк шул тирәдә булдым. Бусы чыннан да иң авыр эшләрнең берсе.

Хатын-кызны әйтмисең дә инде, ир арысланнарның да күбе, иртән бик баһадирланып керешсәләр дә, төшкә таба ыңгыраша башладылар. Бер бичарасы тагы, менеп җитәм дигәндә, аягы таеп китте дә егылып хур булды.

Нәрсәдән көләргә дип эзләнеп торган киленнәргә, кызларга бу җитә калды, әллә нинди оят сүзләр әйтеп, шаркылдап көлеп:

– Ир булып йөрүең корсын, мескенкәем! – дип, җегетнең адәм күзенә күренерлеген калдырмадылар.

Гыйльминур җиңги дә, дуңгыз, түзмәде:

– Әйдә әле, Гайния, – ди, – ирләр хур булып калсын, шул егылган «җегет»нең агачларын ал да үзең мендер, – ди.

Башка киленнәр дә, моңа кушылып, Гайнияне димләргә керештеләр.

Кыз күп сатулашмады, шәлен баганага элде, яулыгын ияк астына төшереп бәйләде дә минем агачларга килеп тотынды.

Салам төяүчеләр безгә юри күп салалар. Безне әллә нинди оят сүз белән озатып калалар, шаярталар.

Әмма Гайния «эһ» тә итми, минем арттан әллә нинди биек эскертләр башына саламны очыртып кына мендерә.

Бөтенләй хур итәсем килми-килүен! Шулай да кызык өчен бер егуга егам бу кызыйны! Менә җае да чыкты!

Безгә бик күп төягәннәр. Агачлар сыгыла-сыгыла килә... Мин юри эскертнең уң як читенә табарак барам... Гайния кычкыра:

– Син кая тартасың, егасың бит, уңгарак бар! – ди. Тагын чак кына сулга атладым, агачларны шул якка табарак кыйшайттым.

Вәссәлам! – Саламы-нисе белән Гайния ике эскерт арасына ава башлады. Ул арада булмады, шуларга үзем дә кушылып, бергә-бергә тәгәрәп килеп тә төштек.

Шул егылу-аву арасында Гайнияне кочаклап, яңакларына иренемне тидереп кала алдым. Ул, күз ачып йомганчы өстендәге саламнарын актарып ташлады да, япмага таба шаярып көлеп:

– Ай, каһәр төшсен! Мәхәббәтсез, Солтан, урыс, юри екты! – дип кычкырып йөгерде...

Халык бик озаклап көлде, тагын әллә нинди оят сүзләр белән кычкырдылар. Көн буена “бия” дип, “айгыр” дип безне мыскыл иттеләр.

**XXX**

Тән тәнгә тисә, күңелләрдә якынлык арта, диләр.

Дөрес сүз булса кирәк. Шул ашлык сукканда эскерт башыннан кочаклашып бергә егылганнан бирле, безнең арада ниндидер бер нечкә ефәк җеп сузылган кебек булды. Бу җеп көннән-көн калыная бара, кыскара бара, безне һаман-һаман бер-беребезгә якынрак-якынрак тартып китерә, баглый бара кебек иде.

Бүген мин арба төзәткәндә, Гыйльминур җиңгинең сөйләгән хәбәре, аның китергән яулыгы менә шул җепнең бөтенләй-бөтенләй кыскарып җиткәнен, хәзер инде безнең арада, бик нечкә генә бер пәрдәдән башка, бернәрсә калмаганын күрсәтәдер түгелме соң?!

Йөрәгем сизә: минем сәламем аңа ирешкәч, бигрәк тә: «Көтсен, бүген кич аның янына тәрәзә алып керәм», – дигән сүзем ирешкәч, Гайниянең каннары кайнагандыр, ул мине бөтенләй үзенеке итеп, үзен минеке итеп тоя башлагандыр дип өмет итәм.

**XXXI**

Без өйләнгәч, төннәр дә кыскарып китте бит, каһәр төшкәннең!

Өйләнгәч дигән сүзне болай гына, йөрәк әрнүдән генә әйтәм. Юкса, без өйләнеп эшне бетерергә өлгерә алмаган идек әле.

Минекеләр дә, Гайниянекеләр дә ризалар иде. Без, бөтен ил каршында гайбәткә калып, безнең хакта:

Зариф картның кара айгыры
Улак башы кимерә;
Зариф картның Гайниясе
Солтанкай дип тилмерә, –

дигән рәвештә бәетләр дә чыккач, бу бәетләрне урамнарда кычкырып җырлап йөри башлагач, ике як та сүзсез, әллә нинди зур мәһәрләр-фәләннәр турысында сөйләшеп тормыйча ук, безне өйләндермәкчеләр иде. Тик картларның бер генә сүзе бар иде:

– Җәй көне туй ясап, илдә булмаган мөгезне без генә чыгармыйк: эш бетсен, иген-таруны җыеп алыйк, насыйб булса, көзге байлыкта шаулатып туй итәрбез, – диләр иде.

Игеннәр, безнең бәхеткә каршы, искиткеч дәрәҗәдә шәп булып җиткәннәр.

Халык шат иде. Һәркем быелгы иген белән үзенең тереклеген төзәтеп

калырга өмет итә. Бурычлылар – бурычларын түләргә, атсызлар – ат алырга, өйсезләр – өй салырга, улы җиткәннәр – килен алырга, кызы җиткәннәр – кыз биреп туй ясарга, – һәркем шулай бу байлыктан үзенең дөньясын рәтләп калырга уйлый.

Шундый дәртләр, шундый уйлар белән һәркем бил баглап, җиң сызганып, изү чишеп, уракка төште... Һәркем һәр көн үзенең җиренә барып төшкән саен, арышның саламга озынлыгын, башакка туклыгын, көлтәнең күп чыгуын, чүмәләләрнең ешлыгын, зурлыгын күреп, бу өметләр дә, бу уйлар да ныгый бара. Ара-тирә яңгырлар була торганга, тары, карабодайның да шәп булачагына камил ышандылар. Башка нәрсә чәчәргә хәле җитмәгән ярлылар быел үзләренең ун-унбиш таяк тарылары белән дә, һич булмаса, берничә ай тук торуны уйлап, зур дәрт, зур гайрәт белән эшкә – урырга, чабарга тотындылар.

Шундый өметләр, шундый уйлар белән янып, рәхәтләнеп, шатланып, шаулашып эшләп йөргән заманда, көпә-көндез һәммә халык яланда уракта чакта, патшадан фәрман килеп төшә:

– Герман белән сугыш!

– Һәммә ир җаны коралланырга, фронтка китәргә тиеш!

Аяз көндә, димәк, һич көтмәгәндә, яшен сугу ничек әсәр итсә, патшаның бу фәрманы анардан яманрак булды.

Халык аптырый кала. Картлар бөтенләй шашалар:

– Бу ни эш бу?

– Патша хәзрәтләре безнең хәлне белмиме икәнни?

– Аңа әйтәсе иде: бераз кичектер, иген-таруны җыйыйк, аннан соң да сугышка өлгерерсең! – диясе иде.

– Юк шул, аның тирәсен әллә нинди боярлар чолгап алганнар. Болар дөрес хәлне сөйләмиләр булыр!

– Патша хәзрәтләре бездән ерак... Безнең сүзләр, безнең хәлләр аңа барып ирешә алмый! – диешәләр.

## XXXII

Күрәсең, шулайдыр инде! Күрәсең, патша хәзрәтләренең тирәсен чолгап алган боярлар аңа безнең хәлне ирештермиләрдер!..

Басулар елап калды. Ура башланган җирләрне бетерергә түгел, яртылый куелган чүмәләңне очларга да ихтыяр бирмәделәр: патшадан фәрман килеп төшүгә, әллә ничә җегетне, ат мендереп, басуга чыгардылар да, кычкырып, ай-байлап, ай-һай-ау салдырып, һәммә халыкны куып кайтардылар.

Беренче нәүбәттә элек солдат булып хезмәт иткәннәрне кырык яшькәчә сөргәннәр иде; алар китеп, алар өчен түгелгән күз яшьләре кибеп өлгерә

алмады – ополчиннарга[20] хәбәр килде...

Шулар артыннан ук быел караласы никрутларны[21] алып киттеләр...

Әйтерсең, кемдер кулына озын чыбыркы тоткан да хайваннарны, тын алырга, туктап су эчәргә ирек бирмәстән, каядыр куа да куа; куа да куа; куа да куа!

Кая куа torгандыр? – суяргамы, тереләй тунап ашаргамы? – Һичкем һичнәрсә белми.

Безнең елгылар киләсе көзгә каралачак булганга, без: «Кызлар, киленнәр күп, бер ел торасы бар, әйдә тибеп, дөньяны җимертеп калыйк, аннан соң, барыбер үләсе бит!» – дип, шаярыбрак сөйләнеп йөри идек... Мондый вакытларда, күрәсең, айлары елга торадыр; ак кар төшеп, малның йортка керүен дә көтмиләр:

– Рәхим итегез, җегетләр, – дип, безне чакыралар.

Бөтен ил өстенә, әйтерсең, ниндидер кара сөрем күтәрелде. Халык акылыннан яза. Ни дияргә, ни әйтергә белми. Карт-коры әллә нинди юк-бар сүзләр сөйли башладылар.

Бездән ерак түгел зур бер ишан бар. Аның хакында электән үк: «Әүлия икән, кешенең күңелендә ни барын белә икән, алдан биргән хәбәрләре дөрес чыга икән», – дип сөйлиләр иде.

Шул әүлия әйтә имеш, ди, бу, дип әйтә имеш, ахыр заман галәмәте, дип әйтә имеш, ди. Элгәрге изгеләрнең китапларында бу хәлләр алдан хәбәр бирелгәннәр, дип әйтә имеш, ди... Бу патшалар үзара җиде ел сугышырлар, бары да хәлдән таяр, аннан соң, әллә кайдан, диңгез артыннан бер сары патша килеп чыгар да бөтен дөньяны үзенә каратыр, һәммә кешеләрне бер дингә кайтарыр, дип әйтә икән, ди... Аннан соң, дип әйтә икән, ди, Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ кузгалыр[7+], Дәҗҗал чыгар[8+], Мәһди күтәрелер[9+], күктән хәзрәти Гайсә иңәр[10+] ... җир йөзенең асты-өскә әйләнеп буталыр да, кыямәт булыр дип әйтә икән, ди.

Карт-коры, карчык-корчык үзара җыелалар да, тик шундый юк-бар сүзләр, куркынычлар сөйләшеп, күз яше түгәләр, дога кылалар, садака өләшәләр...

Һәркемнән бигрәк аналар кайгыралар... Көн юк, төн юк, аларның күзләре яшьле... Кайда гына очрап, сугышка киткән улы хакында авыз ачма: алар бер-ике сүз дә әйтә алмыйлар.

– Бигрәк бәхетсез заманнарга туры килдегез инде, балалар! – диләр дә, күз яшьләренә буыла-буыла, өзелеп еларга керешәләр.

---

[20] *Ополчиннар* – патша армиясендә: хәрби хезмәттә булмаган яисә яше буенча запаска чыккан кешеләрдән төзелгән хәрби резерв.

[21] *Никрутларны* – рекрутларны.

Атасы сугышка киткән бала-чаганың йөзендә нур калмаган, – болар үзләрен ятим кебек тоялар, ахры... Үлем турында, яраланулар турында берәр сүз ишетсәләр, башларын аска иярәр дә пышык-пышык балавыз сыгарга тотыналар.

Сөйгән ярлар, нечкә билле, кара кашлы, зифа буйлы асыл кызлар, йөрәкләренең тирән катлауларыннан иркәләп асраган җегетләре белән сугышка киткәнгәчә бер күрешеп, бер очрашып калу өчен, бер генә минутка булса да, үз янына кертеп чыгару өчен, актык мәртәбә бер кочып, туйганчы бер үбеп, күкрәгенә баш куеп бер елар өчен чаралар эзлиләр, хәйләләр коралар, ата-аналарын мең юл белән алдалап, аулак өйләргә йөриләр... Көзнең озын, караңгы төннәрендә, өйнең үзләре утырган тәрәзәсенә пәрдә сыман итеп кызыл яулыклар эләләр, – моның белән сөйгән җегетләренә ишарәләр ясыйлар. Ерак җирләрдә, куркыныч, канлы сугышларда сагынып-сагынып карарга булсын дип, кызыл җирлеккә аллы-гөлле чәчәкләр белән кулъяулыклар чигеп, җоннан перчаткалар, кечкенә шарфлар бәйлиләр: боларның матурлыгын арттыру өчен, сөйгән җегет тирән окопларда ятканда боларга карап юанырлык, тагы сагынып-сагынып уйларлык булсын өчен, бу перчаткаларны, бу шарфларны яшелле-кызыллы буяуларга маналар...

Башка вакытлар булса, бер кыз белән сөйләшкән өчен ил тутырып гайбәт чыгаралар иде; төнлә берәр кыз тирәсендә уралганыңны күрсәләр, кабыргаларыңны сындырганчы ваталар иде. Хәзер халык йомшарган – юк-барны күреп, вак-төяккә бәйләнеп маташмыйлар, берәр эте лыгырдый башласа, җегетләр:

– Без хәзер патша кешесе! Башың ике булмаса, безнең тирәдә күп чуалма! – дип кенә җибәрәләр.

Мин Гайнияне еш күрәм. Ил-күз тынгач, карт-коры йоклагач, урам як бакчалары аша барып, аның кызыл яулык корган тәрәзәсен алам да, сәгатьләр буенча аның кочагында дөньяның кайгыларын онытып чыгам.

Адәм түгел, кыз гына да түгел, фәрештә, акыллы матур фәрештә инде минем бәгърем Гайния! Кайсы вакытта, бер генә минутка ялгыз калсак та, йөрәгемә кереп бара бичаракаем – үбеп туя алмый, кочып туя алмый... Минем кочагымда эреп, югалып, һушыннан яза бара, яза бара...

Юлга дип, миңа әллә ничаклы ашамлыклар әзерләгән... Менә дигән перчаткалар, чигүле яулыклар бирде. «Болар миннән сагынмалык булсын», – ди.

Үзе ояла, үзенең күзләрендә бөртек-бөртек яшь мөлдерәп тора:

– Онытма, җаным, мине ташлама!.. – ди. – Котәрмен, айлар, еллар көтәрмен, ди, аяксыз-кулсыз кайтсаң да, син минеке, ди, башкага минем күңелем дә, күзем дә төшми! – ди.

Их, бәгырем, Гайниям! Ничек онытыйм?! Ничек онытыйм?! Сине онытырга мөмкинмени?

**XXXIII**

Ашыктырып куалар. Бүген кич калага барып җитәргә, ди. Аннан иртәгә таңда ук каядыр еракка озатачаклар, ди. Кая булсын, сугыш авызына, кан, үлем эченәдер инде!

Хәерле булсын!

Ни язган булса, шуны күрербез!

Сугышка алалар, үлемгә куалар дип, хатын-кыз шикелле елап торып булмый инде!

Куалар, – барасың!

Сугышка кертеп, туп авызына каршы куялар, – үләсең!

Хуш, бәгырем, Гайниям!..

Хуш, әткәй-әнкәй! Картайган көнегездә сезне хөрмәт итә алмадым – бәхил булыгыз, рәнҗемәгез, бу эшләр миннән түгел бит!

Таңнан ук олаулар әзерләнгәннәр. Старосталар өйдән-өйгә кереп куып йөриләр.

Бөтен авыл кайный, чабалар, йөгерәләр, кычкырышалар, елыйлар, елыйлар, елыйлар!..

Ниндидер бер бәйрәм, – кайгылы бәйрәм, кара, бик кара бәйрәм!

Кәрван-кәрван булып, Зәңгәр чишмәнең уртасыннан – байлар мәчете яныннан басу капкасына чаклы тезелгән арбалар безне алып китәргә әзер торалар.

Бала-чага гөж килә. Әткәй минем арба яныннан үзенең актык сүзләрен әйтә-әйтә бара... Аның йөзендә тирән кайгы җыерчыклары күбәйгән, чәч-сакалы бу көннәрдә агарып бетә язган.

– Сау бул, балам, шатлыклы хәбәрләреңне ишетик, – ди.

Әнкәй, елап һушыннан язган кебек, капка баганасына сөялеп катып калды.

Башкалар да күрешәләр, бәхилләшәләр, елыйлар, – бөтен авыл шулай гөж килә, шаулый, кайгы белән шаулый; бөтен кешеләр, бөтен өйләр өстеннән, әйтерсең, кара сөрем күтәрелә...

Атлар кузгалды...

Кемдер җегетләрдән берсе гармун тартып җибәрде, кемнәрдер бераз исерек, шулай да матур, моңлы, кайгылы тавыш белән озын көйгә сузды:

Сандугачлар килгән безгә,
Китмәсләр микән көзгә?
Язгы сабан туйларына
Кайтырбыз микән без дә?

Бу кайгылы аваз ничектер йөрәк тамырларына төшә, арка үзәкләрдән, аяк буыннарыннан йөреп, күңелгә җыелып тулып килә дә күзләргә яшь китерә...

Сау бул, Агыйдел буйлары, сау бул, Зәңгәр чишмә!

Без авылны чыгып киткәнче Гайния урамнан кермәде, мин күздән югалганчы, бездән күзләрен ала алмыйча, капка баганасына сөялгән хәлдә, карап-озатып калды.

Бичаракаем, зур кәрван безне алып киткәч, түзмәгәндер, елагандыр, мендәренә капланып, үксеп-үксеп елагандыр, бәгырем Гайниям!

Бер Гайния түгел, бик күп Гайнияләр, бик күп Фатыймалар, Хәдичәләр, Рабигалар, Гөлбикәләр шулай капка баганасына сөялеп озатканнардыр да, сөйгән җегетләре куркыныч канлы сугышка китеп күздән югалгач, мендәрләренә капланып елаганнардыр...

Бер минем әнкәй түгел, йөзләрчә, миллионнарча аналар, исәбе-хисабы булмаган балалар, кадерле аталарын, газиз улларын озатып, шулай елаганнардыр, елыйлардыр, еларлар...

Бу күз яшьләре бер Зәңгәр чишмәдә генә, бер матур Агыйдел, Дим буйларында гына түгелдер, дөньяның һәр җирендә шулайдыр...

Әй, Ходай, син кая? Бу җир йөзен каплаган кайгы сөреме син утырган ерак күккә барып ирешмимени? Кая син? Бу аналарның, бу ятимнәрнең күз яшьләре синең күңелне аз гына йомшартмыймени?!

**XXXIV**

Шаһбаз, Гыйлаҗи, Фазыйл, Гали, мин – без барыбыз яшьтәшләр дип йөри идек. Әнкәйләр дә безне бер елгы балалар дип әйтәләр иде, без үзебез дә бер елда каралабыз, бергә солдатка китәбез, бергә-бергә патшага хезмәт итәбез, аннан соң бергә-бергә өйләнәбез, туй ясыйбыз дип уйлый, шулай сөйләшә идек.

Ничектер, башкарак булып чыкты.

Шаһбаз Зәңгәр чишмәгә кайтмады – ул үзенең эшләгән җирендә каралган да шуннан ук сугышка киткән... Фазыйл да Казанда иде. Авылга күренмәде, шунда каралып алынганмы, ничектер, Мәскәүгә барган да лашманчыларга башлык сыман булып урынга кергән.

Сартларны[22], казакъларны солдатка алмыйлар икән... Шулай да... аларны бу якка хайван кебек көтү-көтү куып китерәләр икән дә, әллә нинди кара, пычрак эшкә кушалар икән, шуларга безнең укыганрак кешеләрне башлык ясап, патшага агент куялар икән.

Безнең Фазыйл да үзенең Мәскәүдәге дуслары, байлары аркасында

---

[22] *Сартларны* – үзбәкләрне.

шунда барып сыенган, ди. Аның бу эше күңелемә бер дә, бер дә ошамады! Әллә кайдан китерелгән бичара колларны, чыбыркы тотып, кара, пычрак хезмәткә куып, шуңа башлык булган булып йөрү җегетлекмени ул! Алай иткәнче, үзең солдат бул, үзең сугышка кит тә үз язмышыңны үзең күр!

Әдрисен[23] белсәм, берсеннән бик оста хат яздырып, бик нык шелтәлим әле Фазыйлны!

Әйтермен: «Без кара кеше, надан кеше, шулай булсак та, бөтенләй җүләр түгел: яхшы-яманны аера беләбез, – диярмен. – Ул бичараларны изеп, кол кебек куып йөрергә ялланып, «лашманчы»[11+] булу – синең кебек зур укыган, тирә-якның йолдызы булган бер кешегә килешә торган эш түгел», – диярмен...

Гали дә чарасын тапты.

Байларга нәрсә? Акча күп, танышлык зур. Алтын булгач, докторын да, Алласын да, мулласын, патшасын да сатып алып була икән шул: ике мең тотканнар, диләр... Бәлки, артыграк та булыр – күпме чыкса чыккандыр, Гали шәһәргә барып каралды, – ахрысы бөтенләйгә котылды...

Аның Германиягә баруы файдалы булды, ахрысы, – борыны черемәде, сәламәтлеге чибәр.

Алар хәзер Зәңгәр чишмәгә сыймыйлар инде: Гыйрфан бай, калага барып, зур йорт алды, магазиннар ачканнар. Тормышын шунда күчерде. Бу тирәдән дә өзелеп бетмиләр, Гали Зәңгәр чишмәдәге эшләрен башкара – күбрәк монда тора, ди.

Сөйләүләренә караганда, болар бик шәбәяләр бугай... Сату-алулар бик харап, ди. Агыйдел, Кама буендагы иген сәүдәсе «Гыйрфан-Гали» компаниясенә кереп бетеп бара, ди.

Шәһәрнең иң зур урамнарында квартал-квартал йортларны урыс, жид[*] байларыннан сатып алалар, ди. Хәзер болар шәһәрдә беренче кеше, ди. Үзләре болай һиммәтле кыланалар, ди. Төрле мәктәпләргә, мәдрәсәләргә, кызлар укыту эшләренә, тагы әллә нәрсәләргә бик зур акчалар түгәләр, ди. Китаплар, гәзитәләр чыгарталар, ди.

Шулай итеп, безнең Галигә бәхет ачылды: сугыштан да калды, үзенең күптәнге уйларына да барып җитте: шәһәргә күчеп, анда беренче кеше дә булды.

Шаһбаз бер хат яздырган иде. Ул анда:

«Дөньяны җимерәбез, малай, хәзер чит патша җирләрендә йөрибез. Карпат дигән тау бар икән... безнең Урал моның янында бала гына... Без хәзер менә шул карлы тауны кичеп төшеп барабыз...» – дигән иде...

---

[23] *Әдрисен* – адресын.

[*] 1936 елгы басмада: *яһүд.*

Шуннан соң хәбәре юк...

Ни хәл булгандыр, бик озакка мәгълүм булмады.

Без Гыйлаҗи белән бергә алындык, бергә уйнадык. Бергә фронтка киттек.

Башкалар аяк-кул бозалар, күзгә, колакка агу салалар. Без моңа якын бармадык. Үлсәм үләрмен, әмма үз кулым белән үземне гарип ясап, имгәтеп маташыр хәлем юк. Ни язган – шул булыр...

Гыйлаҗи да, минем кебек, бозуга каршы булса да, ул, никтер, казармадан казармага, фронттан фронтка куылып йөрүне яратмый иде.

Баштан ук күңеленә утыртып куйды:

– Мин, – ди, – Ярманга[24] пленга китәм... Анда дөнья күрәм, эшкә өйрәнәм, – ди.

Эт нәрсә икән! Сүзендә торды, тугыз ай хәбәрсез гаиб булып йөргәннән соң, Ярманның зур бер шәһәреннән хат килде: мин исән-сау, ди; сохари җибәрегез, ди; үзем балта эшенә керештем, ди.

Мин үзем Польша дигән җирдә, әллә нинди сазлыкларда салкын окопта ятам.

---

Шулай, Агыйдел буенда бергә уйнап, бергә үскән җегетләр җир йөзенең әллә кай якларына таралдык та беттек...

Аннан соңгы елларда дөнья кайнады, моңарчы гел бертөсле генә, тыныч кына агып торган тормыш диңгез кебек дулкынлана башлады. Бу дулкыннар, бу өермәләр эчендә еллар үтте, хәлләр үзгәрде, мәңгелек дуслыкта кырыгар мәртәбә ант итешкән безнең иптәшләр үзләре генә таралып калмадылар, күңелләре дә үзгәрде, юллары шул чаклы бер-беренә каршыланды, без бер-беребезнең бугазларыбызга килеп сарылыштык. Бер-беребезнең күкрәкләренә мылтык төзәп атышыр дәрәҗәсенә җитештек. Араларда упкыннар ясалды.

**XXXV**

Петроград. Зур шифаханәләрнең берсе. Киң, биек тәрәзәләрдән язгы кояш яктысы безнең залга агылып тора. Паркетлы идәннәрдә, майлы буяулы диварда аның нурлары уйныйлар. Безнең залның ак, пакь караватларында авыру солдатлар буй-буй тезелеп ятканнар. Баштанаяк ак киенгән кызлар ара-тирә кереп чыгалар...

Болар матурлар, әйбәтләр, йомшак күңеллеләр: иркәләп сүз кушалар, ни әйтсәң дә минуты белән эшләргә тырышалар. Чирлеләр өчен тынычсызлык булмасын диптер инде, акрын сөйлиләр, кергән-чыкканда аяк

---

[24] *Ярманга* – Германиягә мәгънәсендә.

очлары белән генә басып йөриләр...

Тын, тыныч. Тик ара-тирә кайбер хәстәләр генә, ахрысы, каты газапка түзә алмастандыр, – йөрәкләренең әллә кай җирләреннән килгән бер тавыш белән авыр-авыр ыңгырашып алалар. Болар җаннарыңны үтә кисеп төшә. Шундый газаплы, шундый хәсрәтле ыңгырашалар.

Минем уң ягымда Иванов дигән бер солдат бар иде, аның үзе белән дус идек. Якташ та идек. Хәзер җир дә булды, Агыйдел буена кайтып, яңа дөньялар төзербез дип хыялланып ята иде. Өч көн элек бер бөерен ярып алганнар иде. Шуннан җүнләп һушына килә алмады. Уянып, күз ачу белән шуңа карадым – караваты буш, яртылай эчелгән сөте стаканда тора...

Ак киемлеләрнең берсеннән сорадым: кая, мин әйтәм, безнең Иванов, дим.

– Кире кайтмый торган җиргә китте, – ди.

Тагы бер почмакта безнең полкның Абдулла ята иде. Керенскийның[12+] ярдәмчесе Красновка каршы Гатчинада сугышканда[13+] бик зур җегетлек күрсәткән бер солдат иде. Казан ягымын, ди иде. Без, ди торган иде, Керенский егылганны да көтмәдек, күрше боярларның җирләрен җәйдән үк сөреп чәчтек, йортларын тартып алдык... Кайтса өен, урыннарын да тапмасын өчен нигез ташларына чаклы казып алдык та бәрәңге чәчтек, ди торган иде. Безнең Казан ягындагы мөселманнарның җирләре бик аз иде, хәзер яхшы булды... Бу сугышларны бетерәм дә, авылга кайтып, яңа дөнья көтә башлыйм, элгәреге үчне кайтарам – боярдан басып алган җирләрне мамык кебек йомшартып, кадерләп сөрәм, чәчәм дә, адәм кебек көн итәргә тотынам, ди торган иде.

Керенский качып, аның генералы Краснов безнең кулга бирелгәч, Гатчинадан Питерга[25] кайтты да, теге ниндидер бер училищега бикләнеп, безгә каршы сугыш ачкан бай балалары – юнкерлар[14+] белән бәрелешкәндә, бомба ватыгы күкрәгеннәнме, кайдандыр кереп, аркасыннан үтә чыккан... Шулай да нык җегет икән үзе, бичара. Ярасы шундый каты булса да, һаман телдән калмады, Герман сугышларын, Гатчинага баруларын, инде озакламый авылга кайтып, боярдан алган җирләрдә иген чәчеп рәхәтләнәчәген сөйләп ятты.

Иванов хакында: «Кире кайтмый торган җиргә китте», – дигәч, йөрәгем шуу итте. Шул бичара Казан мөселманы Абдулла яткан якка ирексез күз салдым, – аның да караваты – буш. «Ул да кире кайтмый торган җиргә киткәндер, ахрысы!»

Болар мине арыттылар... Хәлем бетте... Ярым йокы, ярым хәлсез...

---

[25] *Питерга* – Петроградка.

Шулай саташа башладым... Германия белән сугыш кебек иде... Урыс солдатлары белән немецлар арасында канлы бәрелешүләр бара... Һавада ике якның аэропланнары, яңгыр алдыннан кузгалган кошлар кебек, кайнашып, бер-берен куып очалар... Алардан безнең өскә ут ява... Бомба ява... Менә арттан безнең авыр туплар кузгалды... Каршыдан Германиянекеләр җавап бирергә тотындылар... Без уттан ясалган өермә эчендә калдык – төн караңгы иде... Нидер булды... Без, язгы ташкын кебек, каты җил белән кузгалган диңгез дулкыннары кебек, каядыр, ни өчендер, җимерелеп, ишерелеп ага, куыла башладык... Белмим, җир йоттымы? – нидер булды... Бер сазлыкта ялгызым калдым... Тирә-як баткак иде... Алдымда бер ялгыз каен тора иде... Су юкмы икән дип, шуңа йөгердем... Барсам, биле урталай өзелгән бер немец солдаты ята... Үзе үлмәгән... Тирә-ягы кан белән тулы... Күзләреннән, белмим, үлем, белмим, җәһәннәм газабы карый... Котым очты, күтәргән штыгым кире төште... Йөгерә башладым... Ул, урталай өзелгән бәндә, миңа кычкырган кебек: «Солтан, кил яңадан... Мине кызган... Мине үтереп кит... Миңа бер селтәү җитә... Газаплама... Минем йөрәгемне сугып яр – ул туктасын, мин тынычланыйм», – дигән кебек булды...

Хәлем бетте... Яңадан борылып карый алмадым... Йөгердем, артыма карамас өчен, ул күзләрдәге үлем газабын яңадан күрмәс өчен барлык көчем белән йөгердем...

Алда бер стансамы, нидер күренде... Бу Гатчина икән. Аның тирә-ягы халык белән гөж килеп кайный иде. Вокзалданмы, каяндыр бер солдат йөгереп чыкты да мылтыклар, сөңгеләр белән коралланган бик күп җегетләр янына килеп кычкырды: «Ура, ура, иптәшләр! Без җиңдек!.. Керенский качкан!.. Ул дуңгызны кулга төшерә алмадык... Керенскийның генералы казачий атаман Краснов бөтен штабы белән безнең кулга эләкте, – ди. – Әнә безнең командир үзе дә килеп җитә», – ди.

Солдат сүзен әйтеп бетерә алмады, автомобильнең ишеге ачылды. Берничә кеше килеп чыкты. Берсеннән күзләремне ала алмый каттым. Буйга минем чаклы була язар... Сабыр, акрын, ләкин җир-күкне үзе артыннан иярткән, тагып алып килгән баһадир кебек көчле салмак атлап килә. Йөзендә әллә нинди бер усал катнаш ачумы, кемгәдер иге-чиге булмаган дошманлыкмы бар... Күзләре үтереп, йөрәгеңне җиңеп карыйлар... Кашлары йөзендә-күзендә булган бу авыр карашны, бу ачы каһәрле дошманлыкны тагы да көчәйтеп күрсәтәләр – болар, ничектер, шул күзләр өстенә корылган тимер калканнар кебек, түбән таба салынып торалар... Бу кешенең бөтен йөзендә тирән акыл, бетмәс-төкәнмәс көч белән бергә, арыслан һәм лачынның икесеннән кушылган бер рәхимсезлек күрдем.

Кемдер: «Менә шул инде безнең кызыл командир», – диде... Ул сөйли

башлады.

Җирнең төбеннән күтәрелде, диңгезләр кичте, кан дәрьяларын үтеп чыкты, әбүҗәһелләрне*[26] үз кулы белән бугазлады, ерак күкләргә менеп, андагы Аллаларны, фәрештәләрне карага, пычракка буяп, богаулап ыргытты, арыслан, лачын күзләре белән алдагы көннәргә бер караш ташлап, бу үлемнәр, каннар эченә, бу газап дөньясына кайдандыр бер тәрәзә ачты: аннан кояш күренде, нур ага башлады, тирә-як чәчәкләр белән тулды... Болар бары да кызыллар иде. Карап туйгысыз матурлар иде. Ахырын тыңлый алмадык, кайдандыр куе кара сөрем күтәрелде, алар кешегә әйләнделәр, кулларында сөңгеләр бар иде, Гали белән Фазыйл шуларның алдында кебек иде...

«Туктагыз!.. Карап килегез!.. Кызыл чәчәкләрне әрәм итәсез бит!» – дип кычкырдым.

Ишетүче булмады. Теге кара сөремнән ясалучылар штыкларын сузып безгә ташландылар.

Кемдер бомба ыргытты... Ыңгыраша башладылар... Аркамнан нәрсәдер җып-җылы булып агадыр булып тоелды, карый алмадым... йөгердем...

Хәлем бетә, егылам...

---

Көннәрме, айлармы, атналармы үткәндер, мин менә шул һәйбәт шифаханәнең ак залында каты авыруларның газаплы ыңгырашулары эчендә уянып китәм...

Ләкин һаман ышана алмыйм...

Бу төшме?.. Саташумы?.. Әллә мин чыннан да Гатчинада контрларга каршы сугышканда каты яраланганмынмы?..

**XXXVI**

Кемдер, аяк очы белән генә басып, яныма килгән кебек булды.

Күземне ачсам, безнең палатаның хатын докторы Анна Федоровна каршымда тора.

– Хәлең ничек? – ди.

– Зарарсыз... Тик әллә нигә бик саташып газапланам, – дим, – бетәрме икән бу? – дим. Хәзер генә ниләр белән саташканымны сөйлим.

– Синең җәрәхәтең бик эчкәре иде... Яра башлагач, доктор да курыккан иде. Ике пуля йөрәк буена барып җиткән... Котылса, бер могҗиза була инде, дигән иде, бәхетең зур икән: инде терeләсең, – ди.

Кулымны карады, култык астына градусник куйды да ридикюленнән[27]

---

* 1936 елгы басмада: *әбүҗәһелләрне* сүзе урынына *дөньяның кара көчләрен* сүзләре килә.

[26] *Әбүҗәһелләрне* – монда: *явызларны, дошманнарны* мәгънәсендә.

[27] *Ридикюленнән* – вак-төяк әйберләрне салу өчен махсус хатын-кызларның кечкенә сумкасы.

кечкенә бер записка чыгарды:

– Синең авылдашың булса кирәк, – ди, – Шаһбаз Фәхриев дигән бер бик үткен командир бер атнадан бирле һәр көн килә дә керергә талаша. Хәлең авыр булганга, кертмәдек, менә бүген ул миңа записка калдырган. Укып бирегез дигән, – ди.

Кай арада укырга-язарга өйрәнгән бу җегет – мин бераз гаҗәпсенәм.

Марҗа укып бирде:

«Дускай, Солтан, ун көн инде иртә-кич синең лазаретны таптыйм. Кертмиләр... Һушына килде дигәч, бүген сиңа записка калдырам. Без тиздән фронтка китәбез. Шуңарчы ничек кенә булса да сине күрәсе иде. Бик сагындым! Зәңгәр чишмә – Агыйдел буйларын бер сөйләшеп утырыр идек.

Шаһбаз – 1918 – март».

Белмим, шатландым, белмим, нәрсәгәдер тагы җаным әрни иде, нидер булды, – култык астымдагы яра чәнчеп-чәнчеп ала башлады. Бу чәнчү күкрәгемә, кулбашларыма менде. Аннан соң бөтен тамырларым буенча билемә, аякларыма төште – тагы хәлсезләндем, тагы артыграк өзелдем... Бу газап белән тагы арып, йоклапмы, онытылыпмы киттем...

**XXXVII**

Адәм җаны – эт җаны, диләр. Бик дөрес сүз.

Дөньяның җәһәннәмнәрен кичтем. Герман штыкларыннан яраландым. Керенский, Краснов казачийларының, Петроград юнкерларының бомбаларыннан газапландым... Өч мәртәбә ярдылар...

Мин һаман тере. Мин тагы аякта.

Рәхмәт инде докторларга да: яшермәделәр, куркыныч зур, диделәр; теләмәсәң, көчләмибез, диделәр; ярдырмасаң, барыбер рәхәтләнеп йөри алмассың, диделәр.

– Ни булса, шул булыр... Казачий пулясын йөрәк астында асрар хәлем юк! Гомер буенча елап-сыктап яшәгәнче, гарип имгәк булып кеше күзенә карап көн иткәнче үлгәнең мең мәртәбә артык! Йә үтерегез, йә мине яңадан адәм ясагыз, – дидем.

Ярганнан өч ай вакыт үтмәде, мин акрынлап йөри башладым.

Докторлар әйтәләр: шулай даруланып, тыныч кына ятсаң, язгы сабан туйларына чаклы элекке кебек таза җегет булырсың, диләр. Болар мине никтер яраталар, күңелемне күтәрергә тырышалар, шаярталар. Шундый күңелле сүзләр, матур өметләр белән үз алдыма шатланып, яңа дөньяга килгән бала кебек, башымдагы хыялларга, тәрәзәдән төшкән кояш нурларының паркетлы идәннәрдә, шома диварларда, түшәмнәрдә уйнавына сокланып, рәхәт кенә ята идем, кемдер тиз-тиз безнең палатага килде, ишекне

ачып туктады да:

– Солтан Уразбаев иптәш бу палатада булса кирәк, аның ятагы кайда икән? – дип, бераз ватык, шулай да җиңел урысча тел белән сорады.

Төрле яктан авырулар, баш күтәреп:

– Солтан, синең якташ килгән, тор! – дияргә өлгерә алмадылар, мин атылып барып дустым Шаһбазны кочакладым.

Их, дөнья! Адәм бу чаклы үзгәрсә үзгәрә икән! Әгәр юлда очрасам иде, каршымдагы кызыл фуражкалы, шпорлы, яхшы френчле, баштанаяк кораллы, йөзе әллә ничә җирдән яралы бу җегетне минем Зәңгәр чишмәдәге дустым Шаһбаздыр дип ялгыш та уйлый алмас идем.

Шатлыгым башыма сыймый. Иптәшне беленнән кочаклап алам да ятагым янына урындыкка китереп утыртам. Үзем аңа каршы утырам.

Ашыгыч исәнлек-саулык турында сөйлибез. Мин күземне аңардан ала алмыйм.

Безнең күрешмәгәнгә дүрт ел үткән иде. Шул заман эчендә җегетем камил ир булып, чыныгып җитешкән, йөзендә акыл төсе арткан. Күзләрендә әллә ничаклы көрәш, әллә ничаклы гайрәт ялтырый. Кашлары калынайган. Ахрысы, сакал-мыек бик куе үсмәкчедер, нык кырылса да, яңаклары, мыек урыннары бераз күгәреп торалар.

Аның йөзендә, күзендә генә түгел, тавышында, бөтен торышында, аяк атлашында да ниндидер бер көч, ниндидер бер авыр көрәштә чыныкканлык сизелеп тора. Әйтерсең, җәһәннәм утларында кайналып, корычланып чыккан бер җегет, – менә шулай күренде миңа Шаһбаз дустым.

Ниләр башлап, ниләргә күчкәнбездер, ашыгыч аннан-моннан үз хәлләребезне сөйләп үттек. Ул, Герман сугышында[15+] яраланып, Петроградта яткан... Патшаны төшергән көннәрдә терелеп дөньяга чыккан... Шуннан бирле туктаусыз дулкыннар эчендә кайный икән. Гатчина сугышында, Мәскәүдә юнкерлар белән бәрелешүләрдә, белмим, тагы әллә кайларда булган. Иртәгә Донга – Кубаньга китәбез, ди.

– Анда, – ди, – Корнилов[16+], Каледин[17+] дигән собакалар безнең муеннарга богаулар әзерләп маташалар бугай, ди. Шуларны изеп ташлыйсы бар, – ди.

Сүз үзеннән-үзе туган илләргә, нечкә билләргә, элекке дусларга күчте.

Шаһбаз күптән түгел безнең илгә барган икән. Анда безнең прапорлар – җилбәзәкләр белән мөселман байлары, муллалар иман укып, тәкбир әйтеп, яшьләрне, мөгаллимнәрне суеп, үтереп, ерактагы Дутов[18+] планынча безгә каршы «борай фронты» дигән бер бәла чыгарып, халыкны әвәрә кылганнар икән!

– Шул этләрнең кара ояларын туздырып, үзләрен таратып кайтырга

миңа тапшырганнар иде, – ди, – бер мәшһүр татар контры оештырган бу ләгънәтләрне бетерергә барганда, көтелмәгән бер җирдә, Гыйлаҗины күрдем, – ди.

– Ну, ну, – мин әйтәм, – ни эшләгән безнең ул җегет? – дим.

Шаһбаз бераз көлде.

– Бирешми ул безнең каһарман! – ди. – Үзе теләп, алдашып, Германиягә әсир төшкән. Анда да һаман балта эше белән йөргән. Ике мәртәбә качып тотылган. Өченче катында кыйналып, сул кулын сындыртып, бер атна урманнарда, сазлыкларда ач йөреп, ахырында ничектер бер җай белән Россиягә кайтып егылган. Бөтен бер әкият аның сөйләгәннәре, – ди.

– Хәзер ни эшли?

– Зәгыйфь дип кайтарганнар икән. Җан түзмәде ди: тагы калага барып, мөселман солдатлары арасында эшләргә тотынган.

Сүз шунда җиткәч, нәүбәтче кереп кыңгырау шылтыратты:

– Вакыт җитте, хәл белергә килүчеләр чыксыннар, – ди.

Шаһбаз иртәгә фронтка китә. Яңадан йә күрешә алырбыз, йә юк. Сүзләребезнең уннан бере дә бетмәде. Мин, нәүбәтчегә барып, моны аңлаттым: «Бу иптәш – иртәгә фронтка китәчәк отрядның командиры; сез аңа рөхсәт итегез, тагы азрак утырырга», – дидем.

Марҗа кырт кисте:

– Мөмкин түгел! – ди.

Мин яңадан бәйләнә башлагач:

– Минем хакым юк. Бик каласы килсә, комиссар Зингль иптәштән барып сорасын. Ул рөхсәт бирсә, калыр, – ди.

Шаһбаз, бер минутта, «ярый» дип язылган кәгазьне китерде.

Без иркенләп сүзгә керештек.

## XXXVIII

Барыннан бигрәк Гыйлаҗи хакындагы хикәя миңа кызык тоелды.

Иптәшем үзе дә аны көлке итеп сөйли. Миңа бигрәк тә күңелле булып чыкты.

– Германия тубыннан сындырылган кулны төзәтеп авылда ята идем, дип әйтеп әйтә ди, бер базар көн, дип әйтә ди, телеграм алынды. Бөтен тирә-як шау күтәрде... Патша төшкән имеш, сугыш бетә имеш, байлар, боярлар кулындагы барлык җирләрне крестьянга бирәләр имеш, диделәр. Халыкны волость конторына җыеп алып бардым да бунт күтәрдем... Урядникне[28] канга туздырганчы[*] изеп, салкын бүлмәгә яптым... Старшинаны эт итеп кыйнап, урыныннан төшердем. Николайның[19+] сурәтен алып, тәрәзәдән ыргыттым да,

[28] *Урядникне* – Патша Россиясендә өяз полициясенең түбән чинын.
[*] 1936 елгы басмада: *батырганчы.*

малайларга таптарга, ерткалап таратып атырга бирдем.

Аннан соң, дип әйтеп әйтә ди Гыйлаҗи, ни барын, ни булачагын аңлар өчен калага киттем, дип әйтә ди.

Барсам, ни күрим: шәһәр гөж килә. Губернаторлар, исправниклар[29] бары да очкан!

Кайсы ябылган, кайбере качкан, ди.

Казармага барып керсәм, дөньяның асты өскә килеп бара.

Элек борынын күккә күтәреп йөргән әфисәрләр[30] хәзер шым булганнар. Элекке кебек аяк тибеп кычкыруларның исе дә калмаган. Алар хәзер безнең солдатка да, ничектер, кыенсынып, оялыбрак булса да: «Әфәнде» дип, «господин» дип эндәшәләр. Ә, шулаймы, дим, хәзер без дә господамы, дим. Җитәр, мин әйтәм, сез бик күп заманнар үзегез генә әфәнде булып йөрдегез! – дип әйтеп әйттем дип әйтә, ди.

Солдат арасында әллә ниләр бар. Җыр, музыка, кычкырыш, талаш... Китап, теләгәнчә гәҗит – бары да ирек! Җитмәсә тагын, үзләренә кәмитит[31] төзеп алганнар. Болар, яңгырдан соң чыккан гөмбә кебек, дөньяны каплап бара: кая карама – анда кәмитит, кая карама – анда липутат[32]... Бер җирдә шулай: җитәр инде, элгәре дә безне күп изделәр, дип кычкырыбрак сөйләгән идем, тоттылар да үземне липутат итеп сайладылар... – дип әйтә ди.

Курка калдым: йа Ходай, мин әйтәм, мин анда ни эшләрмен? дим. Шулай да сер бирмим. Ни булса, шул булыр, кеше ни эшләсә, мин дә шуны эшләрмен, барыйм әле, дип әйтеп әйттем дип әйтә, ди.

Элгәре вакытта урамнан караганда да куркып, патша килсә, мөгаен шунда төшәр иде дип хәйран булып үтә торган зур бер сарайның ак мәрмәр баскычларыннан тартына-тартына гына мендек.

Зур, матур бер зал. Бер башта яшел өстәл тора. Аннан соң шуңа карап бик күп урындыклар тезелгәннәр. Стеналарда киң кызыл комачларга әллә нинди сүзләр язып элгәннәр. Арада безнеңчә язулар да күренә. Курка-курка гына бер читкә барып утырдым.

Тиз арада халык тулды. Бары да минем кебек соры шинельле солдатлар икән. Боларны күргәч, бераз хәл керде.

Тик алда калкуга куелган яшел өстәл тирәсендә генә яшьрәк әфисәрме, укымышлырак шома солдатмы кебек нәрсәләр күренәләр.

Арттан кемдер:

– Җыелып беттеләр, ачарга вакыт! – дип кычкырды.

---

[29] *Исправниклар* – революциягә кадәрге Россиядә өяз полициясе башлыгы.
[30] *Әфисәрләр* – офицерлар.
[31] *Кәмитит* – комитет.
[32] *Липутат* – депутат.

Нәрсәне ачарлардыр, аңламадым, шул яшел өстәл тирәсендәге бер шома җегет кыңгырау шылтыратты да сөйли башлады. Башкалар да бер-бер артлы чыгып сайрадылар.

Карадым да каттым: телләре телгә йокмый – шундый матур, ипле сөйлиләр.

Сүз мөселман солдатларын үзләренә башка роталарга аеру турында икән...

– Казан башка булыр, тормыш башка булыр, җомганы бәйрәм итәрсез, бергә-бергә укырга, зиһен ачарга да уңай булыр, диләр... Үзем дә дәртләнеп киттем. Сикереп тордым да:

– Ник каршы торырга, – мин әйтәм. – Дуңгыз ите дигәннәре, дим, бик көчле сүз түгел, дим. Ходай үзе кичерсен, дим, кяфер кулында тоткын булгач, башта җирәнебрәк булса да, мин әйтәм, ашадык инде, дим. Хәзер, дим, бер өйрәнгәч, тәмле дә, туклыклы да кебек тоела, – дим. – Шулай да, мин әйтәм, аерым рота ясауга без каршы түгел, дим. Агай-эне үзара бергәрәк җыелып тору – күңелле булыр, дим. Бергә уйныйсың, гармун тартасың, җырлыйсың, дим. Рәхәтләнеп авыл хәлләрен сөйләшәсең, шулай бит, иптәшләр, – дим.

Сүземне әйтеп бетерә алмадым, бөтен зал шау күтәреп миңа кул чаптылар.

Сөйләүчеләр беткәндер, ахры, – теге шома җегетләрнең берсе аягүрә басты, кыңгырау шылтыратты да матур, шома тавыш белән:

– Алай булгач, иптәшләр, мин тавышка куям, – диде. – Каршы кешеләр кул күтәрә, риза булучылар тик утыра, – диде.

Без һәммәбез дә кулларны югары суздык. Өстәл тирәсендәгеләр аптырап калды. Теге шома җегет тагы:

– Хәзер инде каршылар тик утырсын, риза булучылар кул күтәрсен, – диде.

Тагын безнең куллар һәммәсе күтәрелде.

Шома җегетләр түзмәделәр, үзара җылмаештылар да торып аңлаттылар.

Ә, мин әйтәм, алаймы?.. Хәзер инде саташтыра алмаслар.

– Кем каршы?

Һичкем кузгалмый.

– Кем риза?

Һәммә куллар түшәмгә сузылды, дип сөйли, ди, безнең Гыйлаҗи.

Шаһбазның Гыйлаҗи хакындагы хикәясе шул җиргә җиткәч, нәүбәтче марҗа яңадан керде:

– Тиздән докторлар керә. Сез чыгыгыз инде! – ди.

Без карышмадык, өстемә аксыл сары халатны салдым, аякка йомшак башмакны кидем дә, коридор башына кадәрле озатыйм дип, Шаһбаз белән мин дә чыктым.

**XXXIX**

Озаклап сөйләшергә вакыт юк иде. Аерым-аерым сораша бардым.

– Гыйлаҗи шуннан соң ни эшләгән? Шаһбаз яңадан көлде:

– Ул бит зирәк җегет. Тиз аңлаган. Монда безнең Петроградта эшләрнең үзгәрүен көтмичә үк, тирә-як крестьяннарын җыеп барган да боярларның җирләрен сөреп чәчкән... Өйләрен мәктәпләргә, фәкыйрьләргә өләшкән. Шунда безнең Галиләрнең дә мең дисәтинәгә якын җирләре киткән бугай. Хәтерең дәдер, алар, сугыш башлангач, теге князь Долгоруковның[20+] бөтен имениеләре белән җирләрен сатып алганнар иде бит. Шуны ике татар, бер чуваш, бер урыс – барлыгы дүрт авыл җыелып барганнар да үзара бүлешкәннәр.

– Хәзер ни эшли Гыйлаҗи?

– Эш безнең кулга күчкәч, аны тотканнар да, көчләп, безнең өязгә җир комиссары ясаганнар.

– Әйттем, дип әйтә ди: мин ул эшләрне булдыра алмам... Мин җүнләп кул да куя алмыйм бит, дип әйттем, ди.

– Юк, дип әйтәләр, диде, ди, без сиңа доклад хәзерләтергә, кирәгеңне язарга галим урыслар бирәбез. Кул куя белмәсәң, тамга салырсың, дип әйттеләр, дип әйтә ди.

– Ярар, дип әйттем, ди, боярларның тамырын корткачы мин комиссар булам. Аннан соң комиссарлыктан мине коткарырсыз да, зур йортлар, зур күперләр салу эшенә җибәрерсез, дип әйттем, ди.

Риза булдылар, ди.

Шаһбаз сүз арасында Гали белән Фазыйлны телгә алса да, ничектер, аларга чәнчеп үткән иде. Бу дуслар хакында сүз кузгаткач, аның кашы җыерылды:

– Нәрсә булсын, иптәш! Акрынлап асылларына кайталар. Гали ачыктан-ачык байларны безгә каршы оештыра, ди. Дутовка яшертен акча җыя имеш, диләр...

– Фазыйл?

– Ул да калышмаска тырыша бугай – әллә нинди оешмалар корып, төрек-татар байрагы дип, дин, милләт өчен бергә барыйк, аерылмыйк дип лаф ора, шулай дип гәзит яза, съездларда кычкыра бугай... Әмма эшләгән эше бөтенләй байлар файдасына таба бара, ди.

Бу хакта бер нәрсә дә ишеткәнем юк иде, шул изге күңелле, акыллы күзле, якын дустымның андый юлга кереп китүен башыма сыйдыра алмадым.

– Ничек, – мин әйтәм, – алай булыр икән ул?

– Менә ничек, – ди, – безнең губернада Учредилка[21+] вакытында ике список чыккан. Берсе халыкныкы – ... нче номер [*], берсе байларныкы – ... нче номер. Болар арасында зур талаш булган, урыны-урыны белән сугышка да җиткәләгәннәр бугай... Галиләр, Фазыйллар, кара мөфтиләр бары да байларныкын – ...нче номерны яклаганнар. Безнең Гыйлаҗилар бары да – ...нче номер ягында булганнар.

– Кем җиңгән икән?

– Билгеле, кем җиңгән: Фазыйллар бер кеше, Гыйлаҗилар өчме-бишме кеше үткәргәннәр.

Сүзнең иге-чиге булыр кебек күренмәде. Дустымнан аерыласым килмәсә дә, нәүбәтче марҗа яңадан килеп, доктор, сезне чакыра дигәч, озак-озак үбешеп аерылыштык.

Мин үземнең җылы, якты палатама кердем.

Шаһбаз кайтып китте.

Аның бүгенге төне тыныч булачак. Иртәгә ул фронтка – Донда, Кубаньда безнең муеннарга иске богауларны кайтарырга көч җыеп маташучы генералларга каршы сугышырга, тагы кан, газап, үлем эченә китәчәк!

Аннан соң кая барыр? Алда аны, мине, безнең кебек миллионнар, ун миллионнарча җегетләрне нәрсә көтә?

Шаһбазны, Гыйлаҗины, Фазыйлны, Галине яңадан бер күрә алырмынмы?

Без тагы элекке кебек Зәңгәр чишмә буенда, Агыйдел ярларында җыела алырбызмы? – Әллә төрлебез төрле җирләрдә, төрле фронтларда каберләребезне табарбызмы? – белмим.

Белмим дә, ул турыда күп уйларга да яратмыйм.

Ни булса шул булыр, тизрәк терелим дә, шул зур юлга, зур дулкынга яңадан кереп китим!

Докторлар, язгы сабан туйларына сәламәтләнеп җитәрсең, дигәннәр иде.

Әллә ни булды, яңадан кан коелды, яңадан бер ара авыр саташулар кичердем.

Лазареттан чыккач та, көне-сәгате белән Петроград дулкыннарыннан ычкынып булмады.

Юлда да безнең авырулар вагонын вокзалларның саботажник чиновниклары ике урында юри өзеп калдырып, берничә көнне әрәм иттеләр.

---

[*] Чыганакта: №* дип бирелә.

Мәскәүдә, шулай ук Нижний, Богородский, Чаллы пристаньнарында да бераз тоткарлык ясадылар.

Шул мәшәкатьләр соңында, үзебезнең туган илгә бер ай отпускага дип кайтып җиткән көннәрдә, Агыйделнең киң болыннарында чалгы тавышлары ишетелә башлаган; тормышның ул каты дулкыннарыннан азгамы, күпкәме читтә калган җегетләр, картлар, ирләре сугышка киткәч чалгы тотарга өйрәнгән таза beләкле киленнәр, агалары, аталары фронтка киткән кызлар, киек казлар кебек тезелеп-тезелеп, печән чабарга тотынганнар иде инде.

**XL**

Мин көрәшне яратам.

Көрәшсез үткән көннәрне әрәм саныйм. Каты көрәш дулкыннары арасында минем җаным рәхәтләнә, йөрәгем үзенә көч ала, гайрәт ала.

Авылда бер ай тыныч кына хәл җыйсам, камил тазарып җитәрмен дә, яңадан шул канлы көрәш өермәләре мине үз эчләренә тартып алырлар дип, Идел ярына басар-басмас, үз алдыма уйлап куйган идем.

Ай түгел, атна түгел, бер көн, бер сәгать көтәргә дә ирек бирмәделәр.

Мин Зәңгәр чишмәгә җәяүләп, аркама әйберләремне асып килеп кергәндә, кояш батып бара иде инде. Күперне чыккач та, нindидер зур гауга, шау-шу ишеттем. Кемнәрдер кычкыралар, талашалар, кемнәрдер елыйлармы, үзләрен-үзләре яклап әрләшәләрме, – белмим, нидер бар, нидер кузгалган, нидер дулкынлана. Түбән оч тыкрыкларын үттем. Базар мәхәлләсенә, байлар урамына якынлап барам. Алдымда, минем юлыма буе белән, безнең Гыйлаҗи дуслар эшләгән зур, мәһабәт, матур мәчет утыра. Зәңгәр чишмә күле ягыннан килгән шәфәкъ кызыллыгы фарыз бүлмәсенең тәрәзәләренә төшкән, ерактан ут кебек кызарып яналар. Алда тавыш көчәйгәннән-көчәя бара.

Чү! Бу ни эш? Кемдер, нәрсәдер рәттән өч мәртәбә атып җибәрде!

Моны ишетүгә кулларым ирексез кобурыма сузылды. «Наганым исәнме икән, урынындамы икән?» – дип капшап карадым. Бу миңа кадерле нәрсә: бер казачий батальонны аз көч белән юкка чыгарган өчен командир иптәшнең фәрманы буенча бүләк иткәннәр иде. Егермегә якын пулясы бар. Эшләве гаҗәп дәрәҗәдә яхшы. Иске режим вакытында төз ату өчен медаль алган кулларымда бу наган булса, бернәрсәдән дә курыкмаска мөмкин.

Шул уйлар белән алга барам.

Күңелемә кинәт бер нәрсә килде: тукта әле, кайдадыр юлда, пароходтамы, берәр стансадамы[33] чех дип, словак дип, нидер лыгырдаганнар иде түгелме соң?.. Йөз мең кеше, имеш, баштанаяк кораллылар, имеш, Самарны[34] алганнармы, алалармы, имеш, аннан башка калаларга китәләр,

[33] *Стансадамы* – станциядәме.
[34] *Самарны* – Самара шәһәрен.

имеш... Белмәм, тагы шундый «имеш-мимешләр» сөйләгәннәр иде...

Мин:

– Без андыйларны күп күрдек инде! – дип кенә куйган, ул турыда бер дә уйлап тормый үткән идем.

Мин пароходлардан урап кайтканчы, әллә шундый бер этләр тагы безнең кәрванга өрә башлаганнармы? Каным кыза, йөрәгем суга, аякларым үзләреннән-үзләре ашыгалар.

Бу чатта миңа өй ягына – уңга таба китәргә тиеш иде. Уйлап-нитеп тормадым, сулга борылдым да базар мәйданы ягына киттем.

Мәчетне, Гыйрфан байның зур таш кибетләрен үтсәм, бөтенләй шаша калдым. Көтелмәгән, уйга килмәгән, килми торган бер күренеш!

Базарның уртасында печән үлчи торган баганаларга берничә кеше аякларыннан югары асылганнар. Боларның берсе безнең авылда дүрт ел буе балалар укыткан мөгаллимә Хәдичә иде. Болар тереләрдерме, үлеләрдерме, белеп булмый. Куллары салынып төшкән, йөзләре адәм карагысыз булып яраланган... Кан тамчылары җиргә тамалар... Бу асылганнар тирәсе кара болыт кебек, туфан кебек халык көтүе белән кайный. Кычкыралар... талашалар... Нәрсәдер берсеннән-берсе тарткалап алырга тырышалар... Белмим, һәммәсе акылдан шашкан, белмим, кыямәт булган: кешеләр ни эшләгәннәрен белмиләр, күзләрен кан баскан... Ниндидер бер көч белән әле бер якка, әле икенче якка кузгалып, шау-шу белән, гауга белән дулкынланалар. Боларның башында зур бер командир кебек безнең Гали йөри. Аның да күзләре канлы, тавышы карлыккан, үзе анда йөгерә, монда йөгерә, шул бозык гырылдавыклы тавыш белән бертуктаусыз акырына:

– Җәмәгать, көткән көннәрегез килеп җитте. Сез котыласыз... Форсатны качырмагыз...

Аптырап Галинең өстенә карадым; башында эфисәр фуражкасы, аякта шпорлы ялтыр итек, беләктә ак тасма, кулында менә дигән маузер!

Үземне-үзем белмәдем:

– Гали, синме? Бу ни эш? – дип кычкырып, аңа барып тотындым.

Халык тынды, минем билдәге наганны күргәч, беразы, куркып, икегә аерылдылар.

Ләкин Гали үзен-үзе югалтмады, канлы күзләре белән миңа бер генә мәртәбә карады да, бераз кире чигенеп, әллә нинди зәһәрле, каһәрле тавыш белән:

– Ә... алаймы? Асыл кош үзе килеп аягыннан эләктеме?.. Җәмәгать, менә сезгә Солтан Уразбаев!.. Дөньяны туздыручыларның иң яманнарыннан берсе! Тотыгыз да бәйләгез моны! – дип кычкырды.

Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, кемнәрдер мине тотарга килә

башладылар.

Үземне-үзем сизмәстән, наганымны суырып алдым да:

– Кем миңа кагыла?.. – дип, рәттән дүрт мәртәбә як-якка аттым.

Халык, лачыннан качкан чәүкә көтүе кебек, куркышып, читкә таралды. Урталыктагы ачыклыкка карасам, ниндидер бер гәүдә ыңгырашып ята. Йөрәгемә нидер чәнечте, таныш кебек булды, дөньяны онытып, шул ыңгырашкан гәүдәгә ташландым.

Ни күрим?

– Су, бер генә тамчы су! – дип, чак-чак ишетерлек бер тавыш белән саташып, ыңгырашып, минем дустым Гыйлаҗи ята.

Күтәреп алыйм дип иелсәм, муеныма аркан салдылар. Шунда ук кул-аягымны бәйләргә азаплана башладылар.

Кайдандыр безнең күпер башында торган чактагы күрше Сафа бабай килеп чыкты да мине якларга теләде:

– Җәмәгать, моның ни гөнаһсы бар? Бу бит ата-анасын күрергә кунакка кайтып килә, – диде.

Ул арада Гыйлаҗиның атасы Зариф оста белән минем эткәй килеп чыктылар. Шау-шу яңадан күтәрелде. Шаһбазның агасы, аның артыннан башка вакытта җыеннарда сирәк күренә торган безнең иске күршеләр, авылның читләрендә, балчык читән өйләрдә яшәүчеләр, атасыннан, төп йорттан куылып чыгып, читләрдә өйдәш торучылар телгә килделәр:

– Көпә-көндез адәм үтерәсез!

– Бу ни эш!.. Чех дип, ул чаклы масаймагыз!..

– Безнең очта да яңадан бәйрәм булыр әле! – дип кычкыра-кычкыра, мине коткардылар.

Гыйлаҗины, аркылы агачка салып, өенә алып киттеләр.

**XLI**

Бездән унике чакрымлык стансадан дошманның беренче этрәте[*35] кичә көндез сәгать икеләрдә үтеп киткән икән. Гыйлаҗи үзенең ике иптәше белән Зәңгәр чишмә һәм Ивановка арасында Гыйрфан байның җирен – урманын бүлешү турында чыккан бер аңлашылмауны тикшерергә килгәннәр икән. Чехларның килеп җитүе[22+] белән, Гали коралланып чыккан да, унбиш-егерме кеше белән конторны килеп баскан, Гыйлаҗиларны шунда ук кыйнап, өстерәп, базар мәйданына чыгарганнар. Ике иптәшен, авылдагы бер мөгаллимәне асканнар. Безнең дусны кыйналудан коткара алмасалар да, күз күргән кеше булганга, асарга ирек бирмәгәннәр икән.

Мин, өйгә кайтып бу хәбәрне сөйләтергә, Гайнияне күрергә дә өлгерә

---

[*] 1936 елгы басмада – *отряды.*

[35] *Этрәте* – отряды.

алмадым, Сафа бабай килеп җитте: яланаяк, күлмәкчән, үзе йөгерә-йөгерә арып, гыжылдап беткән:

– Солтан балакай, ди, сине барыбер әрәм итәрләр... Анда иске урәтникләр, элекке староста белән старшиналар, земски нәчәлникләр – бары да Гали байга җыелганнар! – ди... – Насыйб булса, дөньялар тынычлангач, яңадан кайтып, әткәң-әнкәңне күрерсең... Бер минут торма, хәзер кит! – ди. – Дөньяның берәр җирендә безнекеләр бардыр әле, шуларны эзләп табарсың үзең! – ди.

Әткәй киенә башлады, әнкәй үзен-үзе белмичә, елап, һушыннан язып калды, – мин, Зариф осталарга кереп, Гыйлаҗиның хәлен белдем: өметсез түгел күренә, бер кулы сынган, кабыргалары ватылган. Шулай да йөрәге эшли. Тик бичараның бер күзен әрәм иткәннәр – чукыпмы, сугыпмы, уң күзен чыгарганнар, аның урынында укмашкан кызыл кан белән сузылып-сузылып чыккан тамырлар гына күренә. Аның карт белән карчыгы туктаусыз елыйлар.

Гайния агарынган, иреннәре дерелди, күзләрендә бетмәс-төкәнмәс җәфа-хәсрәт бар. Шулай да нык икән. Әллә нинди сулар, үләннәр, яфраклар, тозлар җыйнаган да, әҗәл эчендә яткан агасын юып, бәйләп йөри. Мине күрүгә күзләре нурланды. Аз гына да тартынмады, качмады:

– Илаһым, хуҗам! Бу хәлдә күрергә өмет итмәгән идек. Сине дә шулай әрәм итмәсәләр ярар иде!.. – дип, ак алъяпкыч белән яшьле күзләрен сөртеп, яңадан агасын карарга тотынды.

Сөйләргә, юатырга вакыт юк иде:

– Без озакламабыз, яңадан кайтырбыз, – дидем дә исәнләшеп чыгып киттем.

Сафа бабай белән әткәй мине Агыйдел ярынача озатып, көймә белән аша чыгардылар.

Зур юллардан, авыллардан бару куркыныч булганга, мин болыннар, таулар, урманнар ашасыннан китәргә булдым.

Агыйдел элеккечә шаулап ага калды, аркама әйберләремне аскан хәлдә, мин, болындагы таллар арасында салынган сукмак белән, калага карап юл тоттым.

Ничек кенә булса да, Фазыйлны күрергә, аның аркылы Гыйлаҗины бу котырган этләр авызыннан коткарырга кирәк.

Күп таулар кичеп, күп чокырларда йоклап, бөтенләй икенче киемдә калага барып керсәм, яңа дөньяга чыккан кебек булдым. Аксыл күк киемле ят эфисәрләр автомобильләрдә очалар. Киенеп, ясанып, шәһәр урамнарын каплаган матур кызлар, яртылай тәннәре ачылып йөргән гаҗәеп чибәр яшь хатыннар бу «каһарманнарга» чәчәкләр ташлыйлар, күзләрен нурландырып,

ул чит мәмләкәт командирларына сөеп җылмаялар.

Болар да ят, болар да яңа этләр. Әмма боларның һәммәсеннән бигрәк Фазыйлларның исеме кайный:

– Фазыйл гәзитәдә нидер язган... Дин-милләт өчен кайгырган.

– Фазыйл кайдадыр, нидер сөйләгән... Дини-милли әмәлгә, хезмәткә чакырган. Фазыйллар, чех-словакларны яклап, этрәт төзиләр.

– Фазыйл кемнәрнедер тоттырган... Дин-милләт дошманнарын бетергән.

– Фазыйл, кемнәрнедер атарга кирәк дип, список төзеп биргән... Советка каршы сугыш ачкан!

– Фазыйл кемнәрнедер, башкорт авылларында яталар имеш дип, эзләп китерү өчен агентлар чакырткан! Советчы кызылларны үтертергә план корган! Большевикларны кырдырырга планнар төзеп йөргән! – дигән сүзләрнең уңнан да, сулдан да колакка керүе, аның исеменең телләрдә йөрүе мине таң-хәйранга калдырды.

Сугыш башыннан бирле бу шәһәргә аяк басканым юк, шуңа күрә кем дә булса таныр, тотып бирерләр дип шикләнмим. Бөтенләй башка, нәкъ кырык тартмачы Шәрәфи абзый булып киенүем, чәч-мыекны да шулай ясатуым – миңа куркынычны тагы да азайта.

Фазыйлны биш көн эзләдем. Алтынчы көнне зур бер йорттан беләгенә ак тасма таккан матур, әйбәт бер яшь эфисәр һәм дә баштанаяк ак ефәктән киенгән яшь сылу бер кыз белән көлешә-көлешә сөйләшеп чыкканда очраттым. (Эчемнән генә бу фәрештәне Гәүһәрдер дип уйладым.) Тартынмадым, бардым да ят тавыш белән, ләкин күзләренә туры карап:

– Фазыйл абзый, мин Зәңгәр чишмәдән килдем. Әткәгезнең йомышы бар иде, – дидем.

Үткен җегет бит безнең Фазыйл: акыллы күзләре белән миңа бер генә мәртәбә текәлеп карады да, янындагыларга:

– Гафуыгызны үтенәм, миңа этидән ашыгыч йомыш бар икән! – дип, кулларын кысып, юлдашларыннан аерылды.

Аның квартиры ниндидер бер зур байда икән. Туры шуңа бардык. Гаҗәеп матур бай бүлмә, китаплар, гәзитләр белән тулы.

Ишекне бикләп, ачкычын кесәсенә салды, йомшак креслога утырды да миңа текәлеп карады:

– Йә, нинди эш сине миңа китерде?

Мин сөйләп бирдем:

– Нык кыйналса да, әле үләрлек түгел... Аны монда хөкемгә озатачак булып калдылар... Бәлки, китергәннәрдер дә... Син ул котырган этләрдән Гыйлаҗины коткарырга тиешле!

Кыйммәтле папиросны капты, берничә әйләнде дә, кинәт минем алдыма тукталды. Күзем аның калын алтын сәгать бавына, аягындагы сары шиблетына[36], үтә ак якасына төште. Ул, ахры, минем күз карашымны сизгәндер, яңадан китеп, язу өстәленең бер читенә барып утырды:

– Менә нәрсә, – ди, – Солтан туган: син бераз соңгарак калгансың!

– Ничек алай, әллә син инде Гыйлаҗины да бетерттеңме?.. Мөселманнарны бит синнән киңәшмичә атмыйлар, диләр.

– Синең алдыңда рия сатарга теләмим... Чынын әйтәм, Гыйлаҗи миңа килеп эләксә, аны коткарырга тырышыр идем. Ләкин зур хаталык булган: атасы әрәм иткән!

Мин сикереп тордым да аның өстенә бардым:

– Дөресен сөйлә, юкса үзеңне шул җирдә атып үтерәм дә качам.

Фазыйл көлде; күзеннән, йөзеннән ниндидер бер яшерен хәсрәт йөгергән кебек булды:

– Юк, мин ялганламыйм, дөресе шул: кыйналган кичнең иртәсендә, башкалар турында хәбәр сөйләр дип, безнең Галиләр Гыйлаҗины арбага салганнар да монда җибәргәннәр; атасы Зариф карт та калмый озата килгән икән. Калага җитәр алдыннан, Идел тугаенда, бу ахмак бабай, бер эш белән туктаган чакта, азрак хәлләнә башлаган улын җилкәсенә күтәрепме, ничектер, агач арасына алып кереп китә башлаган. Каравыл бер сүзсез шул җирдә тоткан да артларыннан аткан. Зариф та, Гыйлаҗи да шул җирдә җан биргәннәр.

Мин артык сүз әйтмәдем:

– Беләбез без андый качуларны! – Качкан вакытта ал яктан йөрәккә атуларны! – дидем дә чыгып киттем.

**XLII**

Көн киттем, төн киттем.

Бөек Уралның таулары арасында зур күлләр буена салынган заводларны, шахталарны кичтем. Башымны кая куярга гаҗиз булган минутларда бу җирләрнең эшче хатыннарына туры барып кердем. Кем икәнемне сорамыйча ук белделәр. Ашатып-эчертеп, юлыма икмәк биреп җибәрделәр.

Зур, матур җәйләүләрдә күп җылкылар белән кымыз ясап яткан данлыклы башкорт илләрендә булдым. Бер юлаучы[37] булып, ыруғның олы аталарында берәр тәгәч[38] кымыз эчеп чыктым.

Данлыклы Ирәмәлнең[23+] итәгендә, Җаек белән Агыйделнең башлап

---

[36] *Шиблетына* – шнурлы яисә як-яклары резинкалы ирләр ботинкасына.
[37] *Юлаучы* – юлда йөрүче.
[38] *Тәгәч* – кымыз, чәй кебек нәрсәләр эчәр өчен кечкенә агач савыт.

чишмәләнеп чыккан җирләрендә озак юлда көйгән йөзләремне юдым, көмеш кебек саф, боз кебек салкын сулары белән янган йөрәкләремне бастырдым. Бөек Корташ[24+] тавының ялангач ташлары өстенә утырып хәл алдым, – шул тауның башыннан сөйгәне егылып һәлак булгач, кайгылы йөрәкнең чыгарган җырларын җырлап, якты кояшка, биек тауларның башларында ялгызы шаулап утырган агачларга карый-карый, тагы алга киттем.

Күп адашулардан, күп эзләнүләрдән соң, арып, хәлдән таеп, авырып, данлыклы бер партизан гаскәргә барып егылдым; бу – тереләй бирелергә теләмәгән берничә мең эшче җегет берләшеп, Белориттан[25+] – Верх-Уралдан[26+] башлап, дүрт яктан дошманның һөҗүме астында ут ярып бара торган, барган саен көче минем кебек ирләрнең кушылуы белән һаман арта торган, шулай бара-бара дошман туфрагы эчендә үзенә утыз мең гаскәр җыйнап, кояш чыгышы ягыннан – Ирәмәл – Корташ буеннан алып, кояш батышына – Камага таба бөек Уралны аша кичеп чыккан, шундый гайрәт белән сигез ай ут эчендә, сугыш эчендә бара-бара, яктылыкка барып ирешкән мәшһүр Каширин – Блюхер әтрәте[27+] иде.

Дошманның күкрәгеннән чыгып, җир астыннан үсеп күтәрелгән бу утыз меңлек әтрәтнең язмышы чиктән тыш бер тәвәккәлгә – тик каһарманлыкка гына багланган булса да, боларга килеп кавышу миңа мөэмин* күңелнең үз туган иленә тыныч кайтып кергәч кенә таба торган бер бәхетен, бер рәхәтен бирде. Дүрт якта дошман булса да, һәрбер адымны тик сугышып кына атласак та, күңел ышанадыр иде: кайдадыр яктылык бар, кайчан да булса без шуңа ирешербез, ди идек.

Йөрәк ялгышмады, кызыл яктыга барып чыктык. Бераздан чехны да бетердек.

Аннан соң мин авылга кайттым.

**XLIII**

Чех белән Учредилка арасында булган оятсыз зинадан бер бала дөньяга килде[28+]. Уйнаштан туып, ай үсәсен көн үскән, ел үсәсен ай үскән аждаһа, тиз арада төрле диннәрнең, төрле кавемнәрнең әбү җәһелләрен** үз тирәсенә җыйды да, кара болыт, куркыныч караңгы туфан булып, бөтен Себерне, Уралны каплап алды, Волга буена сузылып ятып, Мәскәүне йотарга авызын ачты.

Сабан-суканы, балта-чүкечне ташладык.

Кулга кылыч алдык та бу гыйфритне куа киттек.

Казан – Иркутски арасындагы тауларны, елгаларны, сахраларны сигез ай эчендә үттек, Себернең тайгаларында бу аждаһаларның башын өзеп,

---

* 1936 елгы басмада: *гарип.*

** 1936 елгы басмада: *кара көчләрен*. Монда: “дошманнарын” мәгънәсендә.

этләргә ашаттык.

Шуның белән инде тынычландык дияргә өлгерә алмадык – берсе Балтыйктан, икенчесе Кара диңгездән тагы ике куркыныч җылан чыкты да, берсе – Мәскәүне, берсе – Петроградны йотарга башларын суздылар[29+].

Кулдагы кылычларны куеп, бер таяк җир сөрә алмадык, бер өйнең түбәсен ябарга вакыт булмады, тагы коралландык – тагы боларны куа киттек.

Берсен Балтыйкка батырдык. Икенчесен Кырымның матур йөзем бакчалары, аллы-гөлле чәчәкле ярлары буенча йөрәк канын агыза-агыза, Кара диңгезгә куып төшердек.

– Инде тындык!

– Инде сабан-сукага!

– Инде җимерек өйләрне төзәтергә! – дигәндә, иң ышанычлы саналган Кронштадтның кызыл туфрагын кайдандыр искән җилләр белән нindидер кара корым, тузан каплады, кызыл әләмне таплады[30+].

Түзмәдем, җаным әрнеде, үзем теләп киттем.

Бөек крепостьларның тишекләреннән авызлары безгә каратып куелган зур тупларның өзлексез яудырган утларына каршы боз өстеннән күкрәк белән шуып бара идек... Өстебезгә ут ява иде... Ләкин без һаман шуа идек...

Кинәт янымда нидер җенләнеп шартлады. Карасам: уң аягым үземнән дүрт таяк җирдә, читтә, ялгызы канап ята.

Петроградта ике, Мәскәүдә биш, – барысы җиде ай лазаретта яттым. Өзелгән аякларымның, түгелгән каннарымның билгесе булсын дип, күкрәгем Кызыл йолдыз[30a+] белән зиннәтләнде. Бу – йөрәгем өчен иң кадерлесе булды. Күннән, агачтан, резиннан миңа аяк ясадылар.

Зарарлы түгел, култык таягы белән йөрергә уңай булачак.

Озатырга бер юлдаш бирделәр.

Лазаретларда күп ятып, буш араларда ике телдә дә укырга-язарга өйрәнеп җиткән идем инде, мондый җирләргә тиз арада әллә килеп була, әллә юк дип, бик күп китап җыйдым.

Шулай итеп, юлга чыктык.

Мәскәүдән кузгалгач, өч атна үтте дигәндә, урманнар, болыннар, матур яшеллекләр белән киенеп, аллы-кызыллы[*] чәчәкләр белән бизәнеп җиткән, иген басуларында яшелле-көрәнле солылар, тарылар арасында карабодайның ак чәчәкләре җирне каплап, тирә-якны бал исе белән хушландыра башлаган, биек тау итәкләрендә кыйбла кояшының нурларына йөзе белән караган җирләрдә каен җиләкләре, җир җиләкләре тулып, кызарып, пешеп килгән чакларда, матур аяз көннәрнең берендә, мин тагы үзебезнең Агыйдел буена –

---

[*] 1936 елгы басмада: *аллы-гөлле.*

Зәңгәр чишмәгә кайтып төштем.

**XLIV**

Соңгы атлар алмашкан Ивановка чувашы:

– Кызыл инвалидны ярты сәгатьтә илтеп җиткерим әле, – дип шаяра-шаяра, иң яхшы күк юргасын[39] төпкә, алмачуар чабышкысын мичәүгә[40] җигеп, минем каршы торуыма карамастан, кыңгырау да таккан иде.

Зәңгәр чишмәгә җитеп, күпердән тузан туздырып чабып чыгуга, төрле урамнардан, төрле өйләрдән миңа баш иеп, кул селкеп калдылар. Безнең иске чүплек башындагы күршебез Сафа бабай, танырга тырышкан кеше кебек, кулларын күз өстенә куеп карады да шатлыгыннан ботларына кулларын чапты. Берничә җирдә балалар, мине танып:

– Солтан абзый килә!.. Солтан абзый!.. Һу... әллә-лә... әллә!.. – дип, йөгереп, чыбыркы шартлатып озаттылар.

Шулай балаларны шаулатып, карт-корыга сәлам биреп, баш иеп бара торгач, базар мәчете ягыннан уңга, үзебезнең урамга борылыйм гына дигәндә, кемдер арттан кычкырды:

– Солтан туган, син бугай... Ялгыш китәсең, әнкәң хәзер Гыйрфан бай йортында, – диде.

Зур урам белән туры киттек.

Гыйрфан байның зур капкаларын ачтырып, ике ягы яшел түбәле келәтләр, лабазлар, складлар белән әйләндерелгән киң ишек алдына барып кергәндә, урам яктагы ике катлы биек сарайдан, нидер сөйләшеп, көлешеп, бик күп яшьләр, кызлар, җегетләр чыгып киләләр иде. Боларны күргәч, Гайния искә төште. Ләкин арада ул юк иде.

Мине күрүгә, урта буйлы, шадра йөзле, киселгән чәчле бер кыз, кулларын чабып, кычкырып җибәрде:

– А... Солтан абзый кайтты!.. Солтан абзый!..

Байның кайчандыр үзе торган бу зур матур сараен хәзер колхоз өчен мәктәп белән клубка алганнар икән... Авылның яшьләр түгәрәге белән ячейкасы, берләшеп, гаеткә каршы музыка-әдәбият кичәсе куймакчылар да, бүген шуңа репетиция ясап чыгып киләләр икән. Арбадан төшкәнне дә көтмәделәр:

– Солтан абзый, Солтан абзый!.. – дип, мине сырып алдылар; бер-берсен бүлә-бүлә, үз хәлләрен сөйләргә, миннән бер-бер артлы сорашырга тотындылар.

Әйберләремне, ясалма аягымны, таягымны, төрле кулга тараттылар да, арада тазарак ике җегет үземне ике яктан култыклап, җилтерәтеп:

---

[39] *Юргасын* – юргалап бара торган атын.

[40] *Мичәүгә* – янга.

– Әйдә, менә монда синең әниең, – дип, бакча эчендә, кайчандыр безнең әткәй белән Зариф бабай мәрхүмнәр эшләп биргән алты почмаклы өйгә алып киттеләр.

Баягы кыска чәчле, сандалилы шадра кыз без арбадан төшмәс борын – алдан әнигә:

– Галимә әби, сөенеч, улың кайтты!.. – дип йөгергән икән.

Без бакчага керүгә, өй эченнән әни килеп чыкты.

Аны күргәч, мин хәйран булдым*. Бичаракаем, бу соңгы өч ел эчендә ун еллык картайган: чәчләре ап-ак, яңаклары эчкә суырылган, күзләре әллә кая төпкә батканнар, йөзендә тирән-тирән җыерчыклар буйга-аркылыга сузылганнар, биле бөкрәеп, буе кечкенә генә булып калган; җитмәсә, куллары да калтырыйлар.

Ахрысы, догада, намазда утырган чагы булгандыр, бармак араларында озын тәсбих асылып тора.

Мине күрүгә:

– Ай, балам... Бу җирләрдә ризыкларың бетмәгән икән әле... – диде дә кочаклап катты. Елый да, артык сүз дә әйтә алмады.

Өй чибәр генә, пөхтә генә күренә. Рәхмәт инде, карчыкны урамга ташламаганнар.

Әткәйнең вафатын, Колчак сугышы[31+] вакытында туп төшеп, безнең элекке өйнең янып бетүен ишеткән идем, әнинең кайда урнашуын белә алмый идем.

Байның үз заманыннан калган нәрсәләредер инде: бер почмакта зур карават, ике тәрәзә арасында зур гына көзге, ике өстәл, берничә урындык, идәндә безнең теге өйдән килгән киез, караватта да безнең элекке түшәк-ястыклар, мендәрләр, юрганнар өелеп торалар.

Мин әнинең хәлен сорашып бетерергә өлгерә алмадым, яшьләр каяндыр май, йомырка, сөт, икмәк тә табып китерделәр. Үзләре һаман бер-бер артлы сөйлиләр, сорашалар иде.

Баягы кыска чәчле шадра кыз миңа туры карап торды да:

– Әткәй сине бик ярата иде... Исән-сау кайтсын дип һаман тели иде, – диде.

Мин аны танымадым:

– Сез кем кызы буласыз, сеңелем?

Кыз үпкәләгән тавыш белән бераз иркәләнде:

– Абау! Харап икән! Үзегезнең борынгы күршегезне шулай истән чыгарырга ярыймыни?.. Мин сезне бер дә онытмадым... Кечкенә булсам да,

---

* 1936 елгы басмада: *калдым*.

мин сезгә ияреп җиләккә йөри идем, – диде.

Мин дә төсмерләдем:

– Хәзер таныйм: сез Сафа бабай кызы Миңҗамал бит!

Комсомол кыз шатланып китте.

– Ярый, бөтенләй хәтердән чыгармагансыз икән әле без яшьләрне, – диде дә, һичкемнән сорамыйча-нитмичә, камил хуҗа хатыны кебек, өстәлгә чәйне әзерләде, безгә ясап эчерә башлады.

Сүз акрынлап эзгә керде.

Гыйлаҗины сагындылар. Бик тырышып эзләсәк тә, каберләрен таба алмадык. Халык сөйләве буенча, атылган җирләренә: «Яшьләрдән – Зариф бабай белән Гыйлаҗетдин абзыйга», – дип, таш яздырып куйдык, диләр.

Кемнәр киткән, кемнәр үтерелгән, кемнәр Себердән хур-сәргәрдән[41] булып кайткан – шуларның барын берәм-берәм сөйләделәр, үтерелгән мөгаллимәләрне сагындылар.

Сүз боларга җиткәч, Миңҗамал тагы телгә килде:

– Гыйрфан байның кызын беләсездер, шул аталары, Хәлил муллалар, тагы әллә кемнәр белән бергә Себергә качкан иде. Иркутскида әллә нинди бер татар эфисәренә кияүгә чыккан икән. Бер фетнә өчен ирен атканнар. Кая барырга белмичә, кире Зәңгәр чишмәгә кайтты. Хәзер безнең клубта күчереп язучы булып хезмәт итә, ди. Без аңа, ди, паек бирәбез, жалуния бирәбез, – ди.

Әллә кемнәр, әллә нәрсәләр турында төрле тавыш белән сайрадылар-сайрадылар да:

– Без сезгә күңелсезләнергә ирек бирмәбез... Һәрвакыт тик тә яткырмабыз... Дүшәмбе көн безнең уртак кичәдә өзелгән аягыңның тарихын сөйләрсең, Зәңгәр чишмә буйлары мондый хәлләрне ишетергә бик сусаганнар... ярыймы? – дип, миннән кат-кат вәгъдәләр алгач, шаулашып чыгып киттеләр.

Ләкин, никтер, Гайнияне берсе дә телгә алмады.

---

Күрәсең, шулай мин дә Зәңгәр чишмәдә калам инде.

Бусы озакка – гомергә калу булыр.

Бер аяк белән чит илләргә китеп йөрү мөмкин булмаганга, мин инде калган көчемне шушы Агыйдел буйларына багышлармындыр, ахрысы. Эшләрмен, Гайния минем юлдашым булыр.

**XLV**

Кич Гыйрфан бай кызы керде.

Дөнья дигәнең өйрәтә бит адәм балаларын: элгәре кызыл чәчәкләр

---

[41] *Хур-сәргәрдән* – мәсхәрә булудан.

өстендә очынып кына йөри торган ак күбәләкләр кебек матур, ләкин җиңел холыклы бер туташ иде бу. Тормыш нидер? Хәсрәт нидер? – белми иде. Һәркайда матурлык эзли, шуннан башканы күрми, бик аз нәрсәләр өчен дә үзенең саф көмеш тавышы белән бөтен бакчаны җанландырып көлә иде.

Хәзер тавышында да элекке сафлык юк. Алай музыкалы да түгел. Бераз басынкы... Бераз гына булса да, эш турында, дөнья турында уйлый, сөйләгәнне тыңлый белә.

Элекке иркә, матур йөздә хәзер бик аз гына җитдилек күренә. Күзләрендә, – ул тирә-якка нур чәчә, уен-көлке чәчә, җиңеллек чәчә торган күзләрендә дә, – хәзер элекке нурлар, элекке иркәлекләр өстенә, ниндидер бер уй катнаш акыл пәрдәсе капланып тора.

Авыр язмышлары хакында кайбер нәрсәләр ишеткәнем бар иде. Шуңа күрә яраларына кагылмаска тырышам. Күбрәк үзем сөйләү ягын алга сөрәм, ләкин кыз һич берен* яшерми, яки яшерә алмый.

Кайчан Зәңгәр чишмәдән унбиш йөккә төянеп чыгып китәләр... Ничек дөньяның әллә кай җирләреннән куыла-сөрелә килгән качаклар кәрванына кушылып, бергә агалар... Шуннан соң кайларда булалар, ниләр күрәләр, ахырда үзе тагын ничек монда кайтып егыла – һәммәсен, һәммәсен авыр, фаҗигый хәсрәт белән сөйләп бирә.

Иң авыры бу туташ белән Галигә төшкән икән. Үлем, фәхеш – бары бергә.

Ул үзе, Себер сахралары буенча качаклар кәрваны белән агылып барганда, бер яшь, матур татар прапорщигына гашыйк була. «Күзләре чибәр иде, күңелле сүзләр белән көлдерә белә иде», – ди. Әтиләренең ай-ваена карамый, шуңа кияүгә чыга да фронтта кала. Атналар, айлар йөргәннән соң, гаскәр бүленә дә, болар безнең кулга эләгәләр. Безгә хезмәт итә башлыйлар. Җегет ниндидер бер кара пычрак җинаятьтә гаепләнә – аталар. Бай кызы, карынындагы ике айлык баласы белән, япанда ялгыз калган кебек хәлгә төшә. Актык балдакларын сата-сата, Томскига килә дә бер урыс әфисәре белән тора башлый... Аерылалар...

Аннан соң бер татар спекулянты юл буенча аны үзенә сөяркә ясап, изеп, калага чаклы китерә дә ташлый.

Гыйрфан бай болай җиңелмәгән... Япониягә җитмичә тукталмыйм, дип киткән иде, ди, сүзендә торды, ди. Үзеннән туры хәбәр юк... Хәзер Харбинда[32+] имеш, япон белән зур сәүдә йөртә имеш, дип сөйлиләр, ди. Моңа җаным әрнеде. Иң элек шундый этләрне атарга кирәк иде бит.

Базар баганасына дүрт кешене аскан Галигә ярыйсы эләккән, ул, иске

---

* 1936 елгы басмада: *серен*.

гадәтенчә, ике мәртәбә зур акча белән гаскәрлектән котыла. Тик Колчак ягында ирекле агитатор булып, совет сүгеп, контрланып йөри.

Гаскәрлектән кача дип, кайдадыр, өстеннән әләклиләр... Алдыралар... Фронтка озаталар...

Акларда ярым-ярты прапорщик булып китә. Колчак дөмеккәч, безгә чыга. Бераз зинданда утырталар. Яңадан сату-алуга тотынып карый. Әләктерәләр, ябып чыгаралар. Тыштан советчы күренсә дә, ышанучы булмый.

Ахырдан, Семипалат[33+] шәһәренә килеп, атналар, айлар буенча туктамый, көн-төн эчә башлый, соңра, көзге караңгы төннәрнең берсендә, бүлмә ишегенә аркылы агач куя, тәрәзәләрнең калын пәрдәләрен бөтенләй төшерә дә, наганындагы актык бер пуля белән үзен-үзе атып үтерә.

Боларны сөйләгәндә кыз, ридикюленнән яулык чыгарып, яшьле күзләрен сөртте дә абзасының актык сүзләре язылган кәгазь кисәген миңа бирде...

Бераз җирәндем, нәрсәгә мондый пычракны миңа бирәләр, дип уйладым. Шулай да совет, революция дошманының ничек дөмегүен беләсем килде.

Бер читкә: «Бу язуны Шаһбаз белән Солтанга күрсәтсәгез иде», – дип куелган.

Ашыгыч күз йөртәм:

«Сез төзәчәк тормышны мин күтәрә алмыйм... Элекке көннәрнең, элекке идеалларның кайчан да булса яңадан бер кайтуына иманым калмады... Мал бетте... Йорт-җир китте... Дәрт, вөҗдан да кайдадыр югалды. Әйтегез, ни белән яшим?..» – ди.

Фазыйлның аталары Заһит муллалар да шулай таралганнар. Мулла үзе Семипалат шәһәрендә тифтан үлә. Остазбикәсе акылдан яза. Хәзер кайда икәне мәгълүм түгел, ди.

Тик Фазыйл үзе генә һаман бирешми икән әле. Колчактан өмет киселгәч, Фазыйл мең азап белән башкортларга килеп кушыла. Шулар аркасында үзен коткара. Бөтенләй безнең якка чыга. Советчы булып китә.

Хәзер инде партиядә әгъза*, ди. Бик тырышып, бил баглап безнең юлда эшли имеш.

«Хата булды безнең элекке юллар... Әрәмгә кан түктек без. Революцияне аңламый харап булдык», – ди имеш, ди.

...Үзе Мәскәүдә тора, ди. Татар җөмһүриятенә комиссар итеп чакырганнар иде, хәзергә бармадым әле, дип әйтә имеш, ди.

---

* 1936 елгы басмада: *кандидат.*

Фазыйл хакында бу кызның теге вакыттагы ачуы – үзен алырга теләмәве йөрәгендә нык саклана булса кирәк.

Сүз ул тирәгә җиткәч, туташның күзләрендә ниндидер бер әрнү катнаш үпкә ялтырый. Гүя, әгәр дә шул вакыт Фазыйл мине яшь, гөнаһсыз, бай көемчә, артымнан килгән малым белән алган булса иде, бу хәсрәтләр аңа да, миңа да килмәс иде, дигән бер уй яшен тизлеге белән аның миеннән үтә, – миңа шулай тоелды.

Ул кинәт урыныннан кузгала:

– Сезне бик арыттым бугай... Гафу итегез... – ди.

– Рәхмәт, – дим. – Күп хәбәрләр сөйләдегез, – дим. Сузган кулын кысам. Ләкин бу куллар инде, ахры, байтак нәрсә күргәннәрдер... Элгәре мамык кебек йомшак, нечкә, ак, озын бармаклар хәзер тупасланганнар. Соңгы 2-3 еллар аны шулай үзгәрткәннәр. Исәнләшеп чыга башлый:

– Сезгә бик рәхмәт, йөрәгем бераз бушады, – ди.

– Фазыйлның үзеннән хат юкмы? – дим.

– Миңа юк... Сезгә тапшырырга дигән бер мәктүбе[42] күптән ята, – ди. Үзе матур иркәләнеп[*] җылмая.

Мин шелтәлим:

– Бу ни эш? Сез аны ник миңа алып килмәгәнсез?

Ул иркәләнде, күзләрендә элекке заманның нуры, куштанлыгы ялтырап китте. Шулай бит ул җылан халык. Кирәгендә куштанлык белән алдырмак була. Матур җылмаеп, билен, башын бик аз гына боргалады да, якын тавыш белән:[**]

– Сезнең белән тагын бер мәртәбә озаклап сөйләшеп утырырга сылтау булсын өчен, мин аны бу юлы юри китермәдем, – диде. – Иртәгә кич, – ди, – миңа чәйгә рәхим итегез! Мин сезгә күрше: үзебезнең элекке өйнең, хәзерге мәктәпнең кечерәк бүлмәсен миңа бирделәр. Мин аны курчак өе кебек матур тотам... Килегез. Хатны да шунда укырсыз. Ярый бит? – ди.

Бераз ачуым кабарды. Мин, кызыл фронтчы инвалид, ни эшләп аның бүлмәсенә өстерәлим инде? Башканы белә, менә бу кечкенә нәрсәне аңламый. Ни әйтсәң дә, буржуа валчыгы шул.

– Рәхмәт, – дидем, – бик ватылып кайтканмын... Аннан соң миңа бит сезнең ул сарайларыгызга менеп-төшеп йөрүләр уен түгел икәнен үзегез дә беләсез! – дим.

---

[42] *Мәктүбе* – хаты.

[*] 1936 елгы басмада: *матур иркәләнеп сүзләре* урынына *кыланып* сүзе килә.

[**] 1936 елгы басмада: бу җөмлә *Ул, тагын чытлыкланып:*

Кызның йөзенә, күзенә хәсрәтле төс чыкты, гүя элекке вакытларын хәтерләде:

– Ни эшләмәк кирәк? Таулар Мөхәммәдкә килмәсәләр, Мөхәммәд үзе аларга барырга тиеш диләр[34+] бугай... Ярый, иртәгә килермен...

– Хәерле кич!

– Хәерле кич! – дип кулларымны кысты да, чыгып китте.

**XLVI**

Яшьләр белән ячейканың бергәләшеп куйган «театр»лары гаҗиб дәрәҗәдә җанлы, күңелле булып чыкты. Бик сусаганнар булса кирәк, авылның бөтен халкы диярлек – ире-хатыны, карты-карчыгы, баласы-чагасы, килене-кызы, җегет-җиләне – һәммәсе Гыйрфан байның йорты эченә тулган иде. Байның зур заллары да бу чаклы җәмәгатьне сыйдыра алмаслык булганга, бик күпләр күрүдән мәхрүм калдылар – кире киттеләр, яки ишектән, тәрәзәдән тыңлап, карап азапландылар...

Кичәдә беренче нәрсә – Минҗамал оештырган хорның җыры иде. Шундый күңелле, моңлы чыгардылар ки, озын хәсрәт көенә:

Агыйделкәйләрнең яры биек,
Менеп тә генәй бара бер киек;
Су сипмәгән дә генәй гөлләр кебек,
Көтәмен янып, көеп...

дигән җырлар белән моңланганда зал үлем тынлыгына батты.* Халык кайда икәнен онытты, шул тирән хәсрәтле моң белән, шул музыка уңаена Агыйдел буйлап актылар, шулай агып барганда, ике яктагы биек тауларга, аллы-кызыллы чәчәкләргә карап, хәйран булдылар. Шул зур елгалар, карт урманнар, шул матур чәчәкләр арасында аккан каннарның, түгелгән күз яшьләренең, чигелгән хәсрәтләрнең һәммәсе йөрәктән күтәрелеп башка менделәр, аннан дөньяны каплап каттылар да, аккош балалары кебек тезелеп, моңланган яшьләрнең саф музыкалары белән каядыр югала башладылар, күккә таба менеп, безне коткаралар кебек булды.

Кул чабу һичкемнең хәтеренә килмәде, музыканың, җырның туктаганын, музыкантлар чыгып китеп, сәхнә буш калгач кына аңлый алдылар. Кичәдәге башка нәрсәләр дә, ничектер, халыкның йөрәгенә ятты.

Монда тамашачы белән уйнаучыны аеру кыен иде. Сәхнә белән зал, ничектер, күңелдән берләшәләр кебек, бергә уйныйлар, бергә җырлыйлар, бергә бииләр кебек иде.

Ахырдан мине дә көчләделәр.

Аякны куйдым, култык таягына таяндым да күтәрелдем.

---

*1936 елгы басмада бу җөмлә: *Шундый күңелле, моңлы чыгардылар ки, күтәренке көйгә җырланган бу җырлар йөрәкләрне ашкындырдылар.*

– «Өзелгән уң аяк», – дип, шаяртыбрак сүз башлаган идем, үзем белмәстән, зурга китеп барылган. Дүрт еллык революция дулкыннары халыкның күз алдыннан шаулап үтте... бары да сөйләнде.

Буржуа кәгъбәсендәге потлар җимерелде*... Хәзерге заман контрларының башлары өзелде... Себер сазлыкларыннан, Балтыйк, Кара диңгез баткаклыкларыннан күтәрелеп, безне йотарга куркыныч авызларын ачып килгән аждаһалар кылыч белән туракланды, нәҗес сөякләре утка ягылды... Дөньяның төрле караңгы почмакларыннан кара туфан булып безне батырырга – юк итәргә килгән барлык кара көчләр бер селтәүдә үзләре йөзтүбән китте... Революция кылычы контрларны шулай юкка чыгарды.

Үземне оныттым: халык та минем сүзне ишетми, шул дулкыннарның шаулап бәрелешүләрен үз күзе белән карап утыра кебек иде. Меңнәрчә, миллионнарча Гыйлаҗиларның түгелгән каннары, меңнәрчә, йөз меңнәрчә Солтаннарның өзелгән аяклары – болар һәммәсе әнә шул бөек диңгез дулкыннары эчендә бер тамчы гына булып калды.

Хәлем бетте... Күз алларым караңгыланды. Авызым кипте.

– Туганнар, бүгенгә җитәр, – дидем.

Артык көчләмәделәр. Алкышлап күтәреп алдылар да су бирделәр.

Мин дә, бераз һушымны җыеп, як-ягыма карандым.

**XLVII**

Дошман кыз тагын килеп бәйләнде. Әйтерсең, каеннан кайнатылган сагыз: шулай чат ябыша. Моны – хатынмы, туташмы, ханыммы, белмим – әйтерсең, гомеремдә беренче күрәм. Шулай булып үзгәргән иде ул бүген.

Буе озын, тал чыбыктай зифа... Озынча аксыл йөзендәге, зур күгелҗем күзләрендәге яшь матурлык бүген, ничектер, тирән бер мәгънә белән нурланганнар. Нурмы, хәйләме, белмим. Фронттан соң ышанмас булганмын.

Бетте, һәммә нәрсә бетте, дип зарланса да, калганы бар икән әле: аякларындагы матур укалы туфлиләр уйнап тора... Өстендә ак җефәктән тегелгән платье, зифа буйны тагы да сылурак итеп тартып, билне, күкрәкне күзгә матурлап күрсәтә... Садә, ләкин килешле ясалган прическа аны тагы да ача төшә... Үзе элекке уенчак күбәләк тә, кичәге хәсрәтле ханым да түгел: тышкы җиңел уенчаклык, иркәлек белән эчке хәсрәтле тирәнлек бергә җыелган кебек матур тойгы бирәләр. Моңа ачуым кабара. Бу матурлыклар безнең җилкәне кимерде бит, дим.

Кичәнең башында беренчелек роле Миңҗамалда кебек иде. Гыйрфан кызы читтән килгән кунак кебек, ятрак булып йөри иде... Ике пәрдә дә үтмәде – ул үзеннән үзе күтәрелде, "үз" булып китте. Авыл җегетләре белән

---

* 1936 елгы басмада: *Буржуа тормышының нигезе җимерелде...*

матур итеп куштанлана, алар белән чәнчешеп ала, картлар белән карчыкларның күңелләренә дә бер-ике ятыш сүз әйтеп үтә... Кызларның калфакларын төзәтеп куя, бер дә рәнҗетмәслек рәвештә, бу платьеның менә бу сырларын ешайта төшсәң, тагы матур буласы, дип киңәшләр бирә.

Шулай бер кичәдә һәммәнең якыны, дусты булып киткәндәй күренә.

Сафа карт аңа гаҗәпләнебрәк карый:

– Бик җилбәзәк нәрсә идең, Себер салкыны акылга утырткан икән сине, – ди.

Кыз картка иркәләнеп сыена, үзенең күзләрендә яшь ялтырый:

– Ай, бабакаем, искә төшермә ул хәлләрне!.. – ди дә, аккош кебек биеп, җегетләр, кызлар төркеменә барып кочакларына керә, башкалар моңа ара-тирә ышанычсыз күз ташлап, читкәрәк борылалар.

Кичәнең иң кызу вакытында миңа Миңҗамал килде. Үзе гаҗәп шат: йөзе көлә, күзләре көлә, тавышы көлә:

– Сиңа бик якын бер кеше килде... Хәзер чыксын дип әйтә, бакча эчендә, өеңдә көтеп утыра, – ди.

– Кем? – дим.

– Юк, ярамый, әйтмәскә кушты, кичәдәге халык белмәсен дип әйтте, – ди.

Аякларны, таякларны күтәрәм; халык юл бирә. Чыгып китәм.

**XLVIII**

Өемә кергәч, каршыма килгән кешедән аптырап калдым.

Кем булыр дисез?

Яңа гына кайтып, минем бүлмәмдә, өсләрен дә чишенмичә көтеп утыручы сезгә бик якыннан таныш – минем балалык, яшьлек дустым, революциядә дошманым булган Фазыйл иде.

Күңелемдә ике катлау, ике дулкын туды, шулай да тыштан сер бирмәскә тырыштым. Беренче сәламнән, беренче сүзләрдән соң үзеннән дә яшермичә:

– Кая, җегет, күп үзгәрдеңме? – дигән кебек, йөзенә, өс-башына озак карадым.

Үзгәреше бик зур да, бер дә юк та.

Аякта зур итек, солдат пуставыннан тегелгән галифе чалбар белән килешле френч; билдә, аркада каешлар, сары кобура, аның эченнән наган башын чыгарып карап тора.

Гәүдә нык, таза, каты күренә; элеккедән күп чыныкканга охшый.

Сакал-мыекны әле дә кыра икән. Ләкин озак юлда булудандыр, яңаклары, муеннары күгәреп, ярты каралып киләләр, иреннәр көйгән, карасуланып көеп, бераз кызу канлылык әсәре күрсәтәләр. Фазыйлда элек бу

юк иде. Күзләре элекке кебек матур, акыллы, ләкин тирән бер уй белән карыйлар. Күз төпләренә, маңгай урталарына таба сузылган тирән җыерчыклар, ике чигәдә ара-тирә ялтыраган ак чәчләр җегетнең соңгы берничә елда күп нәрсә, бик күп җәфа кичергәнен күрсәтәләр. Чех, Колчак сабак биргән икән, дип уйладым. Күзләренә туры карадым да:

– Син дә шулай тиз картаясың микәнни, Фазыйл? – дидем.

Начар махорканы китаптан ертып алган кәгазьгә төрә-төрә:

– Бардыр, Солтан, мин кичергән җәһәннәмнәр бер минутта адәмнең чәчләрен бөтенләй агартсалар да гаҗәп түгел! – диде.

Әнкәйнең самавыры, чынаяклары өстәлгә килеп утырганда, Фазыйл мине үзенең җәһәннәм утлары эченә алып кереп киткән иде инде. Сабый чакларда, җегет вакытларда мин аның фикер агышы эчендә булырга – бергә агарга өйрәнгәнмен.

Соңгы елларда булып узган[*] сыйнфый дошманның сугышы безне ут белән су кебек каршы куйса да, миләрнең, йөрәкләрнең юллары тагы бергә кушылып ага башлады бугай.

Күп сүздән соң мин аңа мәсьәләне туры куйдым:

– Партиягә керүеңне дә беләм...[**] Мәскәүдә байтактан эшләвеңне дә ишеттем... Ачыгын әйт: Гыйлаҗи белән аның атасы Зариф картның каны синең кулдамы, түгелме? – Бу бер. Хәзерге үзгәрешең ихлас күңелдәнме, әллә җан саклау өчен, тагы элекке кебек халыкның башына менеп утыру өченме? – Менә бу ике.

Фазыйл яшермәде – күзләремә туры карап:

– Хәзер атып үтерсәң дә, мин синең кулыңдамын, дөресен әйтәм: Гыйлаҗи белән Зариф бабай мәрхүмнәрнең газраиле мин түгел, ләкин теләсәм, вакытында ул газраилне туктата ала идем мин, – диде. – Ихластанмы, баш саклау, халык җилкәсенә яңадан атлану өченме? – дисең... Син бит мине беләсең!

– Бик яхшы беләм.

– Беләсең син: миндә иман белән гамәл бервакытта да аерылмый, аерыла алмый...

– Аны да беләм.

– Аларны белсәң, син минем шикелле йөзләрчә, меңнәрчә укымышлы Фазыйлларның, Иваннарның, Петровларның авыр трагедияләрен бер-ике сүз белән аңлаячаксың.

---

[*] 1936 елгы басмада: *еллардагы үткенләнгән.*

[**] 1936 елгы басмада: *Партиягә кандидат икәнеңне беләм.*

Фазыйлның күзләреннән тирән хәсрәт болыты үтеп киткән кебек булды, авыр хәсрәтле бер тавыш белән дәвам итте:

– Зур сүзләр бар иде... – ди. – Берәүләр бөек Россия[*] ди иде, ватан ди иде. Без төрек-татар байрагы ди идек. Милли азатлык намына[43] чехка, милли идарәгә[35+], Колчакка тагылдык... Халыкны аларга чакырдык. Гыйльмебезне, талантыбызны шуларга корал иттек... Полклар төзеп бирдек. Ак офицерлар бирдек... Эшче-крестьянның палачлары булдык... Революциягә каршы сугыштык. Ләкин, ләкин нәрсәгә ирештек?.. Безнең кебек ихлас күңелле зыялыларның алган нәтиҗәсе, ирешкән хәкыйкате бер генә булды: Иваннарның да, безнең дә ул бөек байраклар, шигарлар[44] һәммәсе алпавыт белән буржуаның җирен, суын, байлыгын, алтынын сакларга, арттырырга бер корал гына икәне көн кебек ачылды. Без һәммәбез шул юлда эшләүче ахмак, сукыр, яки аңлы, ләкин сатлык агентлар гына икәнлеге авыр канлы көрәшләр ялкынында безгә революция нуры белән ачык мәгълүм булды... Моны аңлагач, мин үземә-үзем кызганыч булдым... Хурландым... Ничә мәртәбә үземне үтерергә теләдем... Чех, Колчак белән йөреп, Советка каршы сугышуым өчен хурландым... ...Юк, дидем... Пролетариатка барам...

Ул мине аңлар, дидем. Гафу итәр, дидем. Менә шулай итеп, без кичә табынган тәңреләрне утка яктык... Кичә таптаган Аллаларга хәзер табына башладык... Колчактан Ленинга[36+], пролетариатка килдек, – ди.

– Боларны яңадан бер кат таптамавыңа күзең җитәме?

– Җитә, мең мәртәбә җитә: мин тормышны, тарихны аңладым: бәлки, тагы авыр көннәр, тагы җиңелүләр булыр, ләкин Иделнең суларын кирегә агызу мөмкин булмаган кебек, бөтен дөньяда туып килгән азатлык хәрәкәтләрен дә басарга мөмкин булмаячак... Бу хәрәкәт җиңәчәк... Дөньяның Колчаклары йөзтүбән китеп бетәчәк, Маркс-Ленин юлы[37+] адәмнәрне чын азатлыкка, яктылыкка илтәчәк, ди. Революция тәҗрибәсе моны ачып салды, – ди.

Фазыйл сүзен бетерер-бетермәс урыныннан торды, тәмәке төпчеген мичкә ташлады да яңадан минем каршыма килде. Күзләремә туры карады.

– Беләсеңме, Солтан? – ди. – Мин бер ашыгыч эш белән кайттым. Иртәгә сәгать дүрттәге поездга өлгерергә тиешлемен, – ди.

– Ник бик тиз?.. Нинди ашыгыч эш ул? Иптәш минем яныма ук килеп утырды:

– Мин, туган, Гали мәрхүмнең сеңелесен алырга кайттым, – диде.

Гаҗәпсенеп каравыма каршы, үзенең бу фикергә ничек килүен озак

---

[*] 1936 елгы басмада: *Русия.*
[43] *Намына* – исеменә.
[44] *Шигарлар* – лозунглар.

хәсрәтле рәвештә сөйләп бирде. Мин, әлбәттә, каршы төшмәдем... Ярый, дидем. Нәрсәгә баш авырттырыйм?!

Кызны чакырттым. Фазыйл авызыннан чыккан төтеннәр эчендә сөйли бирде. Себердә һәлак булган атасы Заһит мулланың хәлләрен, акылдан язып, дөньядан югалган анасы Җиһан остазбикәне эзләтергә кеше җибәрүләрен, хәзер кая ашыгасын, алда нинди планнары барлыгын, командировкасының вакыты үтүләрен сөйләп бетәргә өлгерә алмады, бая «театр»дагы киемнәре өстеннән башына нечкә аксыл шарф, җилкәсенә матур, зәңгәр кожан[45] салып, җиңел атлап, уйнаклап туташ[*] килеп тә керде. Ул һаман да шат, ләкин һаман да эчке яралы иде.

**XLIX**

Фазыйл каршы барып аңа кул бирде:

– Сез мине таныйсызмы?

Кыз матур елмайды, күзләрен нурландырып җегетнең кулларын кысты:

– Бу нинди сүз тагы?! Әлбәттә, таныйм: бергә рәхәтләнеп йөри алмасак та, без бит, һич булмаса, җәйләрдә унбиш-егерме ел буенча янәшә йортларда үстек. Сез минем беренче мәхәббәтем – яшерен балалык мәхәббәтем идегез... Гимназиягә баргач, кыш көне китап читләрем сезнең белән тула иде... – ди.

Миңа тыңлау күңелсез, шулай да чыдыйм. Утыруларын үтендем. Кызга урын күрсәттем. Фазыйл, әле арлы-бирле йөреп, әле кызның каршысына килеп, ачык, кыска рәвештә сөйләргә тотынды:

– Бер-беребезне бик яхшы белүебезгә таянып, – ди, – мин һәммә мәсьәләне туп-туры куячакмын. Буяп, бизәп торырга хаҗәт күрмим. Моның өчен ачуланмаска сүз бирәсезме?

– Рәхим итегез!

– Менә нәрсә, туташ, – ди. – Мин сезнең өчен, сезне алу өчен кайттым, – ди.

Туташ аскы иренен тешләп куйды. Әлбәттә, ышанмады. Аннан башка да бик артык күп газаплар кичергән бер хатын белән мондый тупас шаярулар сезгә бер дә килешми, дигән шелтәле мәгънә белән җегеткә карады:

– Тагы ни әйтәсез? Дәвам итегез.

– Ни әйтим? Ачык мәсьәләгә туп-туры җавабыгызны көтәм.

Кыз бераз уйланды, көләргә дә, ачуланырга да аптырап, миңа борылды:

– Бу нинди хәл бу, Солтан абый? Бу – өнме, төшме, әллә без барыбыз да саташабызмы? – ди.

Мин көлмәскә тырыштым:

– Гафу итегез, мин тик тамашачы гына. Әгәр дә таракан булсам,

---

[45] *Кожан* – күн плащ яисә күн пальто.

[*] 1936 елгы басмада: *кыз.*

таякларымны, аякларымны күтәрәм дә чыгып китәм, яки мине калдырасыз да, үзегез бакчага рәхим итәсез.

Гыйрфан бай кызы бераз югалды, миңа карап:

– Юк, юк... Сез, әлбәттә, бу мәсьәләнең эчендә булыгыз, – диде дә җегеткә әйләнде:

– Их, Фазыйл абый, сез бераз соңгарак калмадыгызмы икән? Беләсезме, сез бит миңа дүртенче ир булырга телисез!

– Беләм, бик беләм.

– Минем матур күзле, күңелле сүзле мәрхүм Шаһибәгемне дә, яратып аңа кияүгә баруымны да, аңардан булган дүрт айлык баламны төшерүемне дә беләсезме?

– Беләм.

– Аннан соң Томски шәһәрендә Иванов дигән бер урыс офицерына ай ярым сөяркә булып торуымны да ишеттегезме?

– Аны да ишеттем.

– Фәхри дигән бер карт татар спекулянты, үз вагонына утыртып, мине юл буенча кочагында изеп*, калага китереп ташлавыннан да хәбәрегез бармы?

– Бар. Аннан да хәбәрем бар... Ләкин аптырыйм: ник сез боларны сөйләп, үз йөрәгегезне яралыйсыз?..

Туташ башын аска иде дә акрын, әрнүле тавыш белән әйтте:

– Мин күңелемдәгене яшерә белмим. Бу – минем баладан бирле килгән табигатем. Ул фаҗигаләрне сөйләвем менә ни өчен: ирләр, үзләре ничаклы фахиш[46] булсалар да, хатыннарның «намуслы», «гыйффәтле», «һичкемнең кулы тимәгән» булуын телиләр. Бу турыда безнең мәрхүм Гали абзыйның:

– “Ләм йәтмисһөннә инсө каблаһөм вә лә җан”[47] дип авыз суы корый торган иде. Башта әйтелмәсә, ахырдан күп аңлашылмаулар чыга. Болардан бик артык туйганмын. Шуңа күрә сөйлим.

– Бу сүзләрнең һәммәсен кирәксез саныйм. Сезнең ул фаҗигаләрегез генә түгел, бер хатынның фәхешханәдә булуы, рәсми фахишәлеге дә миңа аның белән язмышымны рәсми багларга манигъ[48] була алмас иде. Бу мәсьәләләрдә мещаннарның карашыннан бик артык югарымын мин хәзер.

– Туктагыз, минем сүзем бетмәгән: моннан байтак еллар элек безнең әнкәйләр сезнең теләүдән башка безне өйләндерә язганнар иде. Мин ул вакытларда, “бу ир-җегет миңа насыйп була икән”, дип шатланып йөргән

---

* 1936 елгы басмада *кочагында изеп* сүзләре урынына *үзенә хатын итеп* сүзләре килә.

46 *Фахиш* – азгын, зина.

47 *Ләм йәтмисһөннә инсө каблаһөм вә лә җан* – Аларга моңа хәтле ирләр һәм җеннәр кагылмаганнар.(Коръәннән алынган).

48 *Манигъ* – киртә, тоткарлык.

идем. Сез ник шул вакытта кире кагып, хәзер яңадан мине эзләп кайтасыз? Ул чакта, миңа һичкемнең “кулы” тимәгән иде. Мин бай идем. Артымнан сезгә күп җир-сулар, йортлар, урманнар, тегермәннәр барачак иде.

– Яшерергә теләмим; дөресен әйтәм: ул вакыт мин Гәүһәр дигән бер Аллага* табына идем.

– Хәзер кайда ул Аллагыз?

– Мин чех, Колчак белән бергә Себердә кызылларга каршы сугышып йөргән чакта, минем ул “Аллам”, ул “фәрештәм” ниндидер вак приказчиктан кәгазь миллиардерга әйләнгән бер яшь спекулянтка кияүгә чыккан.

– Хәзер инде сезгә бер «катын» кирәк булды да, мине хәтерләдегез... Шулаймы?..

– Алай гына түгел: миңа мине сөйгән бер юлдаш кирәк... Мин беләм, баладан ук сезнең йөрәгегездә мин бар идем. Сезнең яшь вакытта асрау артыннан җибәргән берничә мәктүбегез әле дә миндә саклана лар.

– Ярый, бусы дөрес. Сез минем күңелдәгеен укыйсыз... Мин сезгә асыл сылу тәнемне, зифа буемны, калган яшьлегемне, иркәләвемне генә түгел, йөрәгемне дә бирермен... Ул күптән сездә дә... Ләкин Фазыйл үзе миңа нәрсә бирер?

– Фазыйл сезгә уңайлы ир булыр, күңелендә хатын-кыз өчен күпме нәрсә калган булса, шуларның барын бирер. Сез яшьтән үк Фазыйлның йөрәгендә сөйкемле һәм яхшы күңел иясе бер җан булып урнашкансыз. Мин сездә үземә юлдаш күрәм.

– Минем сүзем бетте.

Фазыйл кызның каршысына килеп кулын сузды:

– Димәк, син риза, алайса – бир кулыңны!

Туташ урыныннан торды, җитди, ләкин матур елмайды.

– Ул турыда ике сүз булырга ярамый! – дип, үзенең кайчандыр бик артык нәфис булган, ләкин хәзер ярылып бераз гына тупаслана төшкән кулларын Фазыйлга сузды да шатланып, көлеп, аны миңа өстерәде:

– Ну, Солтан абый, икебезгә дә ата бул: безгә фатиха бир, – ди.

Мин шаярып карадым, бу эштән читтә калырга җай калмады, кычкырып көлдем:

– Ике яшькә мәхәббәт телим, – дидем дә кулларын кыстым.

Озак утырмадылар.

Кыз үзе үк:

– Фазыйл, сиңа монда уңайсыз булыр... Әйдә йокларга минем бүлмәмә бар! – диде.

---

* 1936 елгы басмда: *кызга.*

Миңа хәерле йокы теләп, чыгып киттеләр. Мин көлеп калдым. Ат кешнәшеп, байлар иснәшеп табышалар икән.

– Хәерле зөфафлар[49]! – дип калдым. Башка нәрсә әйтим? Әллә көлке, әллә кызганыч, – белмим.

Кыз каршы тормады, җегет үз вакытыннан калырга бер дә теләмәде. Икенче көнне бу хәбәрне үзе ишетеп килгән яшь җилкенчәк белән бер чәй мәҗлесе ясадылар.

Көндез сәгать уникедә зур тарантаска кыңгыраулап җигелгән пар ат Гыйрфан байның Себердән кайткан кызы белән Фазыйлны хәзер колхоз үзәгенә әйләнгән Гыйрфан бай йортыннан кояш баешы ягына таба алып чыгып китте.

Киттеләр.

Ләкин Фазыйл минем йөрәгемә кара кан саудырып китте. Мине йөз еллык картайтып китте.

Үзендәге үзгәрешләр турында озаклап тукталу өчендерме, кыз белән эшен бетерү өчендерме, белмим, ни сәбәптәндер, минем каршымда мең Фазыйлның иман алмаштыруыннан, миллион кызларның кемнәргәдер кияүгә чыгуларыннан, мең мәртәбә, миллион мәртәбә алдарак торган бер хәбәрне – Шаһбазның ахыр фаҗигасен тик китәргә дип атлар җигелә башлагач кына сөйләде.

– Безнең уртак бер кайгы бар, – ди. – Шаһбаз хакында якын арада күңелсез хәбәр яздылар, – ди.

Сүз аз, хәбәр кыска:

– Минем дөньяда калган бердәнбер дусымны басмачылар авыр бер газап белән ике ай элек Фирганәдә үтергәннәр!

Фазыйл аның хакында байтак нәрсә белә икән.

– Соңгы ел ярым эчендә ара-тирә хаты килгәли иде, ди. Миңа түгел, безнең белән бергә эшли торган бер хатынга килә иде, ди. Кайбер җирләрен миңа да укыта иде, ди. Ул мәктүбләрендә: Донны, Кубаньны тазарттык, ди торган иде, ди. Кавказның биек карлы таулары арасында дошманның җанын алдык. Азәрбәйҗан, Каспий аша Төркстанга юл тотабыз, дип яза торган иде, ди. Сыр-Дәрья, Аму-Дәрья буйларында кара болытлар күренә. Шуларны тазарткач, дөньяның кай җирләрендә, нинди канлы көрәшләрдә йөзәргә насыйб булыр – хәзергә белмим, дип яза иде, ди. Бохарада, Фирганәдә булган кара көчләр[38+] өчен куркыныч кызыл батырларның берсе безнең Шаһбаз икәнен ул җирләрдән кайтучылар сөеп сөйлиләр иде, – ди.

Актык хәбәр яңа алынган:

---

[49] *Зөфафлар* – өйләнешкәннәрнең беренче төне.

Шаһбазның башы өчен меңнәрчә алтыннар вәгъдә кылынган икән. Бер хыянәт белән кулга төшергәннәр дә, басмачыларның кара ояларында биек баганалар белән югары асып, түбәннән җәһәннәм кебек ут якканнар, ди. Каһарман шунда кычкырып-кычкырып янган имеш, ди. Дошманнар үзләре качкач, безнекеләр аның гәүдәсен шул күмер хәлендә асулы тапканнар. Олылап күмгәннәр.

Ләкин бу күмүдән, бу кадердән, бу олылаудан миңа, гайрәтле Шаһбазны белгән меңнәрчә минем кебек җегетләрнең йөрәгенә нинди юаныч?

Гыйлаҗины аттылар. Шаһбазны утка яндырдылар*. Болар – кадерле корбаннар! Революция корбаннары! Хәзер инде кем кала? Кемнәр кала?** Фазыйлләрмы? Безнең түгелгән каннарның эсселегендә кайнап кына яңа «өлгерә» башлаган шул галим*** җегетләрме? Революциянең канлы, утлы көннәрендә чех, Колчак яклап, советка каршы сугышкан ул Фазыйлләрмы?*

Мондый укымышлы ирләрнең безгә файдасы, бәлки, зурдыр, ләкин боларның меңе авыр көрәш көннәрендә бер Гыйлаҗиның, бер Шаһбазның кисеп ташлаган тырнагына да тормыйлар бит! Моны мин күз алдымда күрдем. Фазыйл, бәлки, яхшы да булыр, әмма Гыйлаҗилар, Шаһбазлар бөтенләй башка җегетләр алар!

**L**

Моннан биш-алты ел элек сугышка киткәндә, Гайния мине:

– Көтәрмен... айлар, еллар көтәрмен... Аяксыз, кулсыз булып кайтсаң да, син минеке! Башкаларга күзем дә, күңелем дә төшми! – дип, елап озаткан иде.

Мин булмаган чакларда, бигрәк тә минем хакымда «атылган икән, асылган икән» дип төрле хәбәрләр таралган вакытларда, ул сылу тәнле, уңган куллы асыл кызны төрле җирләрдән яхшы-яхшы урыннарга сорап башкодалар күп йөргәннәр.

Ләкин ул һәммәсен:

– Сүз биргән җегетем бар... аны көтәм... – дип, кире кайтара торган...

Авылга соңгы мәртәбә кайтып төшкәч, элекке кебек качмады. Тартынмады. Кеше алдында минем белән сөйләшә бирде.

Әни бик картайды инде. Вак-төяк эшләр дә аны бик арыталар. Гайния

---

* 1936 елгы басмада: *яктылар.*

** 1936 елгы басмада: *Инде Зәңгәр чишмә дус-ишләреннән кемнәр кала?*

*** 1936 елгы басмада: *гыйлем.*

* Бу урында 1936 елгы басмада түбәндәге абзац бар: *Әлбәттә, түгел. Әнә кызыл инвалидны шаулап каршы алган яшьләр, ячейка массалары, комсомолка Миңҗамаллар бармы? Әнә шулар эченнән тагы исәпсез Шаһбазлар туып күтәреләчәкләр.*

килгән саен безнең әллә ничаклы эшләрне башкара, өйне җыештыра, самавырны агарта, карчыкның гөлләренә, җимешләренә, яшелчәләренә сулар сибә иде.

Кайтып төшкән көннәрдә, ячейка белән, яшьләр белән кайнашып, ничектер, иркен бер вакыт таба алмадым – Гайния белән озаклап сөйләшә алмадым. Ләкин болай сөйләшүнең кирәге дә булмады. Безнең тормышлар, ничектер, үзеннән-үзе кушылып киттеләр...

Беркөнне шулай Гайния җиләктән кайтышлый:

– Әбекәем, бик харап сусадым. Бозлы әйрәнең юкмы? Синдә була торган иде, – дип, янып-пешеп, кызарып, безгә керде.

Минем карчык үзенең хәлсез куллары белән кер юып азаплана иде. Кыз түзмәде:

– Их, әбекәем, бер дә рәтең калмаган синең хәзер. Бар, өеңә кер. Мин үзем бу нәрсәләреңне башкарырмын, – диде.

Мин агач төбендә, аңа сокланып, колхоз турында бер китапны укыштырыбрак ятам. Гайния зәңгәр яулыгын артка кайтарып салды, ак алъяпкыч белән билне кысып, күкрәкне калкытып бәйләде, ак шалкан кебек тулы матур беләкләрне сызганды да, бер самавыр кайнап чыгарлык вакыт үтмәгәндер, бөтен чүп-чарны юып бетерде. Аннан сон, ике чиләккә тутырып, көянтә белән бөгелә-сыгыла Агыйделгә төшеп керләрен чайкап та менде.

Ул арада әнкәйнең самавыры да кайнап чыккан иде. Гайния җыеп кайткан җиләкләр белән тәмләп чәй эчтек.

Өстәлне җыештыргач, ындырдан бер чиләк эре бәрәңге алып кайтты, кое төбендә кырып юды да пешереп безне сыйлады. Кояш баткан иде инде. Бәрәңге ашагач, без икәүләп өй буена бакчага чыгып утырдык.

Гайния күп көлде... Авылның әллә нинди гайбәтләрен сөйләп бетерде... Аннан соң, ничектер, үткән көннәргә кереп киттек...

Авыр вакытлары булган. Агасы Гыйлаҗи белән атасы Зариф карт үтерелгәч, күп җирләрдән башкодалар килеп, бик аптыратканнар... Әнкәсе дә көчләп караган... Ләкин берсенә дә якын бармаган:

– Сүз биргән җегетем бар... аны көтәм, дип әйтә идем, – ди.

Утыра торгач, вакытның үтүе сизелмәгән дә икән. Бакчадагы үләннәрдән, чәчәкләрдән төнге тәмле, ләкин юеш хуш ис күтәрелә башлады. Бер почмакта көндез күренми торган ахшам чәчәкләре ап-ак булып атып чыктылар.

Агыйдел аръягындагы Урал тармаклары артыннан кызарып ай калыкты. Дөнья йөзе матур, йомшак нурга чумды.

– Абау!.. Без таңны аттыра язганбыз икән, – диде дә, Гайния урыныннан кузгалды.

Мин аны кайтармадым, акрын гына билләреннән алдым да маңгаеннан үптем.

Бүген кич безнең зөфаф булды.

Бу төн Гайния белән минем тормыш бөтенләй бергә кушылды. Никах, туй дигән кебек нәрсәләр, ничектер, минем хәтеремә килмәде, Гайния дә кузгатмады.

Шул көннән безне:

– Солтан өйләнгән икән,

– Гайния кияүгә чыккан икән, – дип сөйли башладылар.

Без яхшы торабыз.

Гайния тиз арада тагы чибәрләнеп, нурланып, җиңелләнеп китте.

Мин кайткан чорларда аның күз төпләрендә ниндидер бер әйтелмәгән хәсрәт эзе сизелә* иде. Йөзендә, бөтен торышында да яңгырсызлыктанмы, каты җил-давылданмы бераз газапланган, бераз шиңә төшкән кызыл чәчәкне хәтерләтерлек бер төс бар иде.

Бакчадагы кызыл чәчәкләр, җылы яңгырлардан соң, якты, кояшлы аяз көннәрдә ничек матураеп, кызылланып, янып китсәләр, хәзер Гайния дә шулай булды.

Гыйльминур җиңги безгә бик дусланып китте, ул кергән саен безне шаярта, көлә:

– Гайния, – ди, – аяз елның чәчәге кебек корып бара иде, ди, «яңгыр» килеште аңа: хәзер кем булды бит, карап туймассың, – ди.

Яңа елга балабыз да туачак. Моны бездән бигрәк әнкәй бик көтә.

Кайдан сизә торгандыр, Гайния әйтә, угыл булыр, ди. Без аңа Шаһбаз дип исем кушарбыз, ди. Мин, сөеп, риза булып, аның маңгаеннан, чәченнән үбәм. Гыйлаҗи белән Шаһбаз йөрәгемнең зур бер өлешен өзеп алып киткәннәр иде. Калганын бөтен көенчә революциянең авыл фронтына һәм Гайниягә бирдем. Ул минем юлдашым да, терәгем дә, күңелем көче дә булып бара.

Ара-тирә Фазыйл искә төшкәли. Аны да бик аз гына яратам бугай... Ләкин бу өстән генә, акыл белән генә ярату булса кирәк.

Әмма йөрәгемне яңадан һичбер вакыт үзенә ала алмас инде, ахры... Шаһбаз белән Гыйлаҗи бервакытта да күңелемнән чыкмыйлар. Бу ике иптәшем минем йөрәгемдә революция белән бергә багланып кереп утырдылар.

Менә шулай булып бетте безнең язмышлар.

---

* 1936 елгы басмада: *беленә*.